ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫ

*Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар*

Казан
2021

**УДК 398+801.81**
**ББК 82.3(2=632.3)**
**Б 33**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни редактор**
*филология фәннәре докторы, профессор* ***Ким Миңнуллин***

**Томны төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы**
*филология фәннәре кандидаты, доцент* ***Илдус Фазлетдинов***

**Рецензентлар**
*филология фәннәре докторы, доцент* ***Лилия Мөхәммәтҗанова;***
*филология фәннәре кандидаты* ***Ильмир Ямалтдинов***

**Б 33** **Башкортстан татарлары фольклоры.** Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов. – Казан: ТӘһСИ, 2021. – 304 б.
ISBN 978-5-93091-348-4

«Башкортстан татарлары фольклоры» сериясендәге әлеге китапка Башкортстанның үзәгендә һәм төньяк-көнбатышында урнашкан Бакалы, Балтач, Борай, Дүртөйле, Илеш, Чакмагыш районнарында яшәүче татарлар фольклоры кертелде. Татарлар күпчелекне тәшкил иткән районнардан санала торган төбәк буларак, биредә яшәүче халыктан җыеп алынган гаять бай һәм күптөрле авыз иҗаты әсәрләре игътибарны үзенә җәлеп итә.

Китап туган як тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

**УДК 398+801.81**
**ББК 82.3(2=632.3)**

**ISBN 978-5-93091-348-4**

© И.К. Фазлетдинов, 2021
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2021

## КЕРЕШ

Татар халкының дүрттән бер өлеше генә Татарстанда яши. Калган дүрттән өч өлеше Русия Федерациясенең һәм дөньяның төрле почмакларында гомер кичерә. 2010 елгы халык исәбен алу нәтиҗәләре буенча, Татарстаннан көнчыгышта урнашкан Башкортстан Республикасында гына да 1 миллионнан артык татар кешесе яшәгәнлеге мәгълүм. Сан буенча бирелә татарлар өченче урынны алып тора, бу исә республикада яшәүче халыкның 24,78 проценты дигән сүз[1]. Табигый, Башкортстан территориясендә яшәүче татар милләте вәкилләренең рухи мирасы – галимнәрдә зур кызыксыну тудыра торган өлкә, бу мирасны барлау, туплау һәм өйрәнү гуманитар фәндә әһәмиятле бурычларның берсе.

Соңгы елларда халкыбызның тарихына, рухи һәм мәдәни ядкярләрен барлауга игътибар шактый көчәйде. Заман тудырган яңа сорауларга ачыклык кертүдә халык авыз иҗаты әсәрләренең роле бик зур. Тарих төпкеленә төшеп, хәзерге Башкортстан җирләренең кайсы дәверләрдән милләттәшләребез өчен Ватан булуын ачыклау, мондагы татарларның төрле өлкәләргә карый торган борын-борыннан килгән яшәү-тормыш итү үзенчәлекләрен билгеләү, тарихи вакыйгаларның аларның тормышына нинди үзгәрешләр кертүен тикшерү, татарларның биредәге күрше халыклар белән мөнәсәбәтләренә, урындагы җир-су атамаларына, авыз иҗаты әсәрләренә һ.б. күзәтү ясау – болар һәммәсе дә төрле юнәлешләрдәге күп кенә сорауларга ачыклык керткәндә, игътибарны үзенә җәлеп итә. Матди һәм матди булмаган тарихи

---

[1] Население Башкортостана / Википедия, 2020. URL: https://ru.wikipedia.org/wiki/Население_Башкортостана

чыганаклар сөйләп бетерә алмаганны күп вакыт халыкның авыз иҗаты әсәрләре бәян итүе беребезгә дә сер түгел.

Халыкның үз башыннан кичергән вакыйгалары турында сөйләгәнгә күрә, фольклор әсәрләре әдәби кыйммәткә дә, тарихи әһәмияткә дә ия. Күренекле фольклорчы Ф.И. Урманчеев сүзләре белән әйтсәк, «риваятьләр, легендалар, мифлар теләсә кайсы халыкның иң борынгы һәм борынгы тарихын өйрәнүдә мөһим чыганакларның берсе булып торалар»[1]. Чыннан да, халык иҗаты жанрларында алдагы буыннарның тормыш фәлсәфәсе, тәҗрибәсе, тарихи үткәне, хәтере чагылыш таба.

Хәзерге Башкортстан Республикасы территориясендә яшәүче татарларның этногенезы, тарихи, мәдәни һәм тел үзенчәлекләре тикшеренүчеләр тарафыннан шактый өйрәнелгән, тарихчы һәм телче галимнәрнең бу өлкәгә кагылышлы әһәмиятле хезмәтләре дөнья күргән[2]. Шулай булса да бирелгәге татар

---

[1] *Урманче Ф.И.* Проблемы национальной истории // Академик Мирфатых Закиев. К семидесятилетию / редакторы-составители: Ф.И. Урманче, Х.Ш. Махмутов. – М.: Инсан, 1998. – С. 86.

[2] *Давлетшина З.М.* Татарское население Башкортостана: этнодемографическое исследование / отв. ред. Р.М. Юсупов. – Уфа: Гилем, 2001. – 201 с.; История татар Западного Приуралья. Т. I. Кочевники Великой степи в Приуралье. Татарские средневековые государства: коллективная монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. – 464 с.; *Исхаков Д.М.* Историческая демография татарского народа (XVII – начало XX в.). – Казань: Печатный двор, 1993. – 143 с.; *Кузеев Р.Г.* Народы Среднего Поволжья и Южного Урала: этногенетический взгляд на историю. – М.: Наука, 1992. – 344 с.; Национально-культурные проблемы татар Башкортостана: тезисы республиканской научной конференции. – Казань: Магариф, 2003. – 176 с.; *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров Юго-Западной Башкирии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 191 с.; *Рамазанова Д.Б.* Ык ага чик сызыгы булып... // Идел. – 1993. – № 9. – Б. 58–71; *Рахматуллин У.Х.* Население Башкирии в XVII–XVIII веках: вопросы формирования небашкирского населения / У.Х. Рахматуллин; отв. ред. Н.И. Павленко. – М.: Наука, 1988. – 186 с.; *Сибгатов Р.Г.* Башкортстан татарлары. Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – 191 б.; *Юлдашбаев Б.Х.* История формирования башкирской нации (дооктябрьский период). – Уфа: Башкир. кн. изд-во, 1972. – 336 с.; Татары Уфимского уезда (материалы переписей населения 1722–1782 гг.): справочное издание / отв. ред. Р.Р. Исхаков. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2020. – 192 с. и др.

телле халыкның милли үзбилгеләнеше мәсьәләсендә бәхәсләр әлегә кадәр тынганы юк. Бу җәһәттән Башкортстан республикасында борын-борыннан җирле халыкның зур өлешен тәшкил итеп яшәүче татарларның фольклор әсәрләрен җыеп, туплап бирү, тикшерелә торган ареалда татар халык авыз иҗатын җыю һәм өйрәнү тарихына, татар фольклорының биредәге торышына күзәтү ясау, безнең карашыбызча, бүгенге көндә актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала.

* * *

XVI–XVIII гасырларда Русия дәүләте күп кенә яңа территорияләргә, шул исәптән хәзерге Башкортстан җирләренә дә ия булгач, төбәкләрне өйрәнү өчен, күпсанлы гыйльми экспедицияләр оештырыла. Мәсәлән, 1768 елда, Русия Фәннәр Академиясенең карары буенча, П.С. Паллас җитәкчелегендәге экспедиция – Урал алдына, Көнчыгыш Себергә, Байкал күле артына, И.И. Лепехин җитәкчелегендәгесе Идел буена һәм төньякка юнәлә. Ике төркем дә бүгенге көндә Башкортстанга караган җирләр аша үтә. Алларына төбәкнең табигый-географик шартларын, ресурсларын, халыкның көнкүрешен өйрәнү бурычы куелса да, тикшеренүчеләр моның белән генә чикләнмичә, җирле халыкларның этнографиясе, фольклоры турында кызыклы гына мәгълүматлар теркәп калдыралар. Ике тикшеренүче дә үзләренең урындагы татарлар белән очрашуларын тасвирлап узалар. П.С. Паллас Уфа төбәгенең көнбатыш, көньяк һәм төньяк-көнчыгышында татарлар яшәвен билгеләп үтә һәм алар нигезләгән авылларның Агыйдел белән Ык елгалары арасында аеруча күп булуын ассызыклый. Тикшеренүче Уфа һәм Казан татарлары арасында телдә, гореф-гадәтләрдә бернинди дә аерма булмавы турында яза, бары тик Уфа татарларының хатын-кыз киемнәре казаннныкыларга караганда күпкә матуррак икәнлеген билгели[1].

---

[1] *Паллас П.С.* Путешествие по разным местам Российского государства по велению Императорской академии наук: пер. с немецкого. В 3-х частях. – СПб., 1786. – Ч. 2. – Кн. 1. – С. 7–11.

П.С. Паллас халык авыз иҗатына артык игътибар бирми. Шулай да аңа урындагы татарлар һәм башкортлар арасында таралган риваять, легендалар белән эш итәргә туры килүенә ишарәләр бар. Җир-су атамаларына бирелгән саран гына аңлатмалар шул хакта сөйли[1].

Икенче сәяхәтче И.И. Лепехин үзенең юлъязмасында хәзерге Башкортстан җирләренә урнашкан бер төркем татар авыллары аша үтүен билгеләп уза. Болар – Бакай, Байтуган, Камышлы, Усман, Авыргазы елгасы буендагы Корманай, Бәгәнәш, Сәет, Бугалыш[2]. И.И. Лепехин, аерым географик объектларга тасвирлама биргәндә, аларның атамаларының мәгънәсен, тарихын ачыклый.

1895 һәм 1897 елларда С.Г. Рыбаков тарафыннан тупланган йөздән артык татар һәм башкорт җыры ноталары белән бергә Петербургта басылып чыга[3]. Аларның кайберләренең барлыкка килү тарихларын тасвирлаган риваятьләр дә китерелә. Бу әсәрләр шактый кыскартылып бирелсә дә, С.Г. Рыбаков хезмәтенең әһәмияте зур: монда күпчелек тарихи җырларның көй, сүз һәм риваять синтезы рәвешендә яшәвен ачык күзалларга мөмкин.

XIX гасыр азагында хәзерге Башкортстанның төньяк-көнбатышын үз эченә алган Уфа губернасында яшәүче татарларның теле, этнографиясе, фольклоры белән кызыксыну кискен көчәеп китә. Н.Ф. Катанов, Уфа губернасының Бәләбәй өязенә килеп, биредә яшәүче татарларның тел үзенчәлекләрен аларның фольклор әсәрләре нигезендә өйрәнә һәм, Казанга

---

[1] *Паллас П.С.* Путешествие по разным местам Российского государства по велению Императорской академии наук: пер. с немецкого. В 3-х частях. – СПб., 1786. – Ч. 2. – Кн. 1. – С. 58–59.

[2] *Лепехин И.И.* Дневные записки путешествия доктора и академии наук адьюнкта Ивана Лепехина по разным провинциям Российского государства, 1768 и 1769 г.г. – Ч. 1. – СПб., 1795. – С. 196; Ч. 2. – СПб., 1802. – С. 7, 29, 141, 242.

[3] *Рыбаков С.Г.* О поэтическом творчестве Уральских мусульман: татар, башкир, тептярей / С.Г. Рыбаков. – СПб.: Типография С.Н. Худякова, 1895. – 37 с.; *Рыбаков С.Г.* Музыка и песни уральских мусульман с очерком их быта. – СПб., 1897. – 330 с.

кайткач, шул хакта өч фәнни хезмәт язып чыга[1]. Монда ул Урал алды татарларыннан язып алынган берничә җыр, бәет һәм мөнәҗәт тә китерә.

1906 елда тарихчы һәм тел галиме Г.Н. Әхмәров Вятка һәм Уфа губерналарына килеп, җирле типтәрләрнең тел үзенчәлекләрен һәм этногенезын тикшерә. 1908 елда дөнья күргән «Типтәрләр һәм аларның килеп чыгышы» исемле мәкаләсендә ул «типтәр» атамасының килеп чыгышы турында халык арасында таралган берничә этнонимик риваять китерә[2]. Галим фикеренчә, «бүгенге көндә типтәрләрнең күпчелеген татарлар тәшкил итә, дин, тел һәм гадәтләре, шулай ук торак урыннарының атамалары аларның Казан һәм Вятка губерналарыннан чыгуын һәм шушы губерна татарлары, ягъни Казан татарлары белән туганлыкларын дәлилли»[3].

1914–1915 елларда М.А. Васильев Идел-Урал төбәге буенча сәяхәт итеп, биредә яшәүче татарлар арасында таралган 60 тан артык әкият һәм легендаларны җыеп, урысчага тәрҗемә итеп, 1924 елда аерым китап итеп бастырып чыгара[4]. Шунысы куанычлы: биредә бүгенге көндә Башкортстанга караган территорияләрдә яшәүче татарлар арасыннан табып алынган легендалар да теркәлә. Мәсәлән, «Шүрәлене ничек алдарга» дигән хикәятне тикшеренүче Стәрлетамак өязе, Миркәтле волосте,

---

[1] *Катанов Н.Ф.* Отчет о поездке, совершенной с 1 июня 1897 г. по 20 августа того же года в Белебеевский и Мензелинский уезды Уфимской губернии // Ученые записки Казанского университета. – Казань. – 1898. – Кн. 11. – С. 1–37; *Катанов Н.Ф.* Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 года в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Ученые записки Казанского университета. – Казань. – 1900. – Кн. 7 и 8. – С. 1–30; Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 года в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Ученые записки Казанского университета. – Казань. – 1901. – Кн. 3. – С. 1–76.

[2] *Ахмаров Г.Н.* Тептяри и их происхождение. – Казань: Типолит. Казанского ун-та, 1907. – 27 с. [Отдельный отт. из «Известия общества истории, археологии, этнографии». – Т. XXIII. – Вып. 5].

[3] *Там же.* – С. 17–18.

[4] *Васильев М.А.* Памятники татарской народной словестности – сказки и легенды. – Казань: Изд. комбината издат. и печати ТССР, 1924. – 182 с.

Толбазы авылында язып ала[1] (бүгенге көндә әлеге авыл – Башкортстанның Авыргазы районы үзәге), «Сак-сок» легендасын Бәләбәй өязендә кәгазьгә терки[2].

1910 елның 15 апрелендә Казанның «Шәрык клубы»нда укылган «Халык әдәбияты» исемле лекциясендә мәшһүр әдибебез Габдулла Тукай татарлар һәм башкортлар арасында таралган «Тәфтиләү», «Сак-сок», «Җизнәкәй» кебек халык җырларын анализлый, шунда ук аларның барлыкка килүе турындагы риваятьләрне дә китерә[3]. Ул фольклор әсәрләрен җыю һәм өйрәнү эшенә аерым бер игътибар бирергә кирәклеге турында әйтә.

XX гасыр башында татар халкының, шул исәптән Уфа һәм Оренбург губерналарында яшәүче милләттәшләребезнең легенда-риваятьләрен, авыл тарихларын, башка фольклор әсәрләрен җыю, өйрәнү, фәнни анализлау, популярлаштыру өчен, «Шура» журналы зур көч сала. Аның мөхәррире, күренекле мәгърифәтчебез Риза Фәхретдинов Килем авылында *(хәзер Башкортстанның Бүздәк районына карый. – И.Ф.)* хезмәтче Галләметдин Сәйфетдин улыннан морза Йосыф Тәфкилевның үлеме турындагы риваятьне язып алып бастырып чыгара; «Тәфтиләү» җырын һәм аның тарихын нәшер итә[4]; шулай ук туган як тарихын өйрәнүгә багышланып, үз эчләрендә күпсанлы легенда һәм риваятьләрне анализлаган гыйльми мәкаләләр дә нәкъ шушы «Шура» журналында дөнья күрә[5].

Татар фольклорын өйрәнү эшенең төп юнәлешләрен билгеләүчеләрдән, тумышы белән хәзерге Башкортстанның Авыргазы районы Солтанморат авылыннан булган бөек әдибебез Галимҗан Ибраһимовның исемен аерым атарга кирәк. 1926 елда

---

[1] *Васильев М.А.* Памятники татарской народной словестности – сказки и легенды. – Казань: Изд. комбината издат. и печати ТССР, 1924. – С. 175.

[2] *Там же*. – С. 169.

[3] *Тукай Габдулла.* Әсәрләр: 4 томда. Т. III. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – Б. 257–259.

[4] Тәфтиләү // Шура. – 1915. – № 4. – Б. 97–99.

[5] *Вәлиди Гарифҗан.* Актүбә буйлары // Шура. – 1913. – № 4. – Б. 109–113; *Дәүлиханов Мөхәммәтҗан.* Бабалардан ишетелгән хәбәрләр // Шура. – 1915. – № 14. – Б. 153–159.

«Безнең юл» журналында аның «Тел, әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы. Татар халык әдәбияты турында» исемле зур гына мәкаләсе басылып чыга[1]. Монда әдип хәтта тупланган фольклор материалларын да бастырып чыгару мөмкинлекләре чикле булуы хакында әйтә һәм бу мәсьәләдә Башкортстан татарларының авыз-тел иҗатын өйрәнү эшенең торышына аерым туктала. «Мәсәлән, Бөре кантонынннан Гата Исхакый иптәш тарафыннан татар әкиятләре җыелган. Барлыгы 31 дәфтәр, 500 битләр чамасы. Карар күптән булса да, бастырып чыгаруның юлын таба алганыбыз юк. Фазыйл Туйкин иптәшнең «Ил әдәбияты» дип җыйган кыйммәтле материаллары байтак ятты-ятты да, басар өчен чара булмаганлыктан, рәнҗеп, шелтәләп, үзенә кире сорап алды. Большевик мөхәррир Афзал Таһиров иптәшенең дә яхшы материаллары бар. Якын арада Сәйфи Кудаш иптәш хат язып әйтә: «Җыйган нәрсәм бар, җибәрәм», – ди. Мәрхүм шагыйрьнең – Бабичның җыйганнары да шулай ук сакланып торалар. Болардан күренә ки, хәзер бездә халык әдәбиятын җыю төрле җирдә, төрле рәвештә башланган, моны бер җиргә туплап, тикшереп, коллективның хезмәте рәвешендә бастырып чыгару һәм тикшерүнең вакыты җиткәнлеге бик ачык күренәдер»[2], – дип, Галимҗан Ибраһимов Башкортстан җирлегендә яшәүче татарларның фольклорын өйрәнү эше канәгатьләнерлек дәрәҗәдә алып барылмавын билгели. Шунда ук ул татар фольклорының Казан татарларының иҗаты белән генә чикләнмәвен, аның башка өлкәләрдә һәм республикаларда яшәүче татарлар арасында булган фольклор белән баетылырга тиешлеген әйтә. «Әле бездә моңарчы җыелганы башлыча Казан татарлары эчендә җыелганнар. Хәзер башка кабиләләргә дә кул салырга кирәк»[3], – ди ул һәм шунда ук «җыйган вакытта һич-

---

[1] *Ибраһимов Г.Г.* Әсәрләр: 15 томда. – Т. 8: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918 – 1933) / төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче Г.А. Хөснетдинова; кереш сүз авторы Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – Б. 259–263.

[2] *Шунда ук.* – Б. 260–261.

[3] *Шунда ук.* – Б. 262.

нәрсәне үзгәртмәү, бозмау, халык авызында ничек ишетелгән, шул көенчә язып алу – беренче шарттыр. <...>. Кайдан-кемнән, нинди кабиләдән, кай районнан алынганын, әлбәттә, әйтеп җыярга, язарга кирәк»[1], – дип, фольклор җыюның төп фәнни кагыйдәләрен бирә.

Галимҗан Ибраһимов биредә татар халкын алты «кабиләгә» – Казан татарлары, Касыйм татарлары, мишәрләр, алатырлар, төмәннәр, типтәрләргә бүлә[2]. Күренекле тел галиме Р.Г. Әхмәтьянов, «кабилә» сүзенең рус телендәге «племя, род, клан» дигән терминнарга туры килүен күрсәтә[3], гомерен татар халкының рухи мирасын өйрәнүгә багышлаган язучы Адлер Тимергалин «кабиләчелек» сүзе астында «провинциализм» дигән мәгънә ятуын билгели[4]. Шулай итеп, Галимҗан Ибраһимов бу сүзләре белән татар халкының бер төбәктә генә яшәп, бер төрле генә булмавын, киресенчә, Евразия киңлекләре буенча сибелгән татарларның милли фольклорын, аның үзенчәлекләрен өйрәнү кирәклеген ассызыклый.

Хәзерге Башкортстанга караган җирләрдә туып үскән күренекле татар фольклорчылары Нигъмәт Хәким *(Кыйгы районының Еланлы авылы)* һәм Нәкый Исәнбәт *(Салават районының Нәсибаш авылы)* биредә яшәүче милләттәшләренең авыз-тел иҗаты үрнәкләрен җыюга сизелерлек өлеш кертсә дә, 1960 еллар уртасына кадәр бу эш системалы рәвештә алып барылмый: фрагментар характерда гына була. Башкортстандагы татар халык иҗаты үрнәкләрен биредә яшәүче башка милләтләр фольклор әсәрләре белән чагыштырма-тарихи планда гыйльми анализлау өчен вакыт, гомумән, килеп җитмәгән була әле.

Башкортстандагы татар фольклор мирасының системалы рәвештә җыела һәм өйрәнелә башлавы 1960 еллар уртасында

---

[1] *Ибраһимов Г.Г.* Әсәрләр: 15 томда. – Т. 8. – Б. 261.

[2] *Шунда ук.* – Б. 261.

[3] *Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I т. (А – Л). – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. – Б. 332.

[4] *Тимергалин Адлер.* Миллият сүзлеге: аңлатмалы сүзлек: өч томда. II т. (Й – Р). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – Б. 28.

фәнгә килгән Риф Мөхәммәтҗанов исеме белән бәйле. Биредә галим турында кыскача белешмә биреп китү дә урынлы булыр.

Риф Мирхәбибулла улы Мөхәммәтҗанов 1939 елның 2 июлендә Башкортстанның Ярмәкәй районы Аксак авылында дөньяга килә. Монда сигезьеллык мәктәптә белем алгач, 1957 елда Иске Турай урта мәктәбен көмеш медаль белән тәмамлый. 1957–1962 елларда Башкорт дәүләт университетының филология факультеты татар-рус бүлегендә укый. 1962–1966 елларда башкорт телендә нәшер ителә торган «Совет Башҡортостаны» республика гәзитендә әдәби хезмәткәр вазифасын башкара, күпсанлы очерклар, мәкаләләр яза[1].

Ләкин балачагыннан ук туган авылы халкыннан мәзәкләр, сөйләкләр, йола үрнәкләре җыеп, аларны аерым дәфтәрчекләргә туплаган Риф Мирхәбибулла улының күңеле фәнгә тартыла[2]. 1966 елда сәләтле белгеч Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасына эшкә чакырыла. Аңа «Татар халык иҗаты», «Татар әдәбияты тарихы» фәннәре, махсус курслар буенча лекцияләр уку, студентларның фәнни эшләренә җитәкчелек итү бурычы йөкләтелә. Яшь галим яңа эшкә күңел биреп тотына һәм тиз арада хезмәттәшләре арасында зур абруй казана[3].

Риф Мөхәммәтҗанов 1967 елдан алып 1990 еллар башына кадәр республиканың татарлар күпләп яшәгән районнарына утызга якын фольклор экспедициясе оештыра, йөзләрчә авылны урап чыга. Әлеге экспедицияләрдә җыелган материалларны саклау һәм өйрәнү өчен, аның тарафыннан үзе эшләгән кафедра каршында фольклор фонды оештырыла.

---

[1] Энциклопедия. Ермекеевский район. Республика Башкортостан: А – Я / Т.И. Аминев (рук.) и др.; редкол.: Т.И. Аминев (отв. ред.) и др. – Уфа: Уфимский полиграфкомбинат, 2010. – С. 117.

[2] Галимнең балачагы турында тулырак аның атадан-ата энесе, күренекле татар драматургы Ризван Хәмиднең истәлекләреннән укып белергә мөмкин. *Кара: Хәмид Р.* Яшьти абый // Тулпар. – 2014. – № 3. – Б. 22–27.

[3] *Бу хакта тулырак: Фазлетдинов И.* Юксыну // Тулпар. – 2009. – № 4. – Б. 30–31.

Биредә тупланган фольклор материаллары тиз арада фәнни әйләнешкә кереп китә. Мәсәлән, 1976–1988, 1993 елларда Казанда дөнья күргән «Татар халык иҗаты» академик басмасының һәр китабында да Р.М. Мөхәммәтҗанов җитәкчелегендәге фольклор экспедицияләре барышында, Башкортстанда яшәүче татарлардан язып алынган халык авыз иҗаты үрнәкләре дә урын ала. Академик басмага Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы каршындагы фольклор фонды материалларыннан меңнән артык – кыска, йөзләп лирик һәм тарихи җыр, йөзләгән йола һәм уен җыры, мәкаль һәм әйтем, табышмак, биш йөзләп балалар фольклоры әсәрләре үрнәкләре, утыз ике риваять, легенда, мифологик хикәят, утызлап тормыш-көнкүреш әкияте, урнаштырыла. Болардан тыш аларда С.Г. Рыбаков тарафыннан бүген Башкортстанга караган районнарда язып алынган 16 кыска җыр, Нәкый Исәнбәт теркәп калдырган меңнәрчә мәкальләр һәм табышмаклар, Х. Ханзафаров кебек халыктан чыккан энтузиаст тикшеренүчеләр язып алган әкиятләр һәм бәетләр урын ала.

Өстәп, шуны да әйтик: Башкортстан татарларының фольклор үрнәкләрен җыюда диалектология белгечләренең (Г.Х. Әхәтов, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б.), фольклорчыларның (Б.Г. Әхмәтшин, С.З. Мөхәммәтнуров һ.б.) да билгеле өлеше бар. Аларның хезмәтләрендә 20 дән артык авыл тарихы, тарихи, топонимик риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр урнаштырыла[1].

1973 елда Риф Мөхәммәтҗанов тарафыннан Башкортстандагы татар фольклорының төбәк үзенчәлекләрен өйрәнүгә

[1] *Ахметшин Б.Г.* Предания Мечетлинского и Янаульского районов Башкирии // Фольклор народов РСФСР: межвузовский научный сборник / отв. ред.: Т.М. Акимова, Л.Г. Бараг. – Уфа, 1977. – С. 112–117, 120; Материалы по татарской диалектологии. Вып. 4. – Казань: ИЯЛИ, 1978. – С. 72–73; Материалы по татарской диалектологии. Вып. 5. – Казань: ИЯЛИ, 1983. – С. 69, 72–74; *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров Юго-Западной Башкирии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – С. 183, 186, 187; Татар диалектологиясеннән практик занятиеләр үткәрү өчен материаллар. Өченче чыгарылыш / төзүчесе Г.Х. Әхәтов. – Уфа, 1980. – Б. 10, 14.

багышланган беренче кандидатлык диссертациясе яклана[1]. «Башкортстан Ык буе татарларының йола поэзиясе» дип аталган фәнни эш күренекле башкорт фольклорчысы, филология фәннәре докторы, профессор Ә.Н. Кирәев (әдәби тәхәллүсе – Кирәй Мәргән) җитәкчелегендә башкарыла. Әлеге диссертация Татарстаннан читтә яшәүче татар халкының, аерым алганда, Башкортстанда яшәүче татарларның милли фольклорын, аның төбәк үзенчәлекләрен, биредә яшәүче башка халыкларның авыз-тел иҗаты белән бәйләнешен чагыштырма планда, комплекслы һәм системалы рәвештә анализлаган беренче фәнни тикшеренү булып тора.

Риф Мирхәбибулла улы алып барган тикшеренүләр соңыннан студентлар өчен дәреслекләр, уку кулланмалары булып формалаша. 1977 елда аның – «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: туй поэзиясе»[2], 1982 елда – «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: календарь поэзия»[3], 1984 елда рус телендә «Специфика татарских фольклорных жанров»[4] дип аталган хезмәтләре үзе эшләгән Башкорт дәүләт университеты нәшриятында дөнья күрә. Алар бүген дә студентлар, халык авыз иҗаты белән кызыксынучылар өчен әһәмиятле чыганаклар булып кала.

Галим Р.М. Мөхәммәтҗановның 1996 елдагы вакытсыз вафатыннан соң, ул башлаган эш укучысы И.К. Фазлетдинов тарафыннан дәвам иттерелә. 2005 елда ул филология фән-

---

[1] *Мухаметзянов Р.М.* Обрядовая поэзия приикских татар Башкирии : дисс. ... канд. филол. наук: 10.01.09. – Уфа, 1973. – 228 с. https://search.rsl.ru/ru/record/01009856164

[2] *Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты. Туй поэзиясе: «Татар халык иҗаты» курсы буенча читтән торып укучы студентлар өчен уку әсбабы / фәнни редакторы Т.Н. Галиуллин. – Уфа, 1977. – 70 б.

[3] *Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты. Календарь поэзия: «Татар халык иҗаты» курсы буенча уку әсбабы. – Уфа, 1982. – 72 б.

[4] *Мухаметзянов Р.М.* Специфика татарских фольклорных жанров: учебное пособие по спецкурсу. – Уфа, 1989. – 84 с.

нәре докторы, профессор Ә.М. Сөләйманов җитәкчелегендә «Башкортстан татарларының топонимик риваятьләре һәм легендалары: тарихи нигезләре һәм идея-эстетик функцияләре»[1] темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Әкияти характерда булмаган халык прозасы жанрларын тикшерүгә багышланган берничә күләмле фәнни хезмәт бастырып чыгара[2].

Шуларның «Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» дип аталганы аерым әһәмияткә ия. Биредә татарлар күпчелекне тәшкил иткән, яисә укмашып яшәгән районнардан җыеп алынган 702 фольклор әсәре – 630 риваять, 23 легенда, 33 мифологик хикәят, 16 сөйләк тексты урнаштырыла. Шуларның 600 дән артыгы фәнни әйләнешкә беренче тапкыр кертелә. Томның нигезен шулай ук автор-төзүче укыткан Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы каршындагы фольклор фондында соңгы елларда тупланган материаллар тәшкил итә.

Күзәтүдән күренгәнчә, Башкортстан татарларының фольклор мирасын системалы рәвештә җыю һәм өйрәнү юнәлешендә соңгы 50 елда шактый зур эшләр башкарылды. Йола иҗатына, әкияти характерда булмаган халык прозасы жанрларына махсус монографик тикшеренүләр багышланды, риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр тупланмасы аерым китап булып дөнья күрде. Башкортстан Республикасы территория-

---

[1] *Фазлутдинов И.К.* Топонимические предания и легенды татар Башкортостана: исторические основы и идейно-эстетические функции: автореф. дис. ... канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. – Казань, 2005. – 26 с.

[2] *Фазлетдинов И.К.* Риваятьтә халык тарихы. Авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдә XVI–XIX гасырлардагы миграция процессларының чагылышы: уку кулланмасы / фәнни редактор Ә.М. Сөләйманов. – Уфа: БДУ нәшр., 2003. – 201 б.; *Фазлетдинов И.К.* Тарих кайтавазы – риваять. XVI–XX гасырлардагы зур тарихи вакыйгаларның Башкортстан татарлары риваятьләрендә чагылышы: уку кулланмасы / җаваплы мөхәррир Ә.М. Сөләйманов. – Уфа: БДУ нәшр., 2007. – 111 б.; Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррир Ә.М. Сөләйманов. – Уфа: Китап, 2018. – 344 б.

сендә яшәүче татарларның халык авыз иҗаты әсәрләрен җыеп бастыру, өйрәнү бүген дә көн кадагындагы мәсьәлә булып саналырга хаклы.

Аерым алганда, Татарстаннан читтә яшәүче татарларның эпик, лирик һәм лиро-эпик фольклор төрләргә караган жанрларның күпчелеге (мәсәлән, әкиятләр, мәзәкләр, афористик иҗат жанрлары, бәетләр, мөнәҗәтләр, халык җырлары, балалар иҗаты) аларның төбәк үзенчәлекләре, үзәк мотивлары, персонажлары, бер үк географик һәм рухи мохиттә яшәүче төрле халыкларның эпик традицияләренең бер-берсенә йогынтысы әлегә кадәр тикшерелмәгән өлкәләр булып кала. Әлеге хезмәт шушы мәсьәләләрне тикшерү өчен кыйммәтле гыйльми чыганак булып хезмәт итәр дип күздә тотабыз.

* * *

Татар фольклорын букбөтен система буларак күзаллап, «Башкортстан татарлары фольклоры» сериясенә кергән китапларны басмага әзерләгәндә, беренче чиратта, тикшеренүчеләр өчен милли фольклорыбызның локаль үзенчәлекләрен чагыштырма планда анализлау мөмкинлеген тудыру максатын куйдык. Шул ук вакытта хезмәт бүгенге катлаулы иҗтимагый-сәяси вазгыятьтә татар халкының бөтенлеген саклау, аны төрле тарафларга тарткалауга-бүлгәләүгә юл куймау өчен дә хезмәт итәчәк.

Китапларны төзегәндә, Башкортстан татарлары арасында таралган барлык фольклор төрләрен һәм жанрларын да колачлау максат итеп куелды. Чыганакларның күпчелеге Башкорт дәүләт университеты татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасының фольклор фондыннан алынды. Биредә әлеге уку йортының филология факультеты татар-рус бүлеге студентлары тарафыннан 1966 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр үткәрелгән җәйге фольклор экспедицияләре вакытында тупланган материаллар саклана. Сериянең китапларына кергән төньяк һәм төньяк-көнчыгыш, үзәк һәм төньяк-көнбатыш, көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнарның һәммәсенә дә шундый фәнни экспедицияләр

оештырылган, аларда җыелган үрнәкләр системалаштырылган. Китапларны төзегәндә, «Татар халык иҗаты» академик басмасында, тел белгечләренең хезмәтләрендә һәм вакытлы матбугатта дөнья күргән фольклор үрнәкләре дә файдаланылды.

«Башкортстан татарлары фольклоры» сериясенә кергән китапларның төзелеш структурасы уртак. Һәр китап биредәге татар авылларының тарихларын тасвирлаган риваятьләр белән ачыла. Бу – бик үзенчәлекле төркем. Чөнки алар «гадәттә, теге яки бу авылның кайдан, кайчан, нинди сәбәпләр аркасында күчеп килүе турында сөйли. Авыл тарихларында төбәккә беренче килеп утырган кешеләр, аерым нәселләр тормышындагы мөһим вакыйгалар турында төрле мәгълүматлар бирелә. Бу ягы белән алар тарихи риваятьләргә якын торалар. Күп әсәрләрдә авыл исеменең килеп чыгышы да аңлатыла. Монысы исә топонимик риваятьләргә хас күренеш»[1]. Безнең карашка, авыл тарихларының шушы үзенчәлеге – бер үк вакытта топонимик та, тарихи да характерга ия булуы – аларны риваятьләр составындагы аерым төркем итеп карарга мөмкинлек бирә. Шуңа да алар һәр китапта башка төр риваятьләрдән аерым, районнар буенча урнаштырылып, тикшерелгән географик ареалда яшәүче татарларның тарихы, тормыш үзенчәлекләре белән укучыны алдан ук таныштыра.

Һәр китапта шуннан соң риваять, легенда, мифологик хикәят, сөйләк, әкият кебек эпик фольклор жанрлары урын ала. Алардан соң лиро-эпик фольклор үрнәкләре – бәетләр һәм мөнәҗәтләр урнаштырыла. Соңыннан бер-бер артлы халык җырлары, афористик жанрлар – мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, сынамышлар, ышанулар, юраулар тезелеп китә. Аннан инде тикшерелгән районнардагы йола иҗатының төрле жанрлары бирелә. Һәр җыентык балалар фольклорына караган әсәрләр белән тәмамлана. Бу Башкортстанның төрле район һәм шәһәрләрендә яшәгән татарларның рухи мирасын тулы һәм системалы итеп күзалларга мөмкинлек бирә.

---

[1] *Гыйләҗетдинов С.М.* Риваятьләр, легендалар һәм мифологик хикәятләр турында // Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – Б. 13.

Хезмәтнең күләме чикләнгәнлектән, бүгенге көндә инде югалган яисә югалып бара торган фольклор төрләренә һәм жанрларына – теге яки бу төбәктә яшәүче татарларның йола иҗатына, риваятьләргә, легендаларга, мифологик хикәятләргә, әкиятләргә, им-томнарга, ышануларга, халык җырларының аерым жанр төрләренә, мәсәлән, шәкерт, рекрут һәм солдат җырларына төзүче тарафыннан аеруча игътибар ителде. Аларның барча текстларын да вариантлары белән бергә китапларга урнаштырырга тырыштык. Мәсәлән, борынгы йола фольклоры әсәрләре тулысы белән сакланмаган очракларда аларның аерым элементларын булса да бастырып чыгаруны максатка ярашлы дип таптык.

Шул ук вакытта бүген дә күпләп иҗат ителгән һәм таралган бәет, мөнәҗәт, мәзәк, сөйләк, лирик җыр, мәкаль, әйтем, табышмак кебек фольклор жанрларының кулыбызда булган барлык үрнәкләре дә хезмәткә кертелмәде. Биредә без җирле халыкның тормыш тәҗрибәсен, тарихи асылын ачкан иң характерлы берничә әсәрне бирү белән генә чикләндек.

Һәр китапта теге яки бу жанр үрнәкләре күп урнаштырылган очракта, аларга эчке тематик классификация ясалды; фольклор үрнәкләре аз булса, мондый бүленеш-классификация эшләү кирәк дип табылмады. Жанрлар эчендә классификация үткәргәндә, төзүче күренекле татар фольклорчылары М.Х. Бакиров һәм Ф.И. Урманче хезмәтләрендә[1] китерелеп, бүгенге фольклористиканың үзәгендә торган фәнни принципларга һәм терминологиягә таянып эш итте.

Шунысын да искәртү мөһим: фольклор үрнәкләре халыкның җирле тел үзенчәлекләрен саклап тәкъдим ителде. Сериянең аерым китапларын төзегәндә, географик принцип нигез итеп алынды. Мондый бүленеш шактый дәрәҗәдә шартлы булса да, гамәли күзлектән караганда һәм татарлар компактлы яши

[1] *Бакиров М.Х.* Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б.; *Бакиров М.Х.* Татарский фольклор: монография. – Казань: Ихлас, 2012. – 399 с.; *Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты / фәнни мөхәррире Х.Ш. Мәхмүтов. – Казан: Мәгариф, 2005. – 383 б.

торган аерым бер территориядә таралган фольклор үрнәкләренә игътибарны юнәлтү җәһәтеннән дә иң уңышлысы дип табылды.

Шуны да әйтик, Уфа өязендә 1718–1727, 1761–1764, 1743–1747, 1781–1782 елларда узган I–IV халык исәбен алу – ревизия материалларында ук биредә татарларның күпләп яшәве күрсәтелә. Алар 5 юлга («дорога») сибелеп утыралар. *Уса юлына* хәзерге Башкортстанның Балтач, Борай, Тәтешле, Краснокама, Калтасы, Мишкә, Кырмыскалы, Яңавыл, өлешчә Бөре һәм Караидел районнарындагы татар авыллары карый; *Казан юлында* Бакалы, Бәләбәй, Благовар, Дүртөйле, Кушнаренко, Илеш, Уфа, өлешчә Бөре һәм Караидел районнарындагы татар авыллары теркәлә; *Ногай юлында* Авыргазы, Бишбүләк, Гафури, Иглин, Стәрлебаш, Стәрлетамак, өлешчә Кырмыскалы районнары, Уфа һәм Стәрлетамак шәһәрләре утыра; *Себер юлына* хәзерге Аскын, Кыйгы, Салават, Учалы, өлешчә Караидел районнары урнаша; *Яңа Мәскәү юлына* Бакалы һәм Бишбүләк районнарының бер өлеше керә[1]. Атап үтелгән хезмәттә татар авылларының тулы исемлеге дә, аларда яшәүче милләттәшләребезнең төгәл саны да китерелә. Кулыбыздагы фольклор материалларын аерым китапларга бүлгәндә, без әлеге тарихи-статистик материалларны да истә тотарга тырыштык.

«Башкортстан татарлары фольклоры» сериясендәге көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш төбәкләренә караган китапка Авыргазы, Әлшәй, Бишбүләк, Миякә, Бүздәк, Туймазы, Шаран, Ярмәкәй районнарында яшәүче татарларның фольклор әсәрләре керде. Алар һәммәсе дә борынгы Казан ханлыгы җирләрендә урнашкан[2]. Тел җәһәтеннән караганда да, бу як татарларының сөйләше татар әдәби теле нормаларыннан бөтенләй аерылмый,

---

[1] Татары Уфимского уезда (материалы переписей населения 1722–1782 гг.): справочное издание / отв. ред. Р.Р. Исхаков. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2020. – С. 19.

[2] История татар Западного Приуралья. Т. I. Кочевники Великой степи в Приуралье. Татарские средневековые государства: коллективная монография. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. – С. 225–250.

диярлек[1]. Гомерен Башкортстан татарларының тарихын һәм тел үзенчәлекләрен тикшерүгә багышлаган галим Р.Г. Сибәгатов фикеренчә, гомумән, Төньяк-Көнбатыш Башкортстан сөйләшләре йөз ел элек тә, ике йөз ел элек тә, өч йөз ел элек тә татарча яңгырашлы булган[2].

Әлеге сериягә кергән чираттагы китап Башкортстанның төньяк һәм төньяк-көнчыгыш төбәкләрен колачлый. Анда Аскын, Караидел, Кыйгы, Краснокама, Мәчетле, Тәтешле, Яңавыл, өлешчә Нуриман, Учалы районнарында яшәүче татарлардан җыелган фольклор материаллары урнаштырылды. Биредә шуны истә тотарга кирәк: Аскын, Караидел, Кыйгы, Нуриман, Мәчетле, Учалы яклары – этник яктан катнаш төбәкләр. Шуның өчен дә «биредә төрле этник традицияләрнең тарихи закончалыкка нигезләнеп, берегеп килүе һәм берберсенә йогынты ясавы»[3] ачык сизелә. Нигезен бары тик татарлар тәшкил иткән, татарлар аеруча күпләп яшәгән авыллардан җыелган фольклор әсәрләре генә китапка кертелде.

Укучы игътибарына тәкъдим ителгән бу китап исә Башкортстанның үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнарында яшәүче татарларның фольклор әсәрләрен үз эченә ала. Болар исәбенә Бакалы, Балтач, Борай, Дүртөйле, Илеш, Чакмагыш кебек Башкортстанның үзәгендә һәм төньяк-көнбатышында урнашкан төбәкләр карый. Бу районнар, тел ягыннан, нигездә, моноэтник – татар халкы күпчелекне тәшкил иткән районнар. Гади генә итеп әйтсәк, бу – татарның нигезе. Аларның этник бөтенлеген саклау, халык иҗаты әсәрләрен саклау һәм пропагандалау аша тарихка игътибарны көчәйтү безнең төп бурычыбыз булып тора.

---

[1] *Рамазанова Д.Б.* Ык ага чик сызыгы булып... // Идел. – 1993. – № 9. – Б. 66.

[2] *Сибәгатов Р.Г.* Башкортстан татарлары. Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 65.

[3] *Ахметшин Б.Г.* Горнозаводской фольклор Башкортостана и Южного Урала / науч. ред. Р.Г. Кузеев. – Уфа: Китап, 2001. – С. 5.

Эш барышында барлыкка килгән кайбер күзәтүләребезне дә бәян итик. Беренчедән, Идел буе татарларындагы кебек үк, Башкортстанда яшәүче татарлар репертуарында соңгы елларда язып алынган архаик дастаннар очрамый диярлек. Моны, беренчедән, Ислам диненең халкыбызга иртә үтеп кереп, тәңречелеккә нигезләнгән мифологик традицияләрне кысрыклап чыгаруы белән аңлатырга мөмкин. Ә алар архаик дастаннарның нигезен тәшкил итә. Икенчедән, бу татар халкында борын-борыннан китап культурасының, язма әдәбиятның киң үсеш алуы белән дә бәйле. Нәтиҗәдә, фольклор халыкның эстетик, рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә торган бердәнбер чыганак булудан туктый, күләмле әсәрләр язма рәвештә, әдәби кануннар буенча иҗат ителә, төрле вариантларда язып тарала башлый. Архаик дастаннардан аермалы буларак, стадиаль яктан соңгырак чор эпосы булып санала торган мәхәббәт дастаннары, аларның билгеле сюжетка вариантлары, эпик җыр үрнәкләре һ.б. исә Башкортстан татарлары авызыннан шактый күп язып алынган. «Йосыф һәм Зөләйха», «Таһир һәм Зөһрә», «Ләйлә һәм Мәҗнүн» кебек фольклор һәм язма әдәбият арасында торган китаби дастаннарның вариантлары тикшерелгән ареалда күпләп очраса да, алар, күләмнәре зурлыгы аркасында, әлеге китапка кертелмәде. Киләчәктә мондый төр дастаннарга аерым китап багышлау күздә тотыла.

Мифологик кануннарга корылган архаик дастаннар табылмаса да, Башкортстан татарлары репертуарында иң борынгы чорларны чагылдырган, шул чорларда бабаларыбыз аңындагы дөнья моделен ачып салган сюжет-мотивлар шактый. Мәсәлән, Аскын, Караидел, Нуриман, Илеш якларында алыплар – гадәти кешеләрдән алда яшәгән зур гәүдәле адәми затлар турындагы риваятьләр гаять күп таралган.

Башкортстанда яшәүче милләттәшләребез репертуарында, Казан татарлары фольклорыннан аермалы буларак, күршеләренең малын, җирен тартып алу өчен, күчмә кабиләләр арасында барган феодаль сугышлар – карымта-барымта яулары турындагы риваятьләр дә зур урын тота. Моңа кадәр әлеге төр

әсәрләр мөстәкыйль тематик төркем буларак бары тик башкорт риваятьләре составында гына аерымлана иде. Соңгы еллардагы тикшеренүләребез карымта-барымта яулары белән бәйле мотивларның башкорт фольклорында гына түгел, Башкортстан татарларының риваятьләрендә дә мөһим урын тотуын ачыклады һәм аларны мөстәкыйль тематик цикл итеп карарга мөмкинлек бирде[1]. Безнең фикеребезчә, биредә «татар халкының бер өлешенең хәзерге Башкортстан җирләрендә борын-борыннан яшәп, бу сугышларда турыдан-туры катнашкан булуы турында фикер йөртергә дә урын бар»[2]. Архаик мотивларның күп очравы үзе үк татарларның бу җирләрдә гасырлар дәвамында яшәвен исбатлый.

Янә шуңа да игътибар итү кирәк: китапларга кергән материалларның зур өлеше 1962–1991 елларда, ягъни совет идеологиясе хакимлек иткән чорда язып алынган. Шуңа күрә аерым үрнәкләрдә коммунистик идеология, сыйнфый караш шаукымы, дингә һәм муллаларга карата ифрат тискәре караш та сизелеп кала. Моны аңлап кабул итү сорала. Чөнки фольклор әсәре үзен тудырган, үзе яшәгән чор чынбарлыгын чагылдырмыйча яши алмый. Шуңа күрә дә Совет чорында язып алынган әсәрләрдә мондый, бүген инде бик иске булып тоелган карашларның саклануы – табигый күренеш.

Хәзерге Башкортстан территорияләрендә борын-борыннан, әле Алтын Урда чорыннан ук һәм аннан да иртәрәк, яшәп көн күрүче татарлардан язып алынган авыз иҗатында бердәм татар милләтенә хас яшәү рәвешен, холкын, сөйләмнәрендәге

---

[1] *Фазлетдинов И.К.* Тарих кайтавазы – риваять: уку кулланмасы / җаваплы мөхәррир Ә.М. Сөләйманов. – Уфа: БДУ нәшрияты, 2007. – Б. 8–15; Фазлутдинов И.К. Топонимические предания и легенды татар Башкортостана: исторические основы и идейно-эстетические функции: автореф. дис. ... канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. – Казань, 2005. – С. 20.

[2] Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррир Ә.М. Сөләйманов. – Уфа: Китап, 2018. – Б. 31.

саф татарча үзенчәлекле аһәңне, гомумән, милләтебез кичергән әрнү-борчуларны, шатлык-куанычларны төсмерләү кыен түгел. Татар халкын милли асылына кайтаруда, һичшиксез, мөһим кыйммәтләрдән булган рухи энҗе-мәрҗәннәр алар.

**Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты, доцент;*
*Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе*
*һәм мәдәнияте кафедрасы доценты (Уфа);*
*Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге*
*фәнни хезмәткәре (Казан)*

# АВЫЛ ТАРИХЛАРЫ

## БАКАЛЫ РАЙОНЫ

### 1. Камышлы авылы

1870 елның җәендә Газиз исемле кеше үз гаиләсе белән безнең якларга килеп утыра. Милләте буенча ул татар була. Газиз, өй салганчы дип, каенлыкта куыш кора һәм шунда яши. Каенлыкның өске ягында кеше йөрмәслек сазлык, баткак була һәм күл җәелеп ята. Аның тирә-ягын камышлар уратып алган була. Шуңа да авыл Камышлы дип атала башлый. Тиздән монда Кәрим, Габделгали, Хәбир, Биктаһир, Миңлегали, Корбангали, Имаметдин, Шәрифулла исемле кешеләр килеп утыра. Авылда хәзер шуларның нәселләре яши.

*1998 елда Бакалы районы Камышлы мәктәбе музее материалларыннан БДУ студенты Лилия Гафарова күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 6*

### 2. Мостафа авылы

Мостафа авылы моннан 400 ел тирәсе элек, Пальчиководан Дияшкә бара торган җирдә барлыкка килә. Хәзер ул урынны Иске авыл чокыры дип атыйлар. «Чокыр» диелсә дә, ул җирләрдә чокыр түгел, ә уйсулык. Ул урыннарда башкортларның куе шомыртлыгы була.

Аннан соң кешеләр, авылның чишмәләргә бай булган әлеге урынына – Хөсәен Салих чишмәсенең көньягына килеп төпләнә башлаганнар. Авыл исеменең килеп чыгышы турында ике төрле фикер бар. Берәүләр, иң беренче булып, монда Казан ягыннан килгән Мостафа исемле кеше яши башлаган, диләр.

Авылның исеме дә шуннан килеп чыккан, имеш. Икенчеләр, авылның төньягында башкортлар яшәп, монда беренче булып Мостафа исемле башкорт утырган, диләр. Кайсысы дөрес булса да, авылга нигез салучының исеме Мостафа булуы хак.

Күченеп утырган татарлар авылның югары очында яшәсәләр дә, аларның чәчүлек җирләре түбән очта була, ә башкортлар түбән очта торсалар да, җирләре югары очта була. Шуннан волостьтан землемер килеп: «Сез болай йөрмәгез, үзегезнең чәчәсе ягыгызга күченегез», – ди. Моннан соң башкортлар – югары очка, татарлар түбән очка күченә.

*1997 елда Бакалы районы Мостафа авылында*
*Мөнирҗан Йосыпов (1924-1993) истәлекләреннән БДУ студенты*
*Светлана Медведева күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 7*

БАЛТАЧ РАЙОНЫ

**3. Әрдәгеш авылы**

Бу авылга 1926 елда нигез салынган, диләр. Әльягеш елгасы буена урнашкач, авылга иң башта «Әльягеш» дигән исем бирергә булганнар. Ләкин Аскын районында шул ук елга буендагы бер авыл тагын Әльягеш дип атала икән. Шуңа күрә авылга ,Әльягешкә охшатып, Әрдәгеш дип исем биргәннәр.

*1997 елда Балтач районы Әхмәт авылында*
*Рәис Сөләймановтан (1934 елгы) БДУ студенты*
*Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 8*

**4. Балтач авылы**
*(1 нче вариант)*

Бик элек, хәзер Кушнарен районына кергән Топорино авылыннан Топорин фамилияле урыс кешесе әле Балтач авылы урнашкан җирләргә килеп утыра. Аның балалары, якыннары да шушы җирләргә нигез коралар һәм, шул рәвешле, яңа авыл барлыкка килә. Ә авылның исеме алпавыт Топорин фамилиясенә бәйле. Якын-тирәдә яшәүче татарлар Топорин фамилиясен татарчага тәрҗемә итеп, авылны Балта дип атый башлыйлар.

Тора-бара бу сүзгә «ч» хәрефе өстәлә, һәм авыл Балтач дип исемләнә башлый.

*1997 елда Балтач районы Балтач авылында Нира Әхмәтшинадан БДУ студенты Раушания Әхмәтшина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 9*

### 5. Балтач авылы

*(2 нче вариант)*

XIX гасыр башында әлеге Татарстан якларыннан безнең төбәккә Балтач исемле карт килеп чыга. Ул биредә төпләнеп кала. Аның туган төяге – әлеге Татарстанның Балтач районы җирләре була. Балтач карт үзе нигез салган авылны улы Колый исеме белән атарга тели. Улының исемен мәңгеләштерәсе килгәндер, күрәсең. Ләкин авыл халкына бу атама ошамый һәм ул авылны нигез салучысы исеме белән, Балтач дип атый.

*1997 елда Балтач районы Әхмәт авылында Рәис Сөләймановтан (1934 елгы) БДУ студенты Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 10*

### 6. Бигелде авылы

Туган авылыбыз урнашкан җиргә иң беренче булып моннан 17-18 чакрым ераклыктагы Арбаш авылыннан Бигелде исемле бабай күчеп утыра. Бу хәл 1636 елда була. Әкренләп аның янына башка кешеләр дә килеп төпләнә. Авылга нигез салучысының исеме бирелә.

*1998 елда Балтач районы Бигелде мәктәп музее материалларыннан БДУ студенты Фәнүз Фәхретдинов күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 11*

### 7. Итәвәш авылы

Күпмедер вакыт үткәч, Тушкыр авылында яшәүчеләргә тагын җир җитми башлый һәм халыкның күпмедер өлеше янә күчеп китәргә мәҗбүр була. Җир бүлүче яңа урыннарны күрсәтә дә: «Это ваш», – ди. Ул вакытта урыс телен авылда беркем дә белмәгән. Кешеләр моны «Итәвәш» дип ишетәләр һәм авылга шул исемне бирәләр.

*1997 елда Балтач районы Әхмәт авылында Рәис Сөләймановтан (1934 елгы) БДУ студенты Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 12*

### 8. Карыш авылы

Безнең авылга хәзер 350–400 еллар чамасы. Бу якларга иң беренче булып Тукай белән Байбирденең нәсел-ырулары килеп урнаша. Алар өйләр салалар, урман кисеп, төпләп, чәчүлек җир булдыралар, аны эшкәртәләр. Читтән, Алтай якларыннан, якташлары килә торалар һәм авыл зурая. Шуннан ул икегә – Югары һәм Түбән Карыш авылларына бүленә. Тукай картның нәсел-ыруы Түбән Карыш авылын нигезләсә, Байбирденекеләр Югары Карышка нигез сала.

*1998 елда Балтач районы Карыш авылында*
*укытучы Наил Хаҗиевтан (1940 елгы) БДУ студенты*
*Фәнүзә Садыйкова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 13*

### 9. Мата авылы

Мата – райондагы иң борынгы авыл. Аңа гарәпләр нигез салган дип тә сөйлиләр, чөнки «мата» сүзе гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә «саф сулы чишмә» дигәнне аңлата. Дөресме, дөрес түгелме икәнлеген беркем дә белми.

*1997 елда Балтач районы Әхмәт авылында*
*Рәис Сөләймановтан (1934 елгы) БДУ студенты*
*Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 14*

### 10. Сандугач авылы

Элек җир бүлүчеләр урыс милләтеннән генә булганнар, татарча бер авыз сүз дә белмәгәннәр. Шулай берчак җир бүлүче бу якларга килгән татарларга булачак авыл өчен урын күрсәтеп йөри. Кешеләр, авылга нинди исем бирергә, дип бәхәсләшә башлыйлар. Шулчак җир бүлүче күктәге сандугачларны күреп ала да, халыктан: «Как по-вашему будет соловей?»– дип сорый. Татарларның берсе ипи-тозлык кына урысча белгән була. Ул: «Сандугач!» – дип, кычкырып җибәрә. Кешеләр аны авылның исемен әйтә икән, дип уйлыйлар. Барысына да Сандугач исеме ошый һәм авылны шулай атый башлыйлар.

*1997 елда Балтач районы Әхмәт авылында*
*Рәис Сөләймановтан (1934 елгы) БДУ студенты*
*Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 15*

## 11. Тимер җире

Бу – безнең яктагы бер авылның исеме. Беренче булып шул урынга Тимер исемле кеше үз гаиләсе белән килеп урынлашкан. Балалары һәм оныклары тиздән биредә бәләкәй генә авыл хасил иткәннәр һәм аны «Тимер җире» дип атаганнар. Авыл зурайгач, аңа Тимер дип исем кушканнар.

*1997 елда Балтач районы Тушкыр авылында БДУ студенты Илдар Хөснуллин язып алган. Информаторы күрсәтелмәгән. – Фазлетдинов, 2018, № 16*

## 12. Тучыбай (Туйчыбай) авылы

Туйчыбай авылына типтәрләр Казан ягыннан – Кама буенча килгәннәр. Башкортлардан рөхсәт алганнар утырырга. Типтәрләргә җир бирмәгәннәр, сатып алганнар. Төп кәсеп игенчелек һәм малчылык белән шөгыльләнгән. Чабата ясап көн иткәннәр. Сәйтәктә базар булган. Мең сигез йөз туксан бишенче елны җитмеш ике хуҗалык Шавйады авылына күчеп киткән.

Туйчыбай бик бай кеше булган. Туй котлап, кызларына бөтен җир-суын биргән. Шуңа күрә авыл Туйчыбай дип аталган. Иңчекүл – җир исеме, әнә шул Иңче исемле кызына бүләк иткән җирне. Шул картның әллә егерме ике баласы булган, ди, шулай балаларын туйлап биргән, имеш, туй ясаган. Бу авыл урынында урман булган, елгасы бар Сүләңгеч исемле.

*1977 елда Балтач районы Тучыбай авылында Тимерхаза Карамовтан (1921 елгы) Т. Хәйретдинова язып алган. – МПТД, V. – С. 69; ТХИ РЛ, № 213; Фазлетдинов, 2018, № 17*

## 13. Тушкыр авылы

1680 нче елларда Казан якларыннан килгән бабаларыбыз Мәнәгәз елгасы буендагы урман буена урнашканнар. Ул урманны кисеп, чәчүлек җир ясаганнар. Басуны, калку булганлыгы өчен, «Түш өсте кебек кыр» дип атаганнар. Тиздән бу атама кыскарып, Тушкырга әйләнгән һәм авыл исеме дә булып киткән.

*1997 елда Балтач районы Тушкыр авылында БДУ студенты Илдар Хөснулин язып алган. Информаторы күрсәтелмәгән. – Фазлетдинов, 2018, № 18*

## 14. Штәнде авылы

Әрдәгешкә нигез салучылар кебек үк, Штәнде авылы кешеләре дә, Тушкыр авылында җир җитмәгәч, күченеп китәргә мәҗбүр булганнар. Алар Штәнде елгасы буена килеп урнашалар. Авылга да шул елга исемен бирәләр. Штәнде елгасы язын ишелеп-ишелеп аккан була. Штәнде атамасы шул «ишелде» дигән сүздән килеп чыккан да инде.

*1997 елда Балтач районы Әхмәт авылынд*
*Рәис Сөләймановтан (1934 елгы) БДУ студенты*
*Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 19*

## 15. Яңа Янбай авылы

Монда төрле җирдән күчеп килгән кешеләр яши. Иске Янбайдан Кашаф, Борхан картлар күчеп китәләр. Мәзин карт башта Яңа Янбайга, аннары Калатауга күчә. Калатауда үлә. 1936 елда Гәрәйшә карт, Нәфкат Кәшфуллиннар күчәләр. Әлеге вакытта ул исән, Яңа Янбайда яши.

*2016 елда Балтач районы Иске Янбай авыл китапханәсе*
*материалларыннан БДУ студенты Эльнара Исхакова-Фаткуллина*
*күчереп алган. – Исхакова-Фаткуллина, 2016. – 61 б.;*
*Фазлетдинов, 2018, № 20*

БОРАЙ РАЙОНЫ

## 16. Бадрак авылы

Кайсы әйтә, биш йөз ел дип, Бадрак тарихы языла килгән, тик ул югалган. Килүчеләр алар дүрт агай-эне булганнар. Иң зурысы Бадракка утырган, берсе утырган Бикмәткә, Иске Бикмәт диләр, берсе – Каенлыкка, берсе – Чалкакка. Ул пирвай килеп утырган Сикиязга, саз бар шундый. Шалаш корып яткан, килгәч тә. Аннан соң суның бер ягына Силасау, бер ягына Бадрак утырган. Бадрак бабайның төп килеп утырган урыны Гыйндуллин Фәтхелислам урыны, диләр. Мин белгәндә, җир юк иде, түлке флант бирелгән. Җирне сатып алганнар, Рәвиз чыккач, боларны куа башлаганнар. Болар әйткәннәр:

– Соң без шул гомердән тордык, безгә җир бир, – дигәннәр.

Шуннан алар күчеп утырганнар. Аларның күчеп утыруына ундүртенче елны кырык биш ел диләр иде, хәзер йөз дә сигез ел була. Типтәрләр төрле җирдән килгәннәр, иске закуннан качып килгән кешеләр булган.

Бадрак бабай шалашта утырганда, судан бер йомычка агып килә. Бадрак бабай менеп китсә, бер кеше чолок эшләп утырган. Шуннан Бадрак аңа китәргә кушкан.

– Мин бит кысык итмәем, берүзем генә, – дигән теге кеше. Шуннан Берләч булып киткән.

Үләй авылы турында болай ишеткәнем бар. Болар ике агай-эне боярда хезмәт итеп торган. Бояр әйткән боларга: сез бик күп хезмәт иттегез, давай чукыныгыз, өйләнегез, хатын алып бирәм, җир бирәм, дигән. Боларның фамилиясе Үләйдер, шулай хисап итәм мин. Берсе риза булган чукынырга. Бирскиның бу ягында Үләй дигән урыс авылы бар, монысы да Үләй, тегесе дә Үләй, икесе дә бертуган булган. Берсе чукынырга теләмәенчә кача. Шуннан килеп керә монда. Бадрак бабасына сөйләп бирә:

– Шулай-шулай, мине чукындырырга иттеләр, мин качтым, – ди. Моны жәллиләр, җир ярып бирә, үзенең кызын бирә Бадрак бабасы. Аннан соң абхут чыга ул, зимләмир абхут ясап йөри. Үләй үзе урысча белә икән. Моны ишеткәч, китә ул боярга:

– Давай, мин җирне абхут итәм, зимләмир белән җибәр.

Зимләмир белән абхут итә бу. Яңа Бикмәт кырыннан, Берләч кырыннан, Калмык кырыннан, Силасау кырыннан, аннан урманга кереп китә, аннан Крищонка кырыннан, Әреләнбәк кырыннан, Биштим кырыннан Бикмәткә кадәр әйләндереп ала абхут. Эш бетә, падписать итәләр. Баралар боярга, күрсәтәләр.

– Ә Бадрак кая калды? – дигән бояр.

– Эчтә калды.

– Бадракны читтә калдырса – Үләйнеке була җир, эчтә калдыргач – Бадракныкы була җир, – ди бояр. Аннан Үләй, җир бүлеп биреп, яңадан килешеп киткәннәр. Әле дә безне «Үлейски абхут» диләр.

*Борай районы Олы Бадрак авылында Зыя Галәветдиновтан (81 яшь) һәм Гыйзетдин Шакировтан (73 яшь) Т. Хәйретдинова язып алган. – МПТД, V, 198. – С. 72, 74; ТХИ РЛ, № 215; Фазлетдинов, 2018, № 24*

## 17. Бакалы авылы

Бу авыл элек Иске Имән Күпер дип аталган. Аңа нигез салучылар – Караидел районы Янсәет авылыннан күчеп килгән җиде нәселнең берсе. Ни сәбәптәндер, алар сазлык өстенә төпләнергә булганнар, ныклап җирне эшкәрткәннәр. Авыл читендә генә суы пычрак ярымсазлык-ярымкүл урнашкан булган. Анда һәрчак бакалар җырлаган. Шуңа да авыл Бакалы дип атала башлаган.

*1998 елда Борай районы Бакалы авылында*
*БДУ студенты Гөлназ Биктиева язып алган.*
*Информаторы күрсәтелмәгән. – Фазлетдинов, 2018, № 25*

## 18. Бигәнәй авылы

Авылыбыз 1600 елларда барлыкка килгән булырга тиеш. Ул үзе ике өлешкә бүленгән. Беренче өлешен Бигәнәй дип йөртәләр, ә икенче өлешен – Бишкук дип.

Бигәнәй ягы иң элек Иске Кәңгилде дип аталган. Анда яшәүче халык бик усал булган һәм килгән һәрбер кешене куып кайтарганнар. Бик оятсыз булганнарын сүз белән генә куып калмыйча, хәтта кыйнап та куганнар. Авылга хуҗа кеше татар телен бик яхшы белеп бетермәгән. Ул «кунакларны» куганда: «Бей!», «Гоняй!» – дип өндәгән. Аның тавышын күрше авыл халкы ишетеп торган, чөнки авыллар арасы ерак түгел, 2 чакрым тирәсе генә. Үзара сөйләшә-сөйләшә, «Иске Кәңгилде халкы» дип әйтү сирәгәйгән, ешрак аларны «Бейгоняйлар» дип кенә йөрткәннәр. Тора-бара бу яңы исемне тагын да гадиләштергәннәр, әйтергә җиңеләйткәннәр һәм, нәтиҗәдә, «Бигәнәйләр» сүзе килеп чыккан. Шуннан бирле безнең авыл халкын «бигәнәйләр» дип йөртәләр, авылның үзенә дә Бигәнәй исеме бирелгән.

Ә Бишкук ягының тарихы болай: аның барлыкка килүен якынча 1400–1500 еллар белән бәйлиләр.

Бигәнәй авылыннан ун чакрым ераклыкта Колай авылы урнашкан. Колайда биш уллы бер бай торган. Гаиләләре бик дәрәҗәле булмаган, авыл халкы белән дә тату яшәмәгәннәр.

Шуңа үчләшеп, бай халыкка зыян ясарга гына тырышкан. Чираттагы ниндидер начар эшләре бу байны биш улы белән авылдан чыгып качарга мәҗбүр иткән, дөресрәге, аларны куганнар. Куганда, аларга төбәп, биш ук атканнар.

Беркем дә яшәмәгән, таулы-чокырлы җиргә килеп урнашканнар болар. Урлашып яшәргә күнеккән кешеләр өчен бик уңайлы урын булган, авылның тирә ягы тау-чокырларга бик бай булган. Колайда яшәүче халык, биш ук атуларын истә тотып, «биш» һәм «ук» сүзләрен бергә кушып, аларны «бишкуклар» дип йөртә башлаган.

*2016 елда Борай районы Бигәнәй авылында*
*Гафурьян Гарифьяновтан (1933 елгы)*
*БДУ студенты Рәмилә Фаттахова язып алган*

### 19. Борай авылы

Борай карт, Мәккәгә хаҗга барган бер кешегә ияреп, безнең якларга килгән. Аңарчы ул Мәккәдән 50–60 чакрым ераклыктагы Бурайда шәһәрендә яшәгән булган. Безгә килгәч, Борай карт иң башта Танып елгасы янындагы бер күл янында яши башлый. Ул күл әле дә Борай күле дип атала. Ләкин язын, ташу вакытында, карт яшәгән урынны су баса һәм ул әлеге Борай авылы урнашкан җиргә күчеп утырырга мәҗбүр була. Авылга шулай нигез салына.

*1998 елда Борай районы Борай урта мәктәбе музеенда*
*Шартдин Әбраровның 1921 елда язып калдырган истәлекләреннән*
*БДУ студенты Гөлназ Биктиева күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 26*

### 20. Йомакай авылы

Моннан 200 ел элек агалы-энеле башкортлар Йомакай белән Йомагуҗа, яхшы җирләр эзләп, Танып буена килеп чыгалар. Аларга хәзерге Йомакай авылы кырындагы урыннар бик ошый. Биек-биек матур таулары, уйсу матур үзәннәре, тынып кына аккан Танып суы бу ике туганны сихерләп, үзенә тарта. Алар шушында төпләнеп калырга уйлыйлар һәм авыл төземәкче булалар.

Ләкин, авылга исем табу мәсьәләсе килеп чыккач, ике туган арасында бәхәс куба. Һәркайсысы авылга үз исемен бирергә тели.

Ә соңрак алар әмәлен табалар: тау астыннан агып чыккан салкын чишмә буенда төн кунарга килешәләр. Кем беренче булып уяна һәм туганын уята, авылга шуның исемен бирергә булалар.

Йомакай иртә тора. Чишмәдән су алып кайтып, чәй кайната һәм туганын уята.

– Тор, Йомагужа, авылга Йомакай дип исем кушабыз! – ди.

Шулай итеп, авыл Йомакай дип атала башлый. Йомакайның өч баласы була. Өч баласыннан сигез буынга җитәләр. Әле тугызынчы буын – мин.

*1977 елда Борай районы Кузбай авылында тарих укытучысы Гөлйөзем Хәмәтҗан кызы Аитовадан (1925 елгы) БДУ студентлары язып алган. Ул бирегә килеп төпләнгәнче, Йомакай авылында 4 ай укытып киткән булган. Бу риваятьне дә шундагы бер бабайдан сөйләткән*

### 21. Кәшкәләү авылы

Кәшкәләү авылына Караидел районы Янсәет авылыннан күчеп килүчеләр нигез салган. Алар җиде гаилә булган – Бускын, Сәгыйть, Мөстәкәй, Нөрәй, Тычкан, Юлдаш һәм Биктимер нәселләре.

Кәшкәләү авылының исеме Кушкул атамасыннан алынган. Авыл хәзерге Кәшкәләү белән Яңа Карагыш авыллары арасындагы Күшимән үренең уң як кулына утырган булган. Анда ике кул булганлыктан, авылга Кушкул исеме биргәннәр. Ләкин җир үлчәүче урыс, хаталанып, Кушкул сүзен Кушкулево дип, бозып язган. Соңыннан бу исем урысча Кашкалево, татарча Кәшкәләү булып киткән.

Еллар үткән, авыл зурайган, ләкин Кәшкәләү халкы өчен бу урыннар тормыш көтүгә уңайсызланган, җир җитми башлаган. Шулай итеп, авыл иске урыннан өч чакрым читкә, хәзерге урынына күчеп утырган.

*1998 елда Борай районы Кәшкәләү авылында Миңнемөхәммәт Ишмөхәммәтовтан БДУ студенты Гөлназ Биктиева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 27*

## 22. Кәшкәләү, Бакалы, Шады, Даутлар, Карагыш авыллары

Моннан бик күп еллар элек, авылның хәзерге урынында сазлыклы урман үскән булган. Авыл куш күл буена урнашкан була. Шуңа да Караидел районы Янсәет авылыннан бу җиргә беренче булып күчеп килгән 7 гаилә яңа авылга Кушкул исемен кушалар. Җиде гаилә башта бергә яшәсәләр дә, соңыннан якын-тирәгә таралып утыралар. Шуларның берсе Барыч күле янында каен тузыннан куыш ясап көн итә башлый. Шулай итеп, Тузлыкуш авылы барлыкка килә. Икенчесе Иске Имән күпергә – хәзерге Бакалы авылына, өченчесе – Имән авылга, дүртенчесе – Карагышка, бишенчесе – Даутларга, алтынчысы Шадыга утыра, җиденчесе Кәшкәләүдә кала.

Бу нәселнең Сөхрәттелхаким атадан таралганлыгы билгеле. Аның 11 улы – Сәхипкоръән, Мәүлемхуҗа, Ядебәки, Кузинби, Рушинби, Майкеби, Әлкаби, Әлхакби, Кыйсиянби, Карагузби һәм Котлыби була. Кәшкәләү, Бакалы, Даутлар, Карагыш, Шады авылларына нигез салучылар – Котлыбинең уллары Булат, Байтирәк, Янсәет һәм Акбирде. Булаттан тагын өч улы – Янбакты, Бикбай, Дүсмәт туган, дигән мәгълүматлар бар.

Кәшкәләү авылына XVII йөз урталарында нигез салына. Авылның уртасында куш күл урнашканлыктан, аңа Кушкул исеме бирелә. Җир үлчәүче урыслар Кушкул сүзен Кушкулево дип бозып язганнар. Соңыннан бу исем русча Кашколево, татарча Кәшкәләү булып киткән. Бередә 7 нәсел халык яши: Бускын, Сәгыйть, Мөстәкәй, Нөрәй, Тычкан, Юлдаш һәм Биктимер нәселләре. Аларның иң борынгысы һәм иң ишлесе булып Бускын нәселе исәпләнә.

*1998 елда Борай районы Кәшкәләү авылында*
*Наилә Шәяхмәтовадан (1916 елгы) БДУ студенты*
*Айсылу Муллакаева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 28*

## 23. Кодаш авылы

Гарифулла бабай сөйләве буенча, Нарат авыл чокыры кырына Кузбай авылыннан Кодаш исемле бер бабай килеп утырган. Нарат чокырында агач үскән, зират һәм чишмә булган. Монда әкренләп

авыл барлыкка килә башлаган. Кодаш халкы «башкортлар» дип атала, алар ике төргә бүленә: Югары очка һәм Түбән очка. Югары очлар – типтәрләр, ә калган очлар башкортлар дип аталган. Башкортлар типтәрләрне «пропутниклар» дип тә йөрткәннәр.

Бу вакытта Казан өязендә яшәгән татар халкын чукындырганнар. Шуңа күрә Казан ягында яшәгән халыкның күбесе безнең җирләргә күчеп килгән. Аларга басудан җир бүлеп биргәннәр. Аларны да «пропутниклар» дигәннәр. 1917 елга кадәр авылда ике төрле халык булганлыктан, алар арасында сугышлар да чыккалаган. Алар бигрәк тә бәйрәм көннәрендә сугышканнар.

1917 елгы революциядән соң типтәрләр белән башкортларны берләштерергә, татулаштырырга тырышканнар. Ләкин башта бу халыкларны дуслаштыру җиңел булмаган. Җир өчен сугышлар барыбер дәвам иткән.

*1977 елда Борай районы Кодаш авылында*
*Габдрахман Фәйзрахман улы Фәйзрахмановтан (1900 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 24. Кузбай авылы

Кузбай авылы бик матур урынга утырган. Аның яныннан гына тирә-якка дан тоткан Танып елгасы ага.

Моннан бик күп еллар элек бу җирләргә иң беренче булып Кугаш авылыннан Кузбай дигән карт үзенең семьясы белән килеп утырган. Шуннан соң бу авылны картның исеме белән – Кузбай дип йөртә башлаганнар. Кеше яшәү өчен уңайлы урынга урнашканга күрә, авыл үскәннән-үсә барган. Аның бер ягында урман, икенче ягында Танып елгасы ага. Кешеләр аны «Тынып агучы» елга дип йөрткәннәр. Шуннан Танып исеме килеп чыккан.

Авылга ике милләт кешеләре килеп утырганнар: башкортлар һәм татарлар. Татарларны «типтәрләр» дип йөрткәннәр. Алар башта дус яшәгәннәр. Ләкин соңрак җир өчен талаш чыккан. Авыл икегә бүленгән.

Кузбай авылында 1918 елга кадәр укыту эшләре ике мәчеттә гарәп телендә алып барылган, шуңа авылны ике мәхәлләгә бүлеп йөрткәннәр.

*1977 елда Борай районы Кузбай авылында Муллаян*
*Нәби улы Нәбиевтан (1908 елгы) БДУ студентлары язып алган*

## 25. Сәет-Көрҗә, Ает авыллары

Моннан күп еллар элек Сәет-Көрҗә, Ает авыллары урнашкан урында куе урман булган. Агачлары гаскәр кебек рәт-рәт тезелешеп торганнар. Урман эченнән йөрерлек юл булмаган.

Ямьле Күгәрчен авылында бер кешенең өч улы яшәгән. Алар Көрҗә, Сәет, Ает исемле булганнар. Олы улы Көрҗә әлеге Көрҗә авылы урнашкан җиргә күчеп килгән. Агачларын төпләп, җир булдырган. Җирне эшкәртеп, чәчкән-урган.

Икенче улы Сәет Таңатар авылыннан урап, Сәет авылы утырган урынга килеп урнашкан. Сәет тә үзенчә көн күрә башлаган. Бер көнне ул этләр өргән тавыш ишеткән. Ләкин алар янына бара алмаган. Чөнки юлны урман һәм елга бүлгән була. Сәет бик зур кыенлык белән бу урынга барган. Караса, монда олы абыйсы Көрҗә урнашкан булган икән. Шуннан алар урманны кисеп, елга аша күпер ясаганнар, шуннан ат белән чыгып йөргәннәр. Менә шулай итеп, туганнар аралашып яши башлаганнар.

Өченче улы Ает шулай ук озак йөри торгач, үзенә ошаган урын тапкан һәм шунда килеп утырган. Яңа авыл Ает дип атала башлаган.

Шулай итеп, бер байның өч җимеше өч авылга нигез салган. Авыллар көннән-көн матурланган, үскән. Авылда баш кешене мулла дип йөрткәннәр. Беренче бай Ситдыйк мулла булган. Аңардан соң мулла булып Мөбарәк карт калган.

*1998 елда Борай районы Сәет-Көрҗә авылында БДУ студенты Илсөяр Галиева язып алган. Информаторы күрсәтелмәгән. – Фазлетдинов, 2018, № 28*

## 26. Үтәгән авылы

Үтәгән авылы урнашкан урынга, картлар сөйләве буенча, беренче булып Үтәгән дигән ыру башлыгы килеп урнаша. Бу якынча 1540-1560 елларда була.

Иван Грозный, Казан ханлыгын басып алгач, татарларны көчләп чукындыра башлый. Үтәгән ыруы, чукындырудан качып, бу якларга килеп чыга һәм монда урнашып кала. Аларның элекке торган җирләре якынча хәзерге Чакмагыш районында була,

чөнки Мәүлет бабай Мәхмүтов әтиләренең революциягә кадәр Чакмагышка барып, Агыйдел буендагы җирләрен сатып җибәргәнен хәтерли.

Революциягә кадәр Үтәгән авылында 140 хуҗалык булган. Беренче Бөтендөнья сугышы, аннан соңгы Гражданнар сугышы авылга үзенең канлы тамгасын салып калдырган. Үтәгәннең күп кенә егетләре бу канлы сугышларда башларын салганнар. Авыл берничә тапкыр кулдан-кулга күчкән. Аклар кулыннан авыл халкы күп кыенлыклар күргән.

Тыныч тормыш урнашканчы, күп сулар ага әле. 1921 елгы корылык, ачлык Үтәгән авылы тарихында да кара эз калдыра. Шуннан соң гына тыныч, матур тормыш башлана. Ләкин ул да озакка бармый, чөнки Бөек Ватан сугышы башлана. Үтәгәннең бик күп ир арысланнары Москва-Берлин юлында ятып кала.

*1977 елда Борай районы Үтәгән авылында*
*Сабира Миңнегаһир кызы Вәлиевадан (1903 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## ДҮРТӨЙЛЕ РАЙОНЫ

### 27. Дүртөйле авылы

Дүртөйле үз исемен болай алган. Элек бу урында кечкенә урыс авылы булган. Анда нибары дүрт гаилә – Трапезниковлар, Дьяконовлар һәм агалы-энеле Чистяковларның ике гаиләсе яшәгән. Шулай да, авыл географик яктан уңайлы урынга урнашканлыктан, тирә-якта яшәүче татар-башкорт крестьяннары монда базарга килә торган булган. Үзара сөйләшкәндә, алар: «Дүрт өйле авылга барабыз», – дип әйткәннәр. Чөнки, башта әйткәнчә, Дүртөйле дүрт өйдән генә торган. Башта Дүртөйледә Большая урамына нигез салына, ул хәзер Совет урамы дип йөртелә. Географик яктан уңайлы булуы, авылның үсүенә, зур сәүдә үзәгенә әверелүенә китерә.

*1998 елда Дүртөйле шәһәренең туган якны өйрәнү музее*
*материалларыннан БДУ студенты Миләүшә Нурлыгаянова*
*күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 35*

## 28. Дүртөйле һәм Илеш районы авыллары

Шушы тирәдәге авылларның барлыкка килүе турында түбәндәге риваять яшәп килә. 1470 елда Коты исемле бабай көтүләрен Мәргәли елгасы буена кышларга куып китерә. Бу якларның табигатен бик ошата һәм соңгы көннәренә чаклы шушында яши. Шулай итеп, Коты авылы барлыкка килә. Ә аның әтисенең абыйлары Язарбулат, Тукбулат һәм Тукбулатның улы Солтанбәк, арырак барып, Агыйдел буйларына килеп чыгалар. Әмма, бурлакларның талауларыннан куркып, гүзәл Агыйдел ярларыннан китеп, Торатау тавы итәгенә барып урнашалар. Шулай итеп, Солтанбәк авылы барлыкка килә. Шушы ук нәселдән чыккан Исмәгыйль, Яркәй, Ляяшты, Кадер, Борхан, бурлаклардан качып, Исмаел, Яркәй, Ляяшты, Кадер авылларын барлыкка китерәләр. Ә шушылардан соң инде алда атап үтелгән Дүртөйле авылы барлыкка килә.

*1998 елда Дүртөйле шәһәренең туган якны өйрәнү музее материалларыннан БДУ студенты Миләүшә Нурлыгаянова күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 36*

## 29. Мәскәү авылы

*(1 нче вариант)*

Хәзерге Мәскәү авылы җирләре элек тоташ урманнар белән капланган булган. Моннан 360–380 еллар чамасы элек хәзерге Шәмсетдин күле янына Шәмсетдин исемле кеше килеп утырган. Чыгышы белән ул башкортлардан булган. Аның Мәскәү исемле улы да булган. Ул күчеп китеп, хәзерге Мәскәү авылы урнашкан җиргә килеп утырган. Аңа ияреп, дус-ишләре, кардәш-ырулары, танышлары да күчеп килгән. Авылга нигез салучысының исемен биргәннәр. Халык якын-тирә урманнарны чистарткан, төпләгән һәм игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнә башлаган.

Безнең яктагы башкортлар ясак җыюдан, салым түләүдән баш тарту сәбәпле, югарыдан Сергеев фамилияле комиссар җибәрелә. Бу хәл 1705 нче елда була. Сергеевның «тәртипкә утырту» ысулын халык кабул итми, корал тотып, көрәшкә күтәрелә. Мәскәү Уразбаев үзенә ике меңнән артык крестьяннан

торган гаскәр җыя. 1708 нче елда крестьяннар гаскәренә Казанга барып җитәргә нибары утыз чакрым ара кала. Башта отряд Сарапул өлкәсендәге Савин монастырен җимерә, чөнки анда хөкүмәт гаскәрләренең оясы урнашкан була. Алар, монахлар киемен киеп, яшеренеп йөриләр. Шуннан соң Мәскәү отряды белән Сарапул аша Казанга юл тота. Үтешли бай авылларны талый. Җиңүдән соң Мәскәү авылга әйләнеп кайта.

1880 еллар тирәсендә авылның югары очына татарлар килеп утыра. Алар тиздән Урманасты, Сабанай, Кәчүән, Баши авылларына да күченә. Мәскәү авылы исә зураеп, төзекләнеп китә. Халкы бик усал була. Башка авыл кешеләре Мәскәүгә керергә дә куркалар, аны урап үтәләр.

*1998 елда Дүртөйле районы Мәскәү авылында*
*Тәнзилә Хуҗинадан (1931 елгы) БДУ студенты*
*Дилара Фәттәхова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 37*

## 30. Мәскәү авылы

*(2 нче вариант)*

Элек Николо-Березовка авылында бер бик бай бояр яшәгән. Аның Баши, Әкәнәй һәм Мәскәү исемле өч улы булган. Алар өчесе өч җиргә килеп утырган. Шулай итеп, Мәскәү, Әкәнәй һәм Баши авыллары барлыкка килгән, имеш.

*1998 елда Дүртөйле районы Мәскәү авылында*
*Тәнзилә Хуҗинадан (1931 елгы) БДУ студенты*
*Дилара Фәттәхова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 38*

ИЛЕШ РАЙОНЫ

## 31. Базытамак авылы

Авыл Базы елгасының Агыйделгә килеп кушылган урынында урнашкан була элек. Шуңа аның исеме дә – Базытамак.

Борын заманнарда авылның тирә-ягы куе әрәмәлек белән уратып алынган була. Анда төрле җиләк-җимеш үсә. Ләкин монда бүреләр дә бик күп була. Алар авылга еш кына һөҗүм иткәннәр. Шуңа күрә халык бу урыннан күчеп китәргә уйлый.

Берничә чакрым читтәрәк яңа авыл нигезләнә. Шулай итеп, Базытамак урынын үзгәртә. Авылның элекке урынын хәзер

Үле Базы дип йөртәләр. Еллар үтү белән, Агыйдел һәм Базы елгалары агышын үзгәртә. Базы Агыйделгә икенче урыннан коя башлый. Шуңа күрә Базытамак елгаларның кушылган урыныннан бөтенләй читтә утырып кала. Авылның исеме җисеменә туры килми дияргә мөмкин. Агыйделнең элек аккан урынын халык – Иске Идел, ә Базыныкын – Үле Базы дип йөртәләр.

*1998 елда Илеш районы Карабаш авылында*
*Сания Хаҗиевадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 41*

### 32. Бишкурай авылы
*(1 нче вариант)*

Бишкурай авылы элек Бишкураз дип аталган. «Бишкураз»ның тамыры – «биш» һәм «кураз» сүзләреннән. Сүзлекләрдә «кураз» фарсы теленнән кергән сүз дип күрсәтелә. Мәгънәсе «әтәч» дигәнгә туры килә.

Риваять буенча, монда иң элек Нуркай, Күсекәй һәм, алар белән бергә, тагын өч гаилә килеп утыра. Шулай яз башында, беренче әтәч кычкыру белән, алар бишесе дә басуга чыгалар. Һәркайсы үзе белән берәр әтәч алып килә. Әтәчләрне җир башында суеп йолкалар. Казан асып, аш пешерәләр. Шуннан үзләре эшкә керешәләр. Моңа тиклем кеше кулы тимәгән җирнең чирәмен күтәрәләр.

Шул биш әтәч исеме белән, Бөет язы дигән су буенда авыл нигезләнә. Беренче йортны салганда да, биш әтәч сую йоласы башкарыла. Шуңа да авылны Бишкураз дип атап йөртә башлыйлар. Татарча ул «биш әтәч» дигәнне аңлата. Шуннан Бишкураз Бишкурайга әйләнә.

*1996 елда Илеш районы Лена авылында*
*Сахия Гайсинадан (1924 елгы) БДУ студенты Галия Каһирова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 42*

### 33. Бишкурай авылы
*(2 нче вариант)*

Авылга читтән бер егет килеп утырган. Ул матур итеп курайда уйный белгән. Шуңа да авыл халкыннан үзенә курай табып

бирүләрен сораган. Авыл халкы аңа биш курай табып биргән. Шуннан бирле бу авыл Бишкурай дип атала башлаган.

*1996 елда Илеш районы Лена авылында*
*Сахия Гайсинадан (1924 елгы) БДУ студенты*
*Галия Каһирова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 43*

### 34. Бәләкәй Бишкурай авылы

Иван Грозный Казанны алгач, татарлар, безнең якларга күчеп килеп, Бишкурай авылына нигез салалар. Алар, патшаның эзәрлекләвеннән куркып, үзләрен башкортлар дип яздыралар. Бишкурай халкы әле дә үзен башкорт дип йөри, тик сөйләшүләре татарча.

Шулай да үз милләтеннән курыкмыйча, сатылмыйча, «без – татарлар» дип язылучылар да була. Аларны Бишкурайдан куалар. Татарлар Ямал карт беренче булып килеп утырган җиргә – Корыч тавына күченәләр һәм шунда Бәләкәй Бишкурай авылын нигезлиләр. Шуңа күрә дә Бәләкәй Бишкурай халкын «типтәрләр» дип йөртәләр, чөнки алар тибелгәннәр, куылганнар. Аларга җирнең дә начары эләгә. Элек Бәләкәй Бишкурай авылын Ямал очы дип тә, Типтәр дип тә атап йөрткәннәр.

*1998 елда Илеш районы Бәләкәй Бишкурай авылында*
*Мәсбих Дәүләтшиннан (1921 елгы) БДУ студенты*
*Иркә Шәрәфиева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 44*

### 35. Бүләк авылы

Бүләк авылы 1925 елда барлыкка килгән. «Бүләк» атамасы «бүлек» сүзенең аваз үзгәреше аркасында тугандыр, мөгаен. Чөнки ул Бишкурай авылы халкының бер өлеше, бер бүлеге аерылып, күчеп утыруы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Шуңа күрә авылны Бүләк дип атыйлар.

*1996 елда Илеш районы Сүлте авылында*
*мулла Фахразый Галимовтан (1919 елгы) БДУ студенты*
*Галия Каһирова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 45*

### 36. Груздьевка авылы

Заманында Груздьев фамилияле бик бай урыс алпавыты яшәгән. Ул бик мәрхәмәтле булган, байлык туплап кына кал-

мыйча, халыкка файдалы эшләр дә башкарган. Мәсәлән, Илеш авылында балалар йорты салдырган. Мәчет төзетмәкче булган, ләкин Илеш авылы халкы:

– Урыстан мәчет салдырмыйбыз, – дигәннәр.

Груздьев мәчетне Кенәз-елга авылына төзетергә мәҗбүр булган. Халык, аның эшләгән эшләре өчен рәхмәтләрен белдереп, авылны Груздьевка дип атаган. Бу поселокны әлеге вакытта Элеватор дип тә йөртәләр, чөнки монда элеватор бар.

*1997 елда Илеш районы Илеш авылында*
*Ким Галиуллиннан БДУ студенты Гөлнур Гайсина*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 46*

## 37. Дөмәй авылы

XV гасырда хәзерге Дөмәй авылы урынына Дөмәй исемле бер карт килеп утыра. Моңа тиклем ул Агыйделнең уң ягында, Урал тавының көньяк-көнчыгыш итәгендә яшәгән булган. Дөмәй бик нәфселе кеше була, барлык уңдырышлы җирләрне, урманнарны басып алуны үзенә максат итеп куя. «Нәфсеңне симертсәң, үзеңә бер бәла эшләр», – ди бит халык. Дөмәйне авылдашлары яратмый, куып җибәрә. Карт Агыйделнең аръягына чыгып, үзенә яңа урын эзләргә мәҗбүр була.

Яшәр өчен уңайлы урын эзләп, хәлдән тайгач, маңгай күзе генә түгел, күңел күзе дә хозурланырлык матур җир таба ул. Якында гына өч елга шаулап агып яткан урынга йорт сала. Соңыннан ул елгаларның берсе – Сүдәш, икенчесе – Урта Кыргы, өченчесе Чит Юрга дип атала башлый.

Дөмәйнең ике хатыны, егерме улы, дүрт кызы була. Нәселе үрчеп кенә тора. Шулай итеп, авыл барлыкка килә. Ул нигез салучысының исемен ала.

Халык арткан саен, якын-тирәдәге урманнар сирәкләнә бара. Җир җитми башлагач, ул урманнарны яндыралар. Шулай итеп, йөз ел эчендә Дөмәй зур авылга әйләнә, һәр сишәмбедә үткән зур базары тирә-якта дан казана. Авылда олы мәдрәсә дә салына. Дөмәй тирә-яктән килгән шәкертләр белән тула.

Халык ишәйгәч, бер урынга сыеша алмый башлый. Бер урам, авылны ташлап, читкәрәк күчеп утыра. Шулай итеп, Яңа Дөмәй авылы барлыкка килә.

*1998 елда Илеш районы Дөмәй авылында*
*Нәгыймә Садретдиновадан БДУ студенты*
*Таңсылу Ногманова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 47*

### 38. Иләкшиде авылы

Элгәре бу авылда иләк сугучы кеше яшәгән. Ул иләкне ат кылыннан суга торган булган. Барлык авылдашлары да иләкне гел аңардан ала торган булганнар. Шуннан соң бу авылны Иләкшиде дип йөртә башлаганнар.

*1996 елда Илеш районы Лена авылында*
*Сахия Гайсинадан (1924 елгы) БДУ студенты*
*Галия Каһирова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 48*

### 39. Илеш авылы

Илеш авылы Сөн елгасының уң як ярында урнашкан. Авылның исеме бу урыннарга беренче килеп утырган Илеш карттан алынган. Алар өч бертуган булганнар һәм хәзерге Бакалы районы Корыч авылы тирәсеннән күчеп килгәннәр. Берсе – Шәммәт, икенчесе Аккүз авылына нигез салган.

Авылның кайчан барлыкка килүе билгесез. Илеш авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә мари авылы урнашкан булган. Бүгенге көндә түбән очтагы бер зиратны «Мари зираты» дип йөртәләр. Авыл зураю белән мариларны кысрыклыйлар, алар Агыйдел елгасының уң як ярына күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Илештә марилардан бары тик Рахманкул нәселе генә кала.

Шулай итеп, бу чорда авылда өч төрле халык яшәгән, ягъни башкортлар, типтәрләр, Казан ясаклылары – соңрак татар җирләреннән килгән кешеләр. Алар һөнәрчелек һәм вак сәүдәгәрлек белән шөгыльләнгәннәр. Бүгенге көндә аларның нәселен Басыйров, Мөхәммәтҗанов һәм Латыйпов фамилияләрен йөртүчеләр дәвам итә.

Башкортлар борынгыдан ук шушында җир биләгәннәр, алар – Урал аръягыннан, ә типтәрләр Казан ягыннан күчеп килгәннәр. Элекке вакытта бу авылда яшәүчеләр башкорт һәм

типтәр урамнарына бүленеп утырган булалар. Типтәр урамында яшәүчеләрнең варислары бүгенге көндә Габбасов, Кашбиев, Хәмидуллин һәм Гәрәев фамилияләрен йөртә.

*1997 елда Илеш районы Югары Яркәй авылында*
*Мөнирә Адиятуллинадан (1956 елгы) БДУ студенты*
*Гөлнур Гайсина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 49*

## 40. Исәмәт авылы

Хәзерге Исәмәт авылы янында элек кеше аягы үтә алмаслык сазлыклар булган. Халык моңардан бик җәфаланган.

Бу авылда бер бик бай сәүдәгәр яшәгән. Аның исеме Исәмәт булган. Халыкның җирсез этләнгәнен күреп, Исәмәт сазлыкларны корытып бетерергә уйлый. Ул бик күп агач-бүрәнәләр алып кайта да аларны сазлыкка ыргытырга куша. Бүрәнәләр бөтен суны эчеп бетергәннәр, ди, һәм сазлыклар бер-бер артлы юкка чыга барганнар. Шулай итеп, яңа чәчүлек җирләр барлыкка килгән.

Халык, хөрмәтләп, авылны Исәмәт дип атаган. Бу сәүдәгәрнең Җайлау исемле кызы һәм Торачы исемле улы да булган. Киләчәктә аларның исемнәре яңа барлыкка килгән авылларга бирелгән.

*1998 елда Илеш районы Югары Яркәй авылында*
*Җиһанур Баһаветдиновадан БДУ студенты*
*Таңсылу Ногманова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 50*

## 41. Иске Күктау авылы

*(1 нче вариант)*

Борын заманда бер картның ике улы булган. Аларның берсе – Күктау, икенчесе Яркәй исемен йөрткән. Алар табигать кочагында уйнап, урманга-суга йөреп, Кисичү елгасыннан балык тотып, үсеп, буй җиткәннәр. Аннан Оренбург шәһәрендә укыганнар. Яркәй, егет булгач, Череккүл авылының чибәр, ләкин астыртын кызын үзенә караткан һәм аңа өйләнеп тә куйган.

Яркәй рус-төрек сугышында, Ларса, Кагула елгалары буендагы бәрелешләрдә аеруча зур батырлык күрсәтә һәм моның өчен командующий П.А. Румянцев тарафыннан Георгий тәресе белән бүләкләнә. Сугыштан кайткач, туганы Күктау белән

икесенә җир сорап ала. Шулай итеп, бертуганнар бер-берсеннән 5–6 чакрым ераклыкта йорт салып кергәннәр.

Иске Күктау авылы аша Казан – Уфа – Оренбург юлы үткән. Аның авыл аша үтүен халык үзе сорап алып, үзе төзегән. Юл салынып беткәч, патшабикә Екатерина II шушы юлдан Екатеринбургка бара, һәм бу юл халык телендә «Әби патша юлы» исемен ала. Әлеге көндә дә авыл уртасында шул вакытта төзелгән күпер тора һәм үз вазыйфасын үти. Авылыбыз да әлеге көнгә кадәр үзенә нигез салучының исемен йөртә.

*1997 елда Илеш районы Югары Яркәй авылында Мөнирә Адиятуллинадан (1956 елгы) БДУ студенты Гөлнур Гайсина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 51*

### 42. Иске Күктау авылы
*(2 нче вариант)*

Күктау авылы турында беренче документаль истәлекләр 1745 елда язылa. Бу вакытта шушы авыл кешесе Зәит Сәетов үзенең җирләрен крестьяннарга бүлеп бирә. Шул ук Зәит Сәетов тарихта тагын бер тапкыр телгә алына. Күктау авылы кешеләре Әбди Кузәков һәм Чапай Бигинеев белән бергә алар, 10 ел буена кулланырга рөхсәт биреп, үз җирләренә ясак татарларын кертәләр.

Элек авыл хәзерге урыныннан 5 чакрым читтәрәк урнашкан була. Ул Кийкичү елгасының ярыннан ук башланып киткән зур урманнан әз генә читтәрәк торган. Бу урынны авыл халкы хәзер Иске йорт дип атый. Ике гасыр элек монда авыл булуын белгертүче бер генә хәрәбә-истәлек тә юк. Шулай да урман читендә кыргыйланып беткән куак-куак балан, карагат, алмагачлар үсеп утыруын искә алырга була. Авыл халкы бу урыннан XVIII гасырда күчеп китә һәм яңа җирләргә урнаша. Алар нигезләгән авыллар – Иске Күктау, Яңа Күктау һәм Иштирәк.

Безнең авыл Бөре белән Минзәләне тоташтыра торган «Баганалы юл» буенда урнашкан. Иске Күктау юлчыларның тукталыш урыны булып торган. Үз заманында бу юлдан Әби патша – Екатерина II үтеп киткән.

XX гасыр башында авылда тегермән, мәдрәсә һәм өч мәчет булган. Халыкның укымышлылыгы турында да кызыклы мәгълүматлар сакланган. 1886 елны авыл сходында катнашкан 106 ирнең 11е төрки телдә үзенең култамгасын куйган.

Революциягә кадәр авылдагы 250 йорт-хуҗалык 30000 дисәтинә җир, 600 дисәтинә урман, 360 дисәтинә чәчүлек биләгән.

*1998 елда Илеш районы Иске Күктау авылында*
*Хәлимә Мәрвәровадан БДУ студенты Айлия Хәмидуллина*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 52*

## 43. Иске Күктау авылы

*(3 нче вариант)*

Элекке заманнарда Яркәй исемле карт яшәгән. Аның Күктау, Аккүз, Исәмәт исемле уллары булган. Картның биләп торган җирләре бик зур булган. Уллары үскәч, ул аларны өйләндереп, җирләрен бүлеп биргән һәм һәрберсенә аерым яшәргә кушкан.

Уллары өч авылга нигез салган, һәрберсенә үзләренең исемнәрен биргәннәр. Шулай итеп Аккүз, Исәмәт, Күктау авыллары барлыкка килгән. Ләкин Күктауга яшәгән урыны ошамаган, һәм ул икенче җиргә күчеп утырган. Яңа авылны – Яңа Күктау, элеккесен Иске Күктау дип йөртә башлаганнар.

*1998 елда Илеш районы Иске Күктау авылында*
*Хәлимә Мәрвәровадан БДУ студенты Айлия Хәмидуллина*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 53*

## 44. Яңа Күктау авылы

Элек-электән безнең якта яшәгән халык Иш тавына карап сокланган. Әйтергә кирәк, бу тау ерактан ниндидер күксел-сары төстә булып күренә. Шуңа да аның янында урнашкан авылны халык Күктау дип атый башлаган. Халык телендә Иш тавының икенче исеме дә – Күктау.

Берникадәр вакыт үткәч, өч-дүрт гаилә икенче урынга күчеп китәләр. Яңа Күктау исемле авыл шулай барлыкка килә. Ә элек яшәгән урыннары Иске Күктау дип атала башлый. Аңа 200 ел чамасы.

*1998 елда Илеш районы Карабаш авылында*
*Сания Хаҗиевадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 54*

**45. Ишкар авылы**

*(1 нче вариант)*

Авылның исеме Ишкар исемле бабайдан торып калган. Иң башта Ишкар бабай Балтач авылы янындагы тау итәгенә урнашкан булган. Ул тауның исеме Кирәмәт булган. Ләкин бу тауда гел туктамый сугышлар булып торган. Шул сугышлар аркасында, Ишкар бабай башка, тынычрак җиргә күчеп китә. Авылымның әлеге вакытта урнашкан урыны нәкъ менә шул Ишкар бабай килгән җир булып чыга да инде. Шаулап аккан елга буенда ул үзенең өен салган. Картыем сөйләвенчә, ул чорда әлеге авыл урынында куе урман булган. Йортка урын тазартыр өчен, аңа бик күп көч түгәргә туры килгән.

Күпмедер вакыт үткәч, Ишкар бабай кырына бүтән җирләрдән дә кешеләр килеп төпләнгән. Шулай итеп, авыл көннән-көн үсә барган. Монда яшәгән кешеләр авылны нигез салучысының исеме белән – Ишкар дип атыйлар.

*1997 елда Илеш районы Кызыл Байрак авылында*
*Мәликә Хөснуллинадан (1903 елгы) БДУ студенты*
*Айлия Хәмидуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 55*

**46. Ишкар авылы**

*(2 нче вариант)*

Ишкар исемле карт Яркәйнең бертуган абыйсы булган, дип сөйлиләр. Бик күп еллар элек ул хәзерге Ишкар авылы урнашкан җирләргә килеп утырган. Башта монда берничә өй генә була, ә соңрак, еллар үтү белән, Ишкар зур авылга әйләнә. Ләкин авылда яшәүче крестьяннарның күбесе җирсез була, алар кош-корт, мал-туар асрый алмыйлар. Бу кешеләр иртәннән кичкә кадәр кулакка бил бөгәләр. Кулак түләгән эш хакы мескен халыкка әзгә дә җитми.

Авылда Хөсәен, Кәрим, Хәким исемле усал, ерткыч кулаклар яшәгән. Алар һәрвакыт крестьяннарны талаган. Тик Октябрь революциясе генә крестьяннарга үзләренең җирләрен кире кайтарды.

1918 елны Ишкар авылында «аклар» белән «кызыллар» арасында кан койгыч сугышлар барган. Бу елның көзендә авыл

акгвардиячеләр кулында була. Алар Ишкар крестьяннарын талыйлар, качып калган партизаннарны эзлиләр.

Авылда Идрис Яһүдин исемле партизан яшәгән була. «Аклар» авылны басып алгач, Идрис кача. Дошманнар аны таба алмагач, Идриснең әнисен тоталар. Фәрәрбануны алар җәфалыйлар, улының кайдалыгын әйттерергә тырышалар. Мескен ана азаккы чиккә чаклы тора, улының кайда икәнлеген әйтми. Фәрәрбануның чыдамлыгына «аклар» аптырыйлар, ачулары килә. Алар, Идрискә үч итеп, әнисен асып куялар.

Идрис, кызылгвардиячеләрне җыеп, Дүртөйле ягыннан «аклар»га каршы һөҗүм белән килә. Алар «аклар»ны шундук үтереп бетерәләр, авыл азат ителә. Совет власте урнашкач, авылда сельсовет председателе сайлана. Ул коммунист Сафа Нәгыймов була. Ул кулакларга каршы көрәш башлый. 1929 елга тиклем алар юкка чыгарыла.

*1997 елда Илеш районы Югары Яркәй авылында Җиһанур Баһаветдиновадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 56*

## 47. Иштирәк авылы

*(1 нче вариант)*

Хәзерге Иштирәк авылы бик гүзәл, ямьле урынга урнашкан. Авылны урталайга бүлеп, елга ага. Аның ярларында урман-куаклыклар үсеп утыра.

Борын заманда, бер кеше, атына атланып, шушы җирләрдән үтеп барган. Ул безнең якларның искиткеч табигатен, мал асрау өчен бик уңайлы булуын күргәч, тиз арада гаиләсен, мал-мөлкәтен шушында алып килгән. Шулай итеп, авылга нигез салынган.

Кешеләр аңа исем кушарга уйлаганнар. Искә алганнар: монда тирәк агачлары күп булып, ишелеп үсә икән. Шуңа да авылга Иштирәк исеме бирелә.

*1997 елда Илеш районы Иштирәк авылында Ямигнур Муллагалиевтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 57*

## 48. Иштирәк авылы
*(2 нче вариант)*

Борын заманда Иштирәк һәм Карабаш авыллары кешеләре бик тату яшәгәннәр. Кайгыларын да, шатлыкларын да бергә кичергәннәр. Авыр чакта бер-берсенә ярдәм кулы сузганнар. Бервакыт читтән килгән халык, җир сорап, Карабашлыларны талый башлаган. Карабаш халкына ярдәмгә Иштирәк кешеләре ашыккан һәм дошманны куып җибәргәннәр. Шуннан Карабаш халкы әйткән:

– Әйдә, Иштирәкне Ишт**е**рәк дип атый башлыйк. Шушылай тату, бер-беребезгә терәк булып яшәрбез, – дигәннәр.

Шуннан бирле кайбер кеше авылны Иштирәк дип, кайберсе Иштерәк дип атап йөртә.

*1997 елда Илеш районы Иштирәк авылында*
*Ямигнур Муллагалиевтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 58*

## 49. Йонны авылы

Өлкәннәр сөйләвенә караганда, Йонны авылы кеше исеменнән килеп чыккан булырга тиеш. Өч бертуган ага булган, имеш: Яркәй, Рсай һәм Юньле. Алар өчесе өч урынга барып төпләнгән. Юньле исеме тора-бара Йонныга әйләнгән. Хәзер Йонны икегә бүленгән: Югары Йонны һәм Түбән Йонны. Алар арасыннан Базы елгасы ага. Географик яктан Йонны Рсай һәм Яркәй авыллары арасында урнашкан.

*1997 елда Илеш районы Йонны авылында*
*Риф Мәгъдәновтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 59*

## 50. Кадер авылы

Кадер авылы үзенең килеп чыгышы белән Бүләр волостенең старшинасы Кадергол Касимовка бурычлы.

Элек бу җирләр калын кара урман белән капланган булган. Урманнар кыргый корт оялары белән тулы булганнар. Җәнлекләрнең исәбе-хисабы булмаган. Шуңа күрә дә бу урманнардан үтеп чыгу мөмкин булмаган, төрле куркынычлар сагалаган.

Берчак шушы урманга, кыргый умарталардан бал алырга дип, Кадергол бабай килә һәм үзенә куыш кора. Кешеләр аның алачыгында ял итеп, төн кунып китә торган булганнар. Танышлары аптырап: «Ул урманнан ничек үттең?» – дип сорасалар: «Кадер бабай алачыгында кундык», – дигән җавап кайтарганнар.

Тора-бара Кадер бабай үзенә йорт салып керә. Балалары үсеп җиткәч, өйләнеп, биредә төпләнеп калалар. 1738 елда Кадергол Касимов В. Н. Татищев исеменә язылган донесениегә үзенең тамгасын куя. Бу донесениедә шушы җирләрне үз карамагы астына алырга рөхсәт сорап, үтенеч язылган була. Шулай итеп, Кадер авылы барлыкка килә.

*1997 елда Илеш районы Кадер авылында*
*Мәкълүфә Фәрхетдиновадан (1915 елгы) БДУ студенты*
*Физәлия Маликова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 60*

## 51. Лена авылы

Лена авылын 1928 елда Бишкурайдан күчеп утыручылар барлыкка китергән. Шәйхинур исемле кешенең атасы Шахмәр карт бу авылга кичтән килеп кунган да иртән әйберләрен җыеп кайтып та киткән. Яңа урын аңа ошамаган. « Башта ук күчмәгән булсам, нинди яхшы булыр иде! Ник күчтем мин?» – дип үкенгән ул кайтып барганда. Шуннан бу авылны Ник күчтем дип йөртә башлаганнар.

Бераздан Сүлте авылыннан Мәләкнең туганнары – Гыйльминур апа, Мәккә, Галәү карт, Хәтмулла, Сәхибулла абзый бу авылга күченеп килгәннәр. Бояр буасыннан урыслар да күченгән. Хәбир картлар Бишкурайдан күчеп утырган.

Алар җыелышып киңәшләшкәннәр дә авылны Лена дип атаганнар. Лена авылының клубы, правлениесе булган. Бу авыл түгәрәк формасында урнашкан. Авыл уртасында ялан. Элек монда алма бакчасы эшләмәкче булганнар. Баганаларын утыртып чыккач, сугыш башланган. Шуннан соң бу баганаларны Сүлтегә алып киткәннәр. Авылда колхоз бакчасы да булган. Анда кәбестә, бәрәңге, кишер утыртканнар. Авыл

артында сушилка да бар иде. Салам ягып, анда ашлык киптерәләр иде.

*1996 елда Илеш районы Лена авылында Наил Гаскәровтан (1934 елгы) БДУ студенты Галия Каһирова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 61*

### 52. Рсай авылы

Авылда элек-электән җир-суга бай булган башкортлар яшәгән. Монда иң беренче булып Рсай карт килеп утырган. Халык, нигездә, игенчелек һәм малчылык белән шөгыльләнгән. Кешеләр борыннан ук ирекле авыл общинасы булып яшәгәннәр. Патша армиясеннән ат дагалау һөнәренә өйрәнеп кайткан Мөхәммәтҗан Хәмидуллин исемле кеше тимерчелек ача. Авыл кешеләре пима басу эшенә дә өйрәнеп китәләр.

Рсай карт үз авылын бик яраткан, башкаларда да аңа мәхәббәт хисе тудырырга тырышкан. Халык, картка бүләк эшләргә уйлап, авылны Рсай дип атаган.

*1998 елда Илеш районы Карабаш авылында Зөлфия Фәсхиевадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 62*

### 53. Сүлте авылы

Әлеге Сүлте авылына башлап туганнары белән Солтангали исемле кыю бабай килеп утырган. Өлкәннәр әйтүенчә, аның милләте башкорт булган, чыгышы әллә Пермь, әллә Вятка ягыннан икән. Ул элек яшәгән җирләр кара урман булган. Аның гаиләсе, нигездә, малчылык белән шөгыльләнгән. Мал асрау өчен урман яхшы булмаган, кешеләр кигәвен, черкиләргә чыдый алмаганнар. Шуңа күрә ул, уңайлы урын эзләп, туган җиреннән күчеп китә һәм безнең якларга килеп чыга.

Солтангали килеп урнашкан җирләр урманлы, күп чишмәле, мал асрауга бик яхшы урын булган. Ул үзенең Игелек һәм Корбангали исемле ике туганы белән Бурлы авылында йорт сала. Солтангали үзенең энеләренә караганда кыюрак һәм көчлерәк булганга, гел өстенлеккә чыга. Шуңа да авыл аның исеме белән Султый дип аталып йөри башлый. Тора-бара ул үзгәреп, Сүл-

тегә әйләнә. Монда яшәүче халык арасында әле дә Солтангали, Корбангали һәм Игелекнең нәселләре өстенлек итә.

*1998 елда Илеш районы Югары Яркәй авылында Сәгыйть Тимербаевтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 63*

### 54. Ташчишмә авылы

Бу авыл 1925 елда барлыкка килгән. Ул тау башына утырган, ә тау астында челтер-челтер чишмә аккан. Бу чишмәнең суы чиста, саф. Авыл халкы рәхмәт укый-укый, әле дә шунда суга йөри. Аның тирә-ягы ташлар белән уратып алынган. Шуңа күрә дә халык авылны чишмә исеме белән, Ташчишмә дип атый.

*1996 елда Илеш районы Ташчишмә авылында Өмәхәдә Гафуровадан (1914 елгы) БДУ студенты Галия Каһирова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 64*

### 55. Теләкәй авылы

Казан ягыннан килүче бер төркем кеше төпләнергә урын эзләгәннәр. Тирә-ягында су һәм урман булган матур гына җиргә килеп туктап, иген чәчеп карарга булганнар. «Ел яңгырлы килсен, иген уңсын!» – дип, теләк теләгәннәр. Ул ел яңгырлы килгән, иген дә бик уңган. Кешеләр сөенешеп: «Иген уңды, теләкләребез кабул булды, әйдәгез, монда төпләнеп кенә калабыз!» – дигәннәр. Шулай итеп, яңа авыл хасил булган. Аны Теләкәй дип атаганнар.

*1996 елда Илеш районы Теләкәй авылында Энҗе Галләмовадан (1977 елгы) БДУ студенты Галия Каһирова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 65*

### 56. Тыпый авылы

Моннан 400 ел элек Тыпый карт Идел аръягыннан Кече Гүрде елгасы буена килеп утыра. Ул башкорт милләтеннән була. Куе урман эчендә биш-алты йорттан торган авыл төзелә. Авылда Аккүз, Күккүз, Баллы, Бәкәй, Көҗмәт, Рәхмәт, Әүхәт исемле кешеләр яшәгән. Ул вакыттагы кешеләрнең дөнья көтү кәсебе малчылык, умартачылык, балыкчылык була.

Тиздән монда татарлар да күчеп килә. Тыпый аларга Гүрде елгасының аръягыннан җир бүлә. Әле дә елганың бер ягын –

Башкорт урамы, ә икенче ягын Татар урамы дип атыйлар. Соңрак монда, җир сорап, чирмешләр дә килә. Тыпый аларга тау башын бирә. Хәзер бу тау «Чирмеш тавы» дип атала.

Авылда җир ике төрле бүленә. Башкортлар җан башына – 15–16 дисәтинә, типтәрләр 7–8 дисәтинә җир алалар. Калган 210 гаилә җирсез була, алар байларга ялланып эшлиләр.

Авылга нигез салучылар арасында иң бае Әүхәт була. Ул малчылык белән шөгыльләнә. 1820 елларда Сирай мулла, Шәрәкәй карт, Ямай, Рәҗетдин байлар ныклап игенчелек эшенә тотына. Алардан соң Әхмәтсәли хәзрәт, Кургали, Габдрахман, Хафиз мулла, Абдулла картлар игенчелек һәм малчылык белән шөгыльләнеп, эре байларга әйләнә.

1850 елларда Көҗмәт карт Маты елгасына тегермән кора. Бу вакытта ике ташлы тегермән дәүләт хисабына тарта.

Шушы елларда Тыпый һәм Туктагол авылы җирләре, урманнары бүленмәгән була. Ике арада шуның өчен зур күсәк сугышлары үтә. Күсәк сугышы белән Тыпыйдан Казыйхан, Йосып, Гали, Дәүләтша картлар җитәкчелек итә. Алыш вакытында үлү фактлары да очрый. 1902 нче елда ике арадагы җир бүлеп бирелә. Җирсез крестьяннарның бервакытта да өсләре – киемгә, тамаклары икмәккә туймаган.

1917 елга кадәрле Тыпый авылында 360 хуҗалык санала. Шулар арасында унлабы хезмәтче тотарлык бай булган. Бу чорда Тыпый авылы Уфа губернасы Бәләбәй өязенең Корыч волостена керә.

Октябрь революциясе җиңгәннән соң, авылда 1918 елга Совет власте урнашып бетсә дә, старосталык хөкем сөрә. Елның азакларына гына бөтен авылга бер депутат сайлана һәм өч ай саен алмашынып тора. Бу депутат авыл советы рәисе вазыйфасын үти. Мондый беренче депутат Ибли Минәҗетдинов була.

Авыл халкы тулысынча диярлек башкортлардан торган. Алар милләте буенча башкорт саналсалар да, сөйләм телләре татарча булган. Бу бүгенге көндә дә шулай. Тыпый кешеләренең сөйләме татар теленең урта диалектының Минзәлә сөйләшенә карый.

*1998 елда Илеш районы Тыпый авылында Фәһимә Галиевадан (1925 елгы) БДУ студенты Фәнүзә Шабаева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 66*

### 57. Уяндык авылы

Бу вакыйга колхозлаштыру чорларында булган. Белүебезчә, бу чорда барлык хуҗалыкларны көчләп колхозга кертkәннәр. Җиде гаилә колхозга керергә теләмичә, Идел буена барып, үзләре аерым яшәргә теләгәннәр. Төнлә, бергәләшеп, алар яңа урынга күчеп утырганнар. Шулай итеп, иртәнгә яңа авыл барлыкка килгән. Алар торгач: «Без уяндык», – дигәннәр. Шуннан бирле бу авыл Уяндык дип атала.

*1997 елда Илеш районы Илеш авылында Ким Галиуллиннан БДУ студенты Гөлнур Гайсина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 67*

### 58. Үрмәт авылы

350 ел чамасы элек авылның Тәкәрлек исемле урамы утырган урынга үзенең алты улы белән Ярмәк исемле кеше күчеп килә. Ләкин, бераз вакыт үткәч, ул Янтуган авылына күчеп китә. Озак та үтми, Ярмәк берничә хуҗалыкны ияртеп, кире әйләнеп кайта. Шулай итеп, авыл нигезләнә.

Ләкин бу вакытта авылда су ташу авыр булган. Тау башындагы чишмәгә үрмәләп менеп-төшеп йөрергә туры килгән. Шуңа да авылга Үрмәт исеме биргәннәр.

Соңрак монда Иж елгасының Чулманга койган урыныннан Салауги башкортлары да килеп утыра. Шулай итеп, авылда унышар гаилә берләштерүче җиде төркем оеша: 1. Ярмәк уны; 2. Атнагул уны; 3. Шәрәй уны; 4. Кенәз уны; 5. Ишбирде уны; 6. Түбән татар уны; 7. Югары татар уны. Аларга җир бүлеп бирелә.

*1997 елда Илеш районы Үрмәт авылында Сәгъдә Яһүдинадан БДУ студенты Рөстәм Хисаметдинов язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 68*

### 59. Череккүл авылы

Хәзерге Череккүл авылыннан ике чакрым ераклыкта Череккүл дип аталган күл бар. Элекке вакытта шушы тирәдә яшәүче башкортларның җирләренә читтән килүчеләр һөҗүм итмәкче булганнар. Бик каты сугыш башланган. Ике яктан да күп халык

кырылган. Яу беткәч, исән калганнар, күмәргә хәлләре булмыйча, үлеп калганнарны шушы күлгә ташлаганнар. Мәетләр шунда ятып, сасып черегәннәр. Шуннан бирле күлгә Череккүл дигән исем бирелгән. Янында барлыкка килгән авылны да кешеләр Череккүл дип атаганнар.

*1998 елда Илеш районы Иштирәк авылында*
*Фәния Гыйльмановадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 69*

## 60. Этәй авылы

Базы елгасы бу җирләрдә тар, ләкин балыкка бик бай булган. Тирә-яктан кешеләр монда балык тотарга килгәннәр. Шулай бервакыт Ишкар авылыннан берәү килеп, елгага кармак салган. Күрәсең, балык тоту бик мавыктыргыч булгандыр, ул озаклаган. Аны малае юллап чыккан. Малайдан кешеләр: «Кайда барасың?» – дип сорагач, «Әтәйгә», – дип җавап биргән. Менә шуңа да бу авылны Әтәйгә дип атап йөртә башлаганнар, тора-бара ул Әтәй дип үзгәргән. Ә хәзер инде авыл Этәй дип атала.

*1998 елда Илеш районы Карабаш авылында*
*Сания Хаҗиевадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 70*

## 61. Югары Яркәй авылы

Безнең якларга иң беренче булып Урал тауларыннан Базый исемле карт килеп утыра. Ул үзенә тормыш көтәр өчен уңайлы урын эзләп йөргән. Шулай бер көнне ул матур гына елга буена килеп чыга һәм монда атын эчерә. Бу елганы ул үз исеме белән – Базы дип атый һәм шунда ук төпләнеп кала.

Базый картның өч улы була. Зурысы – Яркәй Базыев хәзерге Яркәй авылына нигез сала. Уртанчысы Йонны исемле була. Ул Йонны авылын барлыкка китерә. Кече улы – Янтуган хәзерге Янтуган авылы җирләрендә көн күргән.

Яркәй башта бик яхшы балта остасы була. Соңрак ул сәүдә белән шөгыльләнә башлый, бик еш сәяхәтләргә чыга. Аның юллары һәрчак уңышлы була, эшләре әйбәт бара. Шулай итеп, ул бик тә күренекле кешегә әйләнә.

Яркәй үзенең авылындагы бер татар кызына өйләнә. Ләкин, озак та үтми, Оренбург шәһәренә сәүдә белән баргач, ул икенче яшь хатын һәм «Георгиевский крест» алып кайта. Беренче хатынының туганнары моның өчен Яркәйне күрә алмый башлыйлар. Алар егетне үтерергә уйлыйлар.

Җәй көннәрендә Яркәй көн саен су керергә Базы елгасына барган. Көннәрдән бер көнне беренче хатынының туганнары Яркәйне шунда тотып алалар һәм нык кына итеп кыйныйлар. Яркәй һушын югалткач, аны елгага ыргыталар. Егет Түбән Яркәйнең аръягына чаклы йөзеп бара. Аны кер чайкап йөргән бертуган апасы күреп, судан тартып чыгара. Ул, ярдәм сорап, авылга йөгерә.

Шулвакыт Яркәйнең беренче хатынының абыйлары килеп чыга. Әле үлеп бетмәгән Яркәйне күргәч, аларның ачулары тагын да ныграк кабара. Алар егетнең башын таш кисәге белән изеп, үтереп, елгага ыргыталар. Апасы авылдан кешеләр алып килүгә, Яркәй инде юк була. Аны эзләргә тотыналар. Бик озак эзләгәннән соң гына елгадан Яркәйнең үле гәүдәсен табалар. Авылга нигез салучы, исем бирүченең язмышы ана шулай аяныч була.

*1998 елда Илеш районы Югары Яркәй авылында Җиһанур Баһаветдиновадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 71*

## 62. Ябалак авылы

*(1 нче вариант)*

Элек безнең якларда яшәгән, ди, бер карт. Ул гомер буена умартачылык белән шөгыльләнгән. Бал аертып, аны авылдашларына тараткан. Бервакыт моның бал кортлары кими башлаган. Карт, ни хәл итәргә белмичә: «Кая булдылар кортларым?» – дип, кайгыга баткан.

Моның сәбәбе тиз ачыкланган. Авылда ябалаклар күп булган, һәм алар бал кортлары белән тукланганнар икән. Шуннан бирле карт ук-җәяләрен алып, ябалакларга ауга чыга башлаган.

Умарталык тиздән элекке хәленә кайткан, бал кортлары кире үрчегән. Ә карт ябалакларга ауга йөрүен барыбер туктатмаган. Кешеләр аны күргән саен:

– Әнә, Ябалак карт, – дип әйтә торган булганнар һәм авылга картның исемен кушканнар.

*1997 елда Илеш районы Ябалак авылында*
*Мирзаһит Миркасыймовтан БДУ студенты*
*Гөлнур Гайсина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 72*

## 63. Ябалак авылы
*(2 нче вариант)*

Элек бу авыл урынында куе урман булган. Анда ябалаклар, козгыннар оя корганнар. Халык монда килеп, утын кискән. Тора-бара кешеләр монда төпләнеп тә кала башлаганнар, ә авылны Ябалаклы дип атаганнар. Хәзер авылның исеме кыскарып, Ябалак кына булып калган.

*1996 елда Илеш районы Илеш районы Ябалак авылында*
*Сара Арслановадан (1910 елгы) БДУ студенты*
*Гөлнур Гайсина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 73*

ЧАКМАГЫШ РАЙОНЫ

## 64. Бәшир авылы

Зират ташларындагы язуларга караганда, Бәшир авылы моннан 200-250 еллар чамасы элек барлыкка килгән.

Түмән һәм Пенза якларыннан килгән татарлар Сәвәде елгасының уң як тамагына урнашалар. Берничә ел буена шунда яшиләр. Ләкин кар басып йөдәткәнлектән, моннан күчәргә мәҗбүр булалар. Һәм, киңәшләшеп, икегә бүленергә уйлыйлар.

Боларның араларында Бәшир һәм Ихсан исемле картлар була. Халыкның бер төркеме Ихсан бабай җитәкчелеге астында Чәрмәсән буена урнаша, ә икенче өлеше Бәшир бабай җитәкчелегендә Сәвәденең сул ягына күчә. Бәшир авылы өч өлешкә бүлеп йөртелә: Иске Бәшир, Тау Бәшир, Яңа Бәшир. Иске Бәширдә – түмәннәр, Тау Бәширдә – башкортлар һәм мишәрләр, ә Яңа Бәширдә морзалар яшәгән.

«Морза» дип әйтүнең дә тарихы бар. Урыс патшасы, Казанны алыр өчен, Казан ханы белән сугышканда, бу халык патшага сугыш серен ача: шәһәргә керә торган крепость капкасын

күрсәтәләр. Шуның өчен алар ясак түләмиләр, аларга җир дә күбрәк бирелә.

*1970 елда Чакмагыш районы Бәшир авылында Гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы ветераны, элекке колхоз рәисе Мәсәлим Гәрәевтан (1899 елгы) БДУ студентлары язып алган*

## 65. Калмаш авылы

Авылыбызның барлыкка килүенә якынча 400 ел, ди картлар. Аның каян, ничек килеп чыкканын да төгәл генә белүче юк. Авылга беренче булып Баек һәм Уразмәт исемле кешеләр килеп утырган, имеш. Баек – Казан ягыннан, ә Уразмәт Ука елгасы буеннан күчеп килгән булырга тиеш. Шулай итеп, авыл барлыкка килә. Аның исеме булмый. Тора-бара кешеләр авылыбыздан күпләп күчеп китә башлыйлар. Ни өчен икәнлеге билгесез. Авылда торып калган кешеләрне тирә-як халкы «Калмышлар» дип атый. Шулай итеп, авыл Калмыш дип атала башлый. Торабара ул, үзгәреп, Калмашка әйләнә.

*1999 елда Чакмагыш районы Калмашбаш авылында Хәдичә Галләмова-Кәлимуллинадан БДУ студенты Ирина Насыйрова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 146*

## 66. Карьяуды авылы

Авылга иң башта типтәрләр нигез сала. Алар «14 душлык җиргә» килеп урнаша. Бүгенгесе көндә дә авылга беренче булып төпләнгән кешенең варислары исән. Ул – Галиев Хәмәт бабай.

1880 нче елда Хәмәт бабайның картәтәсе Иске Карьяудыдан күченә. Ул җәен арбага барлык кирәк-яракларын төяп, әйберләр өстенә улы – өч яшьлек Садрины утырта. (Хәмит бабайның әтисе була ул Садри). Дүрт чакрымлап ара үткәч, карасалар – бала юк. Әти кеше тиз генә әйберләрне бушата да кире ашыга. Бәхеткә каршы, бала Өчбүлә суының яр буенда уйнап утыра.

Ә Карьяуды авылының исеме болай барлыкка килә. Күчеп утыручы типтәрләр яңа авылга исем таба алмыйча җәфаланалар. Ничек атарга авылны? Менә шулчак күкне кара болыт

каплый, суык җил исә башлый. Җәй вакыты өчен бу гаҗәп хәл була. Әйтерсең дә җәй кыш белән алышына. Күп тә үтми, кар ява башлый. Кешеләр: «Менә кызык, җәй көне кар явамени инде, кар яуды, кар яуды!» – диешәләр. Шулай итеп, авыл Каръяуды дип атала башлый.

*1992 елда Чакмагыш районы Яңа Каръяуды авылында*
*Илсур Мансуровтан (1973 елгы) БДУ студенты*
*Илдус Фазлетдинов язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 147*

## 67. Коты авылы

Коты бабаның Маргыш елгасы буена килеп урнашуы, якынча хисап белән, 1470 нче еллар, дип исәпләнә. Бу бабаның бабасы Гали баба булган. Гали бабаның балалары Урал (Яйык) буеннан килгәннәр. Аның ике улы булган: беренчесе – Ягынгы-Би, икенчесе – Акиярби. Боларның балалары Янбулат, Тукбулат, Язарбулат, Әптел, Солтанбәкләр булып, кайда яхшырак урын бар, шунда күчеп йөргәннәр.

Коты баба Язарбулатның улы булган. Үз маллары белән Маргыш елгасы буена килеп, хәзер Иске йорт дип аталган урында кышлак ясап, шунда берничә еллар утырган. Бу урында ниндидер бер җайсызлык чыгып, 1531 еллар тирәсендә ул Маргыш елгасы буйлап бер бүрәнә агызып җибәрә һәм шул бүрәнә кайда туктала, шунда утырам дип сүз бирә. Ул бүрәнә елганың борылган урынында туктый һәм шунда Иске Котының утырышы була.

Боларны түбәндәге күрсәтмәләр раслый. Коты бабаның балаларының берсе – Габделвәлинең улы Мөхәммәди баба шушы авылның беренче зиярәтында күмелгән. Шулай ук Коты бабаның алтынчы улы Атнагулның кабере дә шунда. Мөхәммәди баба, Гали бабадан башлап, бабаларының исемнәрен язып килә. Шәҗәрә буенча Мөхәммәди баба 76 яшендә үлә. Хәзер бу исемлекләрне шушы көнгә кадәр мин дәвам итәм.

Бабаларның Иске Котыдан Яңа Котыга күчүе, якынча хисап белән, 1627 елларда булырга тиеш. Коты авылының хәзерге көндә урта мәктәп бакчасында калган беренче зиярәтында

Яркәй бабаның сәнә һиҗрия буенча 1040 елда 40 яшендә үлүе турында язылган таш бар иде. Шулай ук Юлдаш бабаның вафат булуы турында язылган ташлар да табыла. Без 1931–1932 елларда укытучы Рәхимҗан Шәрипов һәм укучылар белән бу ташларны табып, аларның кемгә каравын белештек.

Мәсәлән, Яркәй бабаның берничә ел печән чапкан урынына «Яркәй чокыры» дип исем биргәннәр. Моннан тыш Бакый кулы, Биктимер акланы дигән исемнәр дә бар. Иске Коты авылыннан 25 чакрым ераклыкта, Әсән авылы белән Нажы авылы арасында Ябынгы чокыры дигән чокыр барлыгын белдек. Бу Коты бабаның атасының туганы – Ябынгы бинең биләмәсе. Шулай ук Коты бабаның атасы белән бертуган Тукбулатның улы – Солтәнбәк баба, Ак Идел буендагы талаучылардан котылу өчен, Ак Иделдән өч чакрым ераклыктагы Иске Солтанбәк дигән урынга утыра. Бу авылның башка исеме дә бар. Кайбер күрше авыллар аңа мыскыллап Чупты дип исем кушкан.

Бу урында беренче баба урман арасында бура бурата. Бу бураны Бишкураз авылы утырган урынга ташу өчен өмә итә. Өмәчеләр бу бабаның өмәгә әзерләнгән итен азсынып, «биш кураз» дип атыйлар. Башкорт телендә кураз – әтәч дигән сүз. Шулай итеп, авыл – Бишкураз, соңыннан Бишкурай булып китә.

Бу авылда Китапов фамилияле кешеләр бар. Монда яшәгән бабалардан берәү печән чапкан вакытта баш астына китап куеп яткырылган бер бала табып алып үстерә һәм Китапов фамилиясе бирә. Патша вакытында эшче халыкның тормышы авыр булгач, балаларын да ташлап киткәннәр.

*1970 елда Чакмагыш районы Коты авылында*
*элекке укытучы Нурислам Бәдретдинов (1878–1970) язмаларыннан*
*БДУ студентлары күчереп алган*

### 68. Рәҗәп авылы

1703 елның 28 июлендә Уфаның гаскәр башлыгы Ефим Зыбин һәм башкорт-кыръеланлылар арасында килешү төзелә. Аның нәтиҗәсендә, Сәхәш елгасы буендагы җирләр типтәрләргә бирелә һәм Рәҗәп авылына нигез салына. Иң беренче булып, бу төбәккә Рәҗәп исемле карт килеп урнаша.

Типтәрләр татарлардан булганнар. 1762 елда – 60 типтәр, 1870 елда – 605 типтәр, 1920 елда – 1348 татар яшәгән. Бары тик 1925 елда гына 10 хуҗалыктан торган кечкенә авыл – Яңа Тайняш авылы аерыла.

*1997 елда Чакмагыш районы Рәҗәп авылы музее материалларыннан БДУ студенты Эльза Галимова күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 148*

### 69. Тозлыкуш авылы

Элекке заманда шушы җирләрдә атаклы чокырлар булганнар. Аларның исемнәре хәзер дә шул көенчә сакланганнар:

1. Зирекле күл.
2. Умарталы күл.
3. Зиятратлы күл.

Шушы чокырлар буена безнең бабайлар каен тузыннан куыш корып утырганнар. Шуннан бу куышлар күбәя башлаган. Алар шушы кечкенә авылчыкка Тозлыкуыш дип исем биргәннәр. Соңыннан шушы исемне җиңеләйтеп, халык аны Тозлыкуш дип йөртә башлаган.

Безнең бабаларыбыз башкорт булганнар. Шушы җиргә Зирекле күл, Умарталы күл, Зиятратлы күл дип исем биргәннәр. Бу җирләр урман белән капланган булган. Боярлар вакытында ул урманнар киселеп беткән. Авылдан ерак түгел Хәйрулла хуторы бар. Бу хуторда Хәйрулла дигән кеше яшәгән. Бу исем шуннан калган.

*1970 елда Чакмагыш районы Тозлыкуш авылында Насыйбуллин фамилияле кешедән БДУ студентлары язып алган. Ул авылдагы беренче коммунист һәм колхоз рәисе булган*

### 70. Үрнәк авылы

Авылның исеме элек Кара көчек булып йөргән. Аның тарихы мондый.

Элек хәзерге авыл урынында бары тик урман булган. Шунда ук кечерәк кенә бер күл булган. Бу күл төпсез булган, ягъни саз кебек, һәр нәрсәне үзенә тартып алган. Шуңа аны «Кара кичү» дип атаганнар. Күп кенә хайваннар, шул исәптән монда

беренче булып килеп төпләнеп утырган кешенең бик акыллы бер кара төстәге көчеге дә шунда батып үлгән. Соңга таба күлне «Кара көчек» дип атаганнар. Ә инде еллар үтү белән, күл буенда авыл барлыкка килгән. Ул да Кара көчек дип йөртелә башлаган.

*1970 елда Чакмагыш районы Үрнәк авылында*
*Идият Хәмәтҗановтан (1885 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 71. Чакмагыш авылы

Картлар сөйләвенә караганда, хәзерге Чакмагыш авылы урынында элек кечкенә бер елга агып яткан. Тәүгеләрдән булып килеп урнашкан кешеләр елга ярыннан чакматаш чыгара башлыйлар. Шуңа да елгага һәм үзләре төзегән авылга Чакматаш исеме бирелә. Вакыт узу белән, Чакматаш исеме үзгәрә бара һәм бүгенге көндә авыл Чакмагыш дип йөртелә.

Хәзерге Башкортстан җирләрендә булып үткән төрле баш күтәрүләрдән безнең районда яшәгән халык та читтә калмаган. Мәсәлән, Пугачев явы турында сөйләгәндә, Чакмагышта туып-үскән старшина Ишкуәт Дәүләтбаевны искә алып үтү урынлы. 1920 елның февраль аенда Минзәлә өязендә башланган «Кара бөркет» исемле крестьяннар баш күтәрүе Чакмагыш авылына да килеп җитә.

*1999 елда Чакмагыш районы Чакмагыш авылында*
*Госман Мөсәлләмовтан БДУ студенты Ирина Насыйрова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 149*

# РИВАЯТЬЛӘР

## ТАРИХИ РИВАЯТЬЛӘР

### *а) Алтын Урда дәвере һәм карымта-барымта яулары турында*

### 72. Урда

Бу – Ык елгасының бер ягыннан икенче ягына кичү урыны. Заманында бу урыннан Алтын Урда ханнары кичеп йөргән, диләр.

*1997 елда Бакалы районы Мостафа авылында*
*Мөниржан Йосыпов (1924–1993) истәлекләреннән БДУ студенты*
*Светлана Медведева күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 173*

### 73. Калатау һәм Калмык күле

Бу тауда калмыклар белән сугыш булган. Таудан түбәндә бер күл булган. Калмыкларга югарыдан бүрәнәләр тәгәрәткәннәр. Ышыкланып торыр өчен монда балчык өемнәре өйгәннәр. Шуннан бу тауны Калатау дип атый башлаганнар. Калмык күленең исеме дә шуннан калган.

*1977 елда Борай районы Кыдаш авылында*
*Габдрахман Фәйзрахман улы Фәйзрахмановтан (1900 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган. –*
*ТХИ РЛ, № 247; Фазлетдинов, 2018, № 176*

### 74. Үрәзикәй чишмәсе

XVII йөз урталарында авылда үзенең горурлыгы, чибәрлеге белән дан тоткан Үрәзи исемле кыз яши. Чит җирләрдән килгән илбасарлар бу кызны әсир итеп алып китмәкче, кол ясамакчы булалар. Ләкин кыю кыз үз иркен саклап кала. Коллык хурлыгын үлем җәзасына алмаштыра. Баш бирмәгән кызны, авыл читенә чыгарып, атып үтерәләр.

Авыл халкы аның үле гәүдәсен кадерләп тау итәгенә җирли. Кабернең баш очыннан чишмә бәреп чыга һәм аңа «Үрәзи» исеме бирелә. Тау да «Үрәзи» дип атала башлый.

*1998 елда Борай районы Кәшкәләү авылында Наилә Шәяхмәтовадан (1916 елгы) БДУ студенты Айсылу Муллакаева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 188*

### 75. Такыя тавы

Бик борынгы заманнарда, шушы җирләрдә Такыя исемле батыр егет яшәгән, ди. Дошманнар яу белән килгәч, ул аларга каршы көрәшкә чыккан һәм батырларча һәлак булган. Туган җирен ярату, хөрмәтләү хисе аңарда шул хәтле көчле булган ки, хәтта ул Ватан өчен гомерен дә жәлләмәгән. Бу батыр егетне ырудашлары хөрмәтләп, иң биек тауга күмгәннәр. Шуннан бирле бу тау «Такыя тавы» дип йөртелә башлый.

Әлегә кадәр шундый ырым да яшәп килә: янәсе, батыр егет күмелгән тау аның ырудашларын дошман күзеннән саклап тора икән. Һәм, чынлап та, шулайдыр, чөнки Такыя тавын үтмичә, аның аргы ягында нәрсә барлыгын күреп булмый.

*1997 елда Балтач районы Балтач авылында Сөләйман Усмановтан БДУ студенты Раушания Әхмәтшина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 187*

## *ә) Батырша, Салават Юлаев һәм Емельян Пугачев җитәкчелегендәге милли-азатлык көрәше турында*

### 76. Батырша күле

1755–1756 нчы елгы татар-башкорт кубарылышының җитәкчесе Гобәйдулла Гали улы Мәзгетдин (Батырша) исеме белән бәйле күл бу.

1755 нче елның 1 нче сентябрендә Карыш волосте старшинасы Яныш Абдуллин, 150 кешелек отряд җыйнап, Батыршаны гаиләсе, 10 шәкерте белән урманга кадәр озатып куя. Аңа каршы беркем дә корал күтәрми, чөнки Батырша төрки дөньясында бик күренекле шәхес була. Соңыннан үзенең патша Елизавета Петровнага язган хатында ул бу турыда бик җентекләп сөйләп бирә.

Картлар сүзләренә караганда, Батырша шул күл-чокыр буенда гаиләсе, шәкертләре белән бераз яшәп тә ала. Берчак ул үзен куып килүче гаскәрләрдән качып, шул күлгә чума һәм, авызына камыш кабып, эзәрлекләүчеләреннән котылып кала.

*1998 елда Балтач районы Карыш авылында укытучы Асия Гата кызы Харисовадан (1945 елгы) БДУ студенты Фәнүзә Садыйкова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 191*

### 77. Пугач белән Салават юлы

Пугач белән Салават явы вакытында Әби патша армиясенең берничә батальонын кысрыклый-кысрыклый Бөре, Дүртөйле, Мәскәү авыллары тирәләреннән зур гына яу үткән, диләр. Чакмагыш авылы янында, Чибекәй елгасының уң як ярындагы урманлыкта Әби патша гаскәрләре яткан. Шул тирәдә каты гына сугыш булып алган. Әби патша гаскәрләре чигенгән.

Пугач белән Салават гаскәре Тозлыкуш, Чакмагыш, Бәләкәй Чупты, Иске Балак, Камай авыллары аша көнчыгыштан көнбатышка үтеп киткәннәр. Шул тирәдән үткән яу юлын халык «Салават юлы» дип атаган.

Бу юл таулык, урманлыклар аша үтә. Уфа каласында торган патша гаскәрләре арттан төшмәсен өчен, Салават баш күтәрүчеләрнең эзен яшерергә тырышкан, ди. Шуңа ул күбрәк урман юлларын сайлаган. Гаскәр үтеп киткән, ә юл яшел урман белән каплана барган. Яу эзе, шулай итеп, әлләни беленмәгән.

Урман юлын үтешли, Салават атын бер матур акландагы каен янына туктаткан. Гаскәренә шунда куна калырга әмер биргән. Батырга шул каен янында урын әзерләгәннәр. Салаватның җан дусты Кинҗә шулвакыт күрше таудагы чишмәдән су алырга килгән. Алар авыр юлдан соң рәхәтләнеп салкын су белән юынганнар да чәй эчкәннәр. Ул чишмә әле дә бар.

Шулай бер төн кунгач, иртән Пугач белән Салават гаскәрләре Казанга таба юл тоткан. Шуннан бирле Салават атын бәйләп куйган каенны «Салават каены» дип йөртәләр. Чакмагыш мәктәбендә Пугач белән Салават яуларыннан калган хәнҗәр-

ләр, ук башлары да бар. Алар нефтьчеләр поселогы төзелгәндә табылган.

*1999 елда Чакмагыш районы Чакмагыш 1нче урта мәктәбенең туган якны өйрәнү музее материалларыннан Ирина Насыйрова күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 195; 1973 елда Чакмагыш районы Чакмагыш 1нче урта мәктәбендә туган якны өйрәнү музее оештырган укытучы Г. Воробьевның «Салават юлы» һәм «Салават каены» дигән язма материалларын һәм үзе өстәп сөйләгәннәрен берләштереп, Гайса Хөсәенов кәгазьгә теркәгән. – АЭМ, 1973. – 552–553 б.; БХИ РЛ, 1980, № 241; БХИ РЛ, 1997, № 293*

### 78. Әби патша юлы

Уфа һәм Оренбург шәһәрләрен Казан белән тоташтыручы олы юл Күктау авылы Иске йорттан күчкәннән соң төзелгән, диләр картлар. «Саз күпере»н чыгу белән, Яркәйгә борылышсыз барырга мөмкин булган. Юлның Иске Күктау аша үтүен авыл халкы үзе сорап алган, үзе үк аны төзегән. Эш беткәч, патшабикә Екатерина II шушы юлдан Екатеринбургка барган, һәм ул халык телендә «Әби патша юлы» дип атала башлаган.

*1997 елда Илеш районы Дөмәй авылында Фәния Гобәйдуллинадан (1932 елгы) БДУ студенты Гөлнур Гайсина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 192*

### 79. Каторжан юлы

Әлеге көндә Ишкар авылы аша Уфа – Казан трассасы үтә. Кайчандыр шушы юлны авылның уртасыннан Әби патша – Екатерина II үзе салдырткан булган. Ул вакытларда бу юлны авыл халкы «Каторжан юлы» дип йөрткән. Әби патша һәм башка патшалар тарафыннан Себергә каторгага җибәрелгән кешеләр бу юлны күп таптаган.

1866 нчы елда Николай патша Ишкар авылында мәчет төзергә рөхсәт бирә. Ул авылдан бер чакрым читтәрәк урнаша. «Каторжан юлы» читенә өч этап төзелә. Каторгага җибәрелгән юлчылар шул этапларда туктап, ял итә торган булганнар. 1922 нче елда бу этапларны сүтәләр һәм аның материаллары белән Сараяз елгасының сул як ярында кечкенә генә бер мәктәп

төзиләр. Авылдагы беренче укытучы Нәирә апа Шәмсетдинова була.

*1997 елда Илеш районы Кызыл Байрак авылында Мәликә Хөснуллинадан (1903 елгы) БДУ студенты Акчәчәк Хөснуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 194*

### 80. Йолдыз тавы

Базытамак һәм Йолдыз авыллары арасында Әрәкәс күле буйлап 3–4 чакрымга сузылган биек тау бар. Бу – «Йолдыз тавы».

Монда Пугачев Екатерина II армиясенә каршы сугыш алып барган. Бу тауда Пугачев гаскәрләренең корал калдыклары – кылычлар, мылтыклар күп табыла. Окоп урыннары да аермачык күренеп тора. «Йолдыз тавы»ннан торып, Пугачёв гаскәрләре Идел аръягыннан килә торган армиягә каршы сугышкан.

*1998 елда Илеш районы Яңа Күктау авылында Хәбибрахман Кәшбуллиннан (1910 елгы) БДУ студенты Рәйлә Нигмәтуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 204*

### 81. Кала тавы

«Кала тавы» Яңа Аю һәм Тартыш авыллары арасында, Агыйделнең сул ярында урнашкан. Ул Пугачёв сугышы вакытында оборона пункты булып хезмәт иткән. Шушы тауда торып, Пугачёв үзенә гаскәр җыйган. Кеше туплагач, ул башкорт гаскәрләре белән Агыйдел буйлап Казанга юл алган.

Пугачёв урыс һәм башкорт халыкларын дуслаштыру өчен тырышкан. «Кала тавы»нда әлегә кадәр бик күп сугыш кораллары табыла.

*1998 елда Илеш районы Яңа Күктау авылында Хәбибрахман Кәшбуллиннан (1910 елгы) БДУ студенты Рәйлә Нигмәтуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 205*

## *б) Җир биләүчеләр һәм җир өчен сугышлар турында*

### 82. Күҗмә зираты

Кайчандыр Күҗмә исемле кеше яшәгән. Ул елларда көферләр (урыслар) белән җир өчен бик күп сугышлар булган. Бервакытны бу җиргә марилар басып кергәннәр. Күҗмәнең бик

таза, матур кызы булган. Ул кызның беләкләре самавыр юанлыгы булган. Күҗмә шул кызы белән мариларга каршы сугышканнар. Марилар Куҗмәне кара канга туздырып киткәннәр. Аны үтердек, дип уйлаганнар. Күҗмә тау буенда ятып калган. Бераздан аңына килеп, кыймылдый башлаган.

Моны күреп, марилар яңадан килгәннәр. Күҗмә үзенең бер теләге барлыгын әйткән. Марилар аның теләген үтәгәннәр. Ул Гәрә буена төшеп яраларын юган, тәһарәт алып намаз укыган. Шуннан марилар аны үтергәннәр, һәм шул урында күмеп киткәннәр. Хәзер бу урынга «Күҗмә зираты» дип исем биргәннәр. Барлыгы анда – дүрт кабер.

*1977 елда Борай районы Абдулла авылында*
*Гыйлемхан Таһир улы Таһировтан (1907 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 83. Гәрәй имәнлеге

Патша вакытында Гәрәй Морадымов исемле кеше бик зур казна җирен юллап алып, халыкка бүлеп биргән. Үзе шушы урыннарның читенә имән агачлары утыртып чыккан. Бу имәнлекне халык әле дә «Гәрәй имәнлеге» дип атый.

*1998 елда Балтач районы Бигелде урта мәктәбе музее*
*материалларыннан БДУ студенты Фәндүс Фәхретдинов*
*күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 224*

## 84. Илекәй карт

Борын заманнарда Илекәй исемле карт Чыпчык авылыннан Ар елгасының уң ярына күчеп утыра һәм шунда Илекәй авылына нигез сала. Балтач картның улы Колый Балтачев моңа нык ачулана: «Бу минем җирләр. Моннан тиз арада чыгып ычкын! Әнә елганың теге ягына күчеп утыр!» – ди. Ләкин Илекәй аның сүзләрен тыңламый.

Ачуы чыккан Колый Илекәй авылына яу белән килә. Ул ялан уртасында чыгып баса да: «Кем дә кем, монда чыгып, минем белән көрәшергә риза?» – дип, Илекәй халкына кычкыра. Барысы да куркып калалар. Шулчак мәйдан уртасына Илекәй карт чыгып баса һәм көрәш башлана. Берсе дә күрмәгәндә, Илекәй

карт Колыйны чалып ега. Җиңелгәч, Колый үзенең кешеләре белән хурланып кайтып китә. Илекәй авылы халкы Ар елгасының уң ягында торып кала.

Үләр алдыннан Илекәй карт: «Мине Ар елгасының сул ягына күмегез. Мин Колыйны хәрәмләшеп чалып ектым. Ә чынлыкта, ул миннән көчлерәк иде», – ди.

Картның соңгы теләге үтәлә. Әле дә авыл халкы аның каберен хөрмәтләп тота.

*1997 елда Балтач районы Әхмәт авылында Рәис Сөләймановтан (1934 елгы) БДУ студенты Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 226*

## 85. Кала күле

Элек җир өчен сугышлар еш чыгып торган. Баш күтәрүчеләр сугыш коралларын шушы күл буенда калдырып китә торган булганнар. Шуңа да ул «Кала күле» дип атала икән.

*1998 елда Балтач районы Бигелде урта мәктәбе музее материалларыннан БДУ студенты Фәндүс Фәхретдинов күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 230*

## 86. Әдел тавы

Калмашбаш авылының көньяк-көнчыгышында «Әдел тавы» дигән урын бар. Картлар сөйләвенчә, элек биредә Әдел исемле кешенең утарлары, алма бакчалары урнашкан булган. Бу җирбиләүче бик зыялы, мәрхәмәтле кеше булган, хатыны авылда яшәүчеләргә урыс телен укыткан. Халык сөйләвенчә, алар бай булсалар да, бик игелекле кешеләр булганнар. Хезмәткәрләренә карата да кырыслык күрсәтмәгәннәр.

Дөньяда барган хәлләр белән яхшы таныш булган Әдел Октябрь революциясенә кадәр үк инкыйлаб җилләрен тоеп, биләмәләрен чит кешегә сата. Имеш, ул шул вакытта болай дип әйткән ди: «Мин котылдым, Шаһгали, ә син тотылдың».

Чынлап та, Шаһгалине «кулак» дип Себергә сөрәләр, ә Әделнең исеме саф кала.

*1999 елда Чакмагыш районы Калмашбаш авылында Хәдичә Галләмова-Кәлимуллинадан БДУ студенты Ирина Насыйрова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 217*

### 87. Әптерәү иннеге

Авыл читендәге ялан «Әптерәү иннеге» дип атала. Элек бу урында Әптерәү бабай җир тоткан. Аның үз урманнары, басулары, яланнары булган.

Совет власте безнеңякларга да килеп җиткәч, бабай «аклар» белән качып киткән, ә ул яшәгән урын халык телендә «Әптерәү иннеге» дип атала башлаган.

*1998 елда Илеш районы Иске Күктау авылында*
*Мәнкия Мулламөхәммәтовадан БДУ студенты*
*Айлия Хәмидуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 218*

### 88. Баяр бакчасы

Яңа Күктау авылы янында искиткеч гүзәл агачлык, саф сулы чишмәле бер урын бар. Халык аны «Баяр бакчасы» дип йөртә. Революциягә кадәр бу урында бик бай баяр яшәгән. Ул табигатьне нык яраткан, диләр. Баярның бик зур йорты, төрле җимешләр бирә торган матур бакчасы булган. Өе янында гына зур, саф сулы күл җәелеп яткан.

Ләкин авыл халкы аны яратмаган, байлыгына көнләшкән, баяр турында төрле ялган сүзләр чыгарган. Ахыр чиктә авыл халкы баярны асып үтергән.

Аның үлеменнән соң кешеләр баярның йортын да сүткәннәр. Бары тик шушы бакчасы гына утырып калган. Шул еллардан бирле ул бакча урнашкан урынны «Баяр бакчасы» дип атыйлар.

*1998 елда Илеш районы Карабаш авылында*
*Сания Хаҗиевадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 219*

### 89. Кәсәй тавы

Элек авылда Кәсәй дигән кеше яшәгән. Алар Дөмәй карт белән җир өчен бик еш сугышып торганнар. Дөмәйдән аерып, Кәсәй ул таулы җирне үзенә алган. Шул көннән алып, халык телендә бу тау – «Кәсәй тавы».

*1998 елда Илеш районы Тыпый авылында*
*Фәһимә Галиевадан (1925 елгы) БДУ студенты*
*Фәнүзә Шабаева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 232*

## 90. Нажы буе

Авылга нигез салган Рсай карт янына бервакыт, яшәргә җир сорап, Нажы исемле кеше килгән. Ләкин Рсай карт аңа бернәрсә дә бирмәгән, киресенчә, хуҗалыгы яныннан, биләмәләреннән куып җибәргән. Нажы карт, читкәрәк китеп, барыбер үз дөньясын корган. Хәзер ул җирләр «Нажы буе» дип атала.

*1998 елда Илеш районы Рсай авылында*
*Мәгъсүм Кашаповтан (1927 елгы) БДУ студенты*
*Айгөл Сәетова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 241*

## 91. Сугыш чокыры

Йонны авылы янындагы басуда «Сугыш чокыры» дип аталган бер тирән чокыр бар. Аның исеме, чыннан да, сугыш белән бәйле.

XIX гасыр азакларында булган бу вакыйга. Бөре өязеннән Йонны белән Рсай авыллары арасындагы җирләрне бүлергә землемерлар килгән. Алар: «Бу урын бик калын урман һәм бик тирән чокырлардан гына тора», – дип, 13–14 гектар җирнең кайсы авылга караганын ачыкламыйча, мижа билгесен күрсәтмичә калдырганнар.

Шуннан ике авыл халкы арасында бу җир өчен бик күп ызгышлар, ачу-талашулар башланган. Бәхәсне хәл итәр өчен, халык ит, май, бал кебек күчтәнәчләр җыеп, Бөре шәһәреннән кабаттан землемерлар чакырган. Землемерлар бәхәсне аларга бүләккә җыелган акча, күчтәнәчләр күләменә карап хәл иткәннәр. Кайсы авылның күчтәнәчләре күбрәк, бәхәс шулар файдасына хәл ителгән. Бу хәл берничә мәртәбә кабатланган.

Җир күп тапкырлар әле Рсай, әле Йонны авылына күчеп йөргәннән соң, ике авыл халкы бәхәсне кул көче белән хәл итәргә була. Сугыш көне билгеләнә. Барлык ир кешеләр, күсәкләр белән коралланып, әлеге чокыр янына җыелалар. Алар арасыннан иң көчлеләре – Йонны авылыннан «Атаман» кушаматлы Мөхәммәтдин Зәйнетдинов һәм Рсай авылыннан Әхмәтдин исемле кешеләр кара-каршы сугышалар. Дәгъвалы җир сугышта җиңүче кулына күчәргә тиеш була. Шушы урында Йонны авылы «атаманы» Мөхәммәтдин Рсай авылы кешесен тукмап үтерә.

Шулай итеп, ике арада каты сугыш башланып китә. Йонны авылы халкы Рсай кешеләрен кара канга батырып, авылларына җиткәнче куып китәләр һәм сугышта җиңүче булып танылалар. Ә теге 13–14 гектар чамасындагы җир шул көннән башлап «Сугыш чокыры» дип атала һәм Йонны авылы халкы кулына күчә.

*1998 елда Илеш районы Йонны авылында*
*Рүзил Мәгъдәновтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 248*

### 92. Яшь барыня урманы

Элек бу урман урынында бер бай бояр яшәгән. Аның үз заводы да булган. Ул якын-тирәдә беренче булып көлтә ура торган машина алып кайткан. Бу машинаны чит илдә чыгарганнар. Сыерлары да күп булган. Аларны карар өчен, ул хезмәтчеләр тоткан. Әнисә әби, Рәхимә әби шушы сыерларны тәрбияләгәннәр. Захар карт боярның иң яхшы хезмәтчесе булган. Ул башта тимерче булып эшләгән, соңыннан боярның кучеры булып киткән.

Бояр нык итеп кызын яраткан. Аңа бер нәрсә дә жәлләмәгән. Кызына дип, үз өе янына зур кирпеч йорт төзеткән. Шуннан бирле бу урын «Яшь барыня урманы» дип атала.

*1998 елда Илеш районы Лена авылында*
*Мисбах Хәбировтан (1930 елгы) БДУ студенты*
*Галия Каһирова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 259*

### 93. Җир сату

Хәзерге Бөре шәһәре, Лачынтау авылы урнашкан җирләр элек Мәскәү авылы халкы карамагында булган. Югары дәрәҗәле картлар шушы җирләрне бер тәкәгә һәм бер чирек аракыга сатып җибәрәләр. Азактан кире уйласалар да, соң була. Землемер килеп, авыл җирләрен кисеп ала. Шулай итеп, Мәскәү авылы биләмәсе кечерәя.

*1998 елда Дүртөйле районы Мәскәү авылында*
*Тәнзилә Хуҗинадан (1931 елгы) БДУ студенты*
*Дилара Фәттәхова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 225*

### 94. Аю җире

Бик элек Татарстанның Аю дигән авылыннан берегә кешеләр күчеп килә һәм Мирзаит авылы тирәсендәрәк җирдә

урнаша. Лəкин, ни сəбəптəндер, алар монда озак яши алмыйча, кире кайтып китəргə мəҗбүр булалар. Ә тормыш көткəн урыннары шуннан бирле «Аю җире» дип атала.

*1997 елда Бакалы районы Мостафа авылында*
*Мөнирҗан Йосыпов (1924–1993) истəлеклəреннəн БДУ студенты*
*Светлана Медведева күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 551*

## *в) Миллəтара, динара мөнəсəбəтлəр, ыру, сословие атамалары белəн бəйле риваятьлəр*

### 95. Башкорт очы, Түбəн очы

Ихсан авылының җирле халкы элек башкортлар булган. Соңрак монда Пенза якларыннан татарлар килеп утырганнар. Татарлар белəн җирле халык арасында җир-су өчен һəрвакыт көрəш барган, сугышлар килеп чыккан. Шуның нəтиҗəсендə, башкортлар əлеге «Башкорт очы»на күчеп утырганнар. Хəзер анда татарча сөйлəшəлəр. «Түбəн очы»нда исə Пенза өлкəсеннəн килгəн татарлар яши. Алар элек башкортлар эшкəрткəн җирлəрне басып алганнар һəм аларны «түбəннəр» дип атаганнар. Шулай итеп, Иске Ихсан авылы икегə бүленеп, икенче очы «Түбəн очы» дип аталган. Бу оч халкы əле дə түбəннəргə хас итеп сөйлəшə.

*1970 елда Чакмагыш районы Бəшир авылында Гражданнар сугышы*
*һəм Бөек Ватан сугышы ветераны, элекке колхоз рəисе*
*Мəсəлим Гəрəевтан (1899 елгы) БДУ студентлары язып алган*

### 96. Башкорт урамы

Иштирəк авылы урнашкан җиргə беренче булып татарлар килеп утырган. Алар үзлəре бер кечкенə авыл хасил иткəннəр. Соңыннан монда яшəү өчен уңайлы урын эзлəп йөрүче башкортлар да килə. Алар безнең якларны бик ошаталар. Иштирəк авылы халкы Көрпə елгасының икенче ягындагы җирлəрне башкортларга бирə. Башкортлар авылның икенче яртысы булып, бер озын урам ясап урнашалар. Соңыннан алар яшəгəн урам «Башкорт урамы» дип атала башлый.

*1998 елда Илеш районы Иштирəк авылында*
*Зөлфирə Ногмановадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 263*

### 97. Типтәр басуы

Билгеле булуынча, Янтуган авылында төрле милләт вәкилләре яшәгән: башкортлар, типтәрләр, татарлар һ.б. Аларның һәркайсының үзләренә аерым зиратлары булган. Соңрак типтәр зираты урнашкан җирләрне сөреп, басуга әйләндергәннәр. Шуңа күрә авыл янындагы бер басу «Типтәр басуы» дип атала.

*1998 елда Илеш районы Югары Яркәй авылында Салих Басыйровтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 265*

### 98. Типтәр ягы

Элекке вакытта, җир гаиләдәге ир-ат санына карап бирелгәндә, сазлык авылны икегә бүлеп торган. Аның бер ягында типтәрләр, ягъни җирсез халык яшәгән. Алар башкалардан үзләре бер төрле булып аерылып торганнар.

Типтәрләргә җирне дә бик әз биргәннәр. Алар яшәгән урын әле дә «Типтәр ягы» дип йөртелә.

*1998 елда Илеш районы Иске Куктау авылында Нәфисҗамал Гыйльметдиновадан БДУ студенты Айлия Хәмидуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 267; «Типтәр җире» – 1997 елда Бакалы районы Мостафа авылында Мөнирҗан Йосыпов (1924–1993) истәлекләреннән БДУ студенты Светлана Медведева күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 266*

### 99. Казакъ тау башы

Элек авылга мордва, казакъ, нугай халыклары күчеп килә торган булган. Казакъ хатыннары аяк тиңентен озын күлмәкләр киеп, башларына ак сөлгеләр урап, күп булып җыелышып, әкрен генә урак урырга барганнар. Үзләре:

*Нугайлар дим, барсы бара,*
*Татарлар дим, берсе юк, –*

дип җырлаганнар да әле, җитмәсә.

Казакъ хатыннары игеннең һәр сабагын берәмтекләп тотып урганнар. Шуңа да татар хатыннарының һәрберсе иллешәр көлтә әзерләгәндә, болар көн буена көч-хәл белән өч-дүрт көлтә җыйный иделәр.

1930 нчы еллар башында ул халыклар үз җирләренә кайтып киттеләр. Ләкин алар яшәгән урыннар әле дә «Казакъ тавы башы», «Мордва җире» дип атала. Казакъ җырларыннан бер дүртьюллык та истә калган:

*Ак тавыгым б-а-а-р иде,*
*Йомыркасы с-а-а-р иде,*
*Канды булган җиремнең*
*Ике күзе к-а-а-р иде.*

*1998 елда Илеш районы Иске Куктау авылында*
*Мәнкия Мулламөхәммәтовадан БДУ студенты*
*Айлия Хәмидуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 273*

### 100. Бетле саз

Яркәй рус-төрек сугышында аеруча зур батырлык күрсәтә. Моның өчен ул урыс гаскәр башлыгы П.А. Румянцев тарафыннан «Георгий тәресе» белән бүләкләнә. Шуңа өстәп, аңа җир дә бирелә.

Ул заманнарда Ислам диненең көчле йогынтысы астында яшәгән халык урыс тәресенә зур нәфрәт белән караган, шуңа күрә Яркәй «Георгий тәресе»н күкрәгенә тага да алмаган, сандык төбенә яшереп саклаган. Яшерелгән тәрене күргән хатыны: «Көфер белән яшимен», – дип куркып, тәре турындагы хәбәрне этисе Череккүлгә җиткергән.

Череккүл карт, үз чиратында, кеше яллап, Яркәйне үтерткән. Үтерүчеләрне хаклы җәзага тарттырыр өчен, Яркәйнең бертуганы Куктау суд юлларында йөреп караса да, файдасы тимәгән. Авыл халкы Яркәйнең мәетен Куктау авылыннан дүрт-биш чакрым ераклыктагы сазлыкка илтеп ташлаган. Аның гәүдәсе сазлыкта череп, кортлап яткан.

Шуннан соң халык бу урынга «Бетле саз» дигән исем кушкан. Соңрак, юл төзегәндә, сазлык аша күпер салганнар. Аңа халык «Бетле күпер» дигән исем кушкан. Бу атама бүгенге көнгә кадәр саклана.

*1997 елда Илеш районы Дөмәй авылында*
*Фәния Гобәйдуллинадан (1932 елгы) БДУ студенты*
*Айлия Хәмидуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 280*

### 101. Мариларны куу

1914 нче елда Мәскәү авылына марилар килеп урнаша. Әле дә аларның өй урыннары бар. Ләкин авыл халкы аларны бер дә шатланып каршы алмый. Мәскәүлеләр чит телле, чит динле мариларны һич яратмыйлар, аларның сыер-сарыкларын суялар, ә үзләрен кыйныйлар, мәсхәрәлиләр. Нәтиҗәдә, марилар Озын Ялан авылына күчеп китәргә мәҗбүр булалар.

*1998 елда Дүртөйле районы Мәскәү авылында Тәнзилә Хуҗҗинадан (1931 елгы) БДУ студенты Дилара Фәттәхова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 225*

### 102. Кыргыз бүләге җире

Элек монда кыргызлар яшәгән. Туган якларына кайтып киткәндә, алар бу җирләрне Мостафа авылы халкына бүләк итеп калдыралар. Шуннан бирле бу урыннар «Кыргыз бүләге» дип атала.

*1997 елда Бакалы районы Мостафа авылында Мөнирҗан Йосыпов (1924- 1993) истәлекләреннән БДУ студенты Светлана Медведева күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 276*

### 103. Тушкыр суы, Көсәк күл

Элек башкортлар, туганнарын чакырганда, ат суеп, ат ите беткәнче ашатып, кунак итә торган булганнар. Бервакыт Кыйгазы башкорты Кайпан башкортына тай суеп кына ашаткан. Тай гына суеп ашатканга, Кайпан башкортының бик ачуы килгән.

Кунак иткәч, Кыйгазы башкорты Кайпан башкортын бер марый проводник белән пар ат җиктереп озаткан. Кайпан башкорты Кыйгазы башкортының исемен бетерәем дип, марый проводникны үтергән дә, аягына җип тагып, чанага бәйләп, түше белән сүрәтеп алып киткән. «Моны кайда илтеп бәрергә икән? – дип уйлап барган. Проводникның башын тау астыннан чыккан чишмәгә бәргән һәм бу чишмә «Көсәк чишмә» дип аталган, чөнки марыйның исеме Көсәк булган.

Шуннан соң Кыйгазы суын «Түшен ышкыр» исеме белән атый башлаганнар. Бу исем, тора-бара, «Тушкыр» булып киткән.

Кыйгазы суының исеме «Тушкыр»га әйләнеп, Тушкыр елгасы чыккан урынга «Тушкырбаш» исеме бирелгән. Хәзерге вакытта Кыйгазы суын Тушкыр дип кенә йөртәләр.

*1964 елда Балтач районы Тушкыр авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

### *г) Караклар һәм качкыннар хакында*

### 104. Кизгән сазы

Бу зур булмаган сазлык үз исемен 1928 елда алган, дип сөйли картлар. Егерменче елларда Югары Карышта Казыйхановлар бандасының «даны» чыккан була. Алар безнең авыл халкына гына түгел, тирә-як авылларга да зур зыян салганнар. Хакый Атзитаров дигән юлбасарның бигрәк тә куркыныч, канэчкеч кеше булуы турында сөйлиләр иде.

1928 елда шушы банда Борай районы Кизгән авылыннан Яңа Урыс авылы ярминкәсенә баручы бер сәүдәгәрне сагалап торып, аны үтерә һәм гәүдәсен шушы сазга ташлап китә. Шуннан бирле бу сазлык «Кизгән» исеме белән аталып йөри.

1930 нчы елларда банда тармар ителә.

*1998 елда Балтач районы Карыш авылында укытучы*
*Асия Гата кызы Хариповадан (1945 елгы) БДУ студенты*
*Фәнүзә Садыйкова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 289*

### 105. Гайнетдин чокыры

Рапат авылында элек Гайнетдин исемле кеше яшәгән. Бар яктан да аңлы, сәләтле булган ул. Йөзе матур, сүзе татлы икән, кешеләрне бер карауда үзенә тарткан. Аны барысы да яраткан. Беркем дә аның кире якларын күрмәгән.

Чынлыкта исә, Гайнетдин җиңел юл белән баюга исәп тоткан. Аның бик яхшы, өйрәтелгән эт шикелле аты булган. Шул аты белән Гайнетдин ераклардан сарык, кәҗә һәм башка төрле терлекләрне бик оста итеп урлаган.

Авыл читендә тирән чокыр булган. Кешеләр аны читләтеп үтә торган булганнар, нәрсәдәндер шикләнгәннәр. Гайнетдин шушы чокырда урланган малларны чалган. Урлашканда, аты-

ның дүрт аягына да чабата кидерә торган булган. Бу ат эзен яшерү өчен эшләнгән. Хәзер Гайнетдин юк, ә чокыр әле дә бар, аны һаман да «Гайнетдин чокыры» дип йөртәләр.

*1999 елда Чакмагыш районы Рапат авылында*
*Зөләйха Хәбировадан БДУ студенты Ирина Насыйрова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 285*

### 106. Әпес тавы

Исәнбай авылында элек Әпес исемле кеше яшәгән була. Бервакыт ул Игъмәт авылына юлга чыга. Ләкин, юлданиндидер хәл булып, ул шушы таудагы урманга качып китә. Авыл халкы аны барыбер тотып ала.

Бу урман инде күптән киселеп, урыны сөрелеп беткән, ләкин халык кайчандыр ул урнашкан тауны һаман да «Әпес тавы» дип атый.

*1998 елда Илеш районы Рсай авылында*
*Мәгъсүм Кашаповтан (1927 елгы) БДУ студенты*
*Айгөл Сәетова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 282*

### 107. Яркәй тавы

Хәзерге Яркәй авылы янындарак «Яркәй тавы» дигән урын бар. Аның тарихы мондый.

Элек патша хөкүмәте халыкка бик авыр салым салган. Яркәй исемле кеше җитәкчелегендәге авыл халкы салым җыючыларны тукмап, куып җибәргән. Озак та үтми, хөкүмәтнең кораллы гаскәрләре килгәч, Яркәй авылны ташлап, шушы тауга качып киткән. Ул шушында тау куышында качып яткан. Ләкин патша гаскәрләре Яркәй качкынны барыбер тотып алганнар. Шуннан бирле бу тауны «Яркәй тавы» дип йөртәләр.

*1998 елда Илеш районы Иштирәк авылында*
*Кашбелгаян Ногмановтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 296*

### *д) Социаль һәм милли изү фаҗигаләре хакында*

### 108. Баяс урманы

Элек безнең якларда ике дус яшәгән. Берсен Баяс дип атаганнар. Ләкин биредә яшәүче байлар егетләргә иркенләп яшәргә

ирек бирмәгән, төрлечә кысрыклаган. Егетләр моңа түзә алмыйлар һәм, бу байларны талап, казакъ далаларына качалар. Ләкин алар анда да урын тапмыйлар һәм көньякка, Сэди елгасы ягына, юлларын дәвам итәләр. Ләкин Баясның дусты: «Ике тәкә башы бер казанга сыймый», – ди дә юлдашыннан аерылып китә.

Ә Баяс Сэди елгасы янында туктап кала. Биредә ул көтү көтә, сарыклар үстерә. Әмма монда да озак тора алмый, казакълар аны куып җибәрәләр.

Баяс бик озын ил гизеп йөргәч, кире Танып буйларына килеп чыга һәм шунда яшәргә кала. Ул яшәгән урынны халык әле дә «Баяс урманы» дип йөртә.

*1997 елда Борай районы Борай авылында*
*БДУ студенты Луиза Усаева язып алган.*
*Информаторы билгесез. – Фазлетдинов, 2018, № 299*

### 109. Саклау урманы

Бу урман авылга бик якын урнашкан, ләкин аны урманчылар беркайчан да кисәргә рөхсәт итмәгәннәр. Хәтта чабатага юкә кайрысы алырга да ярамаган. Сугыш елларында урманчы Ибрай Вилданов бик күп балаларның чабата юкәләрен чапкалап, балталарын тартып алып калган. Утынны халык авылдан унбиш чакрым ераклыктагы Яңа Штәнде урманлыгыннан кисәргә тиеш булган. Анысы да – черек, яки корыган чыршы.

Хрущев заманнарында Борай районы белән кушылгач, бу урманны ике ел эчендә читкә ташып бетергәннәр. Урман юкка чыкса да, иске заманнарны истә тотып, ул урнашкан урынны «Саклау» дип йөртәләр.

*1997 елда Балтач районы Әхмәт авылында*
*Рәис Сөләймановтан (1934 елгы) БДУ студенты*
*Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 318*

### 110. Вафа буасы

Элек бу буада дүрт ташлы тегермән корылган була. Янында ашлык саклар өчен келәт салына, атлар өчен лапас, кеше кунар өчен йорт та төзелә. Көз көне, ашлык җыелгач, моннан кеше өзелми.

Бервакыт бу тегермәнне Вафа исемле бай сатып ала. Әмма ул аны эшләтеп җибәрә алмый. Ачуыннан бай тегермәнгә ут төртә. Бар әйбер янып бетә, ә Вафа үзе авылдан качып китә. Шуннан бирле бу урын «Вафа буасы» дип атала.

*1998 елда Илеш районы Рсай авылында*
*Мәгъсүм Кашаповтан (1927 елгы) БДУ студенты*
*Айгөл Сәетова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 300*

## 111. Мәчет саклавы

Элек бу җирдә үскән агачларны мәчет миченә ягар өчен генә кисеп алганнар, ә болай ботагына да тияргә ярамаган. Шуңа күрә ул «Мәчет саклавы» дигән исем алган.

*1998 елда Илеш районы Тыпый авылында*
*Фәһимә Галиевадан (1925 елгы) БДУ студенты*
*Фәнүзә Шабаева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 306*

## 112. Сәгъдәт кулы

Бу вакыйга революциягә чаклы булган. Авылда һәр кешегә җир бүлеп биргәннәр. Сәгъдәт исемле иргә дә бераз җир тәтегән. Ул шунда ашлык чәчкән-урган, кыскасы, гаиләсен туйдырган. Җир башта бик күп ашлык биргән, ләкин тора-бара уңыш кими башлаган, чөнки ашлама җитешмәгән. Сәгъдәтнең гаиләсе ачтан интегә башлаган.

Бик күп уйланулардан соң Сәгъдәт шахтага эшкә китәргә карар иткән. Авылдан бераз ерагайгач, ул артына борылып караган. Карашы элек үзе эшкәрткән җирләргә, яшәгән өенә төшкән. Җире буп-буш, өе дә «менә җимереләм, менә җимереләм» дип тора икән. «Бер-ике елдан соң монда Сәгъдәт дөньясыннан бернәрсә дә калмаячак. Исемем дә онытылачак», – дип күңелсез уйларга бирелгән ир. Ул борылып кире кайткан да буш яткан җирләренә үз куллары белән агачлар утыртып чыккан. Еллар үтү белән, монда куе урман үсеп чыккан. Хәзер ул урман «Сәгъдәт кулы» дип атала.

*1998 елда Илеш районы Иштирәк авылында*
*Зөлфирә Ногмановадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 309*

### 113. Шәмсия чокыры

Бу чокыр тарихы биш партизан язмышы белән тыгыз бәйләнгән. Шәмсия исемле хатынның олы улы, дилбегә эшләр өчен, Дөмәй авылына ике дустын ияртеп кайткан була. Байлар, боларның дилбегә ясаганнарын күреп, аларга ат урлау гаебен тагалар. Авыл белән җыелышып, аларны тереләй бер чокырга күмәләр. Шулай итеп, Шәмсия, аның ике улы һәм дуслары тереләй җир кочагына кереп ята.

Хәзер бу чокыр «Шәмсия чокыры» дип атала. Әлеге вакытта бу җирдә зират урнашкан.

*1997 елда Илеш районы Дөмәй авылында*
*Фәния Гобәйдуллинадан (1932 елгы) БДУ студенты*
*Гөлнур Гайсина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 313*

### 114. Хәдичә урамы

Хәдичәнең әти-әнисе ярлы булган. Җәй җитсә, әтисе бай малын көткән, кышкы чатнама суыкларда утын-печән ташыган. Әнисе байбичәнең керләрен юган, йон эрләгән, мал-туарын караган. Ләкин ничек кенә тырышып эшләсәләр дә, өс-башлары – киемгә, тамаклары икмәккә туймаган.

Менә шундый авыр тормышта җәфа чигә алар. Ә бервакыт, көтмәгәндә суык тидереп, башта Хәдичәнең әтисе, аннан әнисе үлеп китә. Җиде яшьлек кыз ятим торып кала. Хәзер инде Хәдичә әрсез байбичәнең йомышчысына әйләнә. Йөгереп йөреп, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләрен эшли.

«Ятим балага шул да ярар әле», – дип, аның өстенә иске-москы кием кидерәләр. Күп вакыт ул яланаяк йөри.

Тормышы нинди генә авыр булмасын, унҗиде-унсигез яшьләргә җиткәндә, Хәдичә бик матур, сылу кыз булып өлгерә. Бер ярлы егет, Хәдичәне өзелеп яратып, кәләшлеккә сората. Ләкин байбичә моңа каршы төшә. Шундый җегәрле асрауны кулыннан ычкындырырга теләми ул.

Ләкин Хәдичә озак яши алмый, яшь кенә килеш, дөнья рәхәтен күрмичә, әти-әнисе кебек үк салкын кыш көннәрендә суык тидереп, урамда дөнья куя. Бу урам хәзер «Хәдичә урамы» дип атала. Егет, сөйгәненә багышлап, җыр чыгара:

*Иртәнчәк мин торып, тышка чыксам,*
*Салмак кына, салмак кар ява,*
*Ятим кыз, мескенем, Хәдичәм.*
*Таң алдыннан торып, бер кыз эшли,*
*Аяккаен күреп эчләр яна,*
*Сөеклем син минем, Хәдичәм.*
*Сандугачлар сайрый, таллар сайлый,*
*Тал булмаган җиргә ник кунсын,*
*Җанкисәгем минем, Хәдичәм?*
*Яшьли ятим калган кыз баланың*
*Бәхеткәйләре лә ник булсын,*
*Бердәнберем минем, Хәдичәм?*

*1998 елда Илеш районы Яңа Күктау авылында Гөләмдәм Садретдиновадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 604*

## ***ж) Гражданнар сугышы турындагы риваятьләр***

### **115. Смак күле**

Бу күлнең исеме 1918–1919 нчы елларда барлыкка килә. Шул чорда безнең тирәләрдә гражданнар сугышы бара. Авыл берничә мәртәбә бер кулдан икенче кулга күчә.

1919 елның мартындагы бер сугышта күп кенә солдатлар һәлак була. Мөселман егетләрен зиратка күмәләр, ә чит диннән булган ике солдатны авылдан читтә, шушы күл буена җирлиләр. Ул солдатларның берсе Смак исемле була. Аларның каберләре хәзер басу астында калып, сөрелеп беткән инде, ә күл һаман «Смак» исемен йөртә.

*1998 елда Балтач районы Карыш авылында Асия Гата кызы Хариповадан (1945 елгы) БДУ студенты Фәнүзә Садыйкова язып алган.. – Фазлетдинов, 2018, № 334*

### **116. Солдат күпере**

Гражданнар сугышы вакытында кызылармеецлар авылда күпер төзегәннәр. Араларыннан берсе, шаяртып:

– Нигә генә салдыралардыр инде бу күперне? Барыбер, «аклар» килгәч, алар кулына күчәчәк бит! – дигән, имеш.

Шушы сүзләре өчен солдат гаепләнә һәм атып үтерелә. Шул вакыйгадан бирле бу күпер «Солдат күпере» дип атала.

*1998 елда Балтач районы Бигелде урта мәктәбе музее материалларыннан БДУ студенты Фәндүс Фәхретдинов күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 336*

## 117. Солдат имәнлеге

Гражданнар сугышы вакытында безнең яктагы күп авыллар аша «аклар» һәм «кызыллар» гаскәре үткән. Авыл халкы җиткән кызларны базларда, абзар түбәләрендә качырып, «аклар»-дан саклаганнар. Чөнки «аклар» «кызыллар» яклы авылларны яндырып көлгә әйләндергәннәр, кызларны мәсхәрәләгәннәр.

1918 елда Яңабирде авылы аша да «аклар» үткән. Бик күп кешеләр, солдатлар корбан булганнар. Үлүчеләрнең исәбе-хисабы булмаган. Мәетләрне чокырларга тутырганнар. Имән урманының көнбатыш ягындагы бер урынга кырыктан артык солдат мәетен күмгәннәр. Халык канлы яшь түккән, көн караңгы төнгә әйләнгән. Кайгы-сагыштан кешеләр эшләмәс булганнар. «Мондый коточкыч көннәрне бүтән күрсәтмә», – дип, Ходайга ялварганнар. Шуннан соң бу урын «Солдат имәнлеге» дип атала башлаган.

*1999 елда Чакмагыш районы Чакмагыш авылында Госман Мөсәлләмовтан БДУ студенты Ирина Насыйрова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 335*

## 118. Бетле күпер

Исәмәт урманы янындагы бер урын «Бетле күпер» дип атала. Гражданнар сугышы елларында бу урманга төрле яклардан качкан кешеләр килеп, яшеренеп ятканнар. Ә әле «Бетле күпер» дип аталган урында көтүе белән чегәннәр дә торып киткәннәр. Юынмыйча, киемнәрен алыштырмыйча айлар буе яшәгәнлектән, алар бетләп беткәннәр. Авыл халкы, бет йоктырудан куркып, монда якын да килмәгән.

Чегәннәр киткәч тә, алар яшәгән җирне халык «Бетле күпер» дип атаган. Бу исем әле дә саклана.

*1998 елда Илеш районы Иске Күктау авылында Мөнәздәха Хәмидуллинадан (1920 елгы) БДУ студенты Айлия Хәмидуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 322*

### 119. Гәверлә кыры

Революциягә кадәр бу җирләр Гаврила бай кулы астында була. Гражданнар сугышы башлангач, ул үзенә кечкенә гаскәр җыеп, «кызылларга» каршы сугышып, якын-тирә урманнарда качып йөри. Кырның исеме дә шуннан калган.

*1998 елда Илеш районы Үрмәт авылында*
*Сөгъдә Яһүдинадан БДУ студенты Рөстәм Хисаметдинов*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 323*

### 120. Сәет тавы

Элек авылда Сәет исемле революционер яшәгән. Гражданнар сугышы вакытында «аклар» бу тирәне басып алгач, ул шушы тауга качып киткән. Авыл кулаклары аны барыбер эзләп тапканнар һәм үтергәннәр. Шуннан бирле тау «Сәет тавы» дип атала.

*1998 елда Илеш районы Үрмәт авылында*
*Сөгъдә Яһүдинадан БДУ студенты Рөстәм Хисаметдинов*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 333*

### 121. Чучак тавы

Югары Яркәй янындарак урнашкан тауны халык «Чучак тавы» дип атый. Гражданнар сугышы елларында «аклар» белән «кызыллар» шушы тауда бәрелешкәннәр икән. Тауның исеме дә шуннан калган, ди.

Биек тау итәгендә нарат агачы үсеп утыра. Аның кайрысына «Отряд командиры Чучаков» дип язылган. Бу командир шушы тау башындагы сугышта һәлак булган икән. Күрәсең, кабере дә шул нарат төбендәдер. Тау әле дә командирның исеме белән, «Чучак тавы» дип йөртелә.

*1998 елда Илеш районы Югары Яркәй авылында*
*Җиһанур Баһаветдиновадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 340*

## *ж) Идел-Урал буйларында 1921 – 1922 еллардагы ачлык фаҗигаләре турында*

### 122. Җиде каен

«Ач кешенең ачуы яман», – диләр. Бик дөрес сүзләр бу. Моны исбатлаган хәл 1921 нче елда була.

...Бер хуҗаның тана бозавы югала. «Тананы урлаган» дип, башта бер кешене гаеплиләр. Ул: «Мин алмадым, тимәдем синең бозавыңа», – дигәч, гаепне икенче берәүгә салалар. Шулай итеп, җиде кеше шик астына алына. Күпмедер вакыт үткәч, «бүтәннәр урлашмас өчен, барысына да сабак булыр» дип, аларны тереләй күмәргә булалар.

Үзләреннән зур чокыр казыталар, җидесен дә шунда төртеп төшерәләр. Чокырдан чыгарга тырышканнарны без белән пешеклиләр. Туйганчы җәзалап, тереләй күмеп, кайтып китәләр.

...Берничә көн үткәч, теге кешенең танасы үзе кайтып керә. Ләкин эш инде узган була...

Берничә елдан соң, җиде кешенең кабере өстендә җиде каен үсеп чыга. Әле дә Саклау урманында алар шаулый-шаулый үсә. Бер дә юкка җәзалап үтерелгән җиде кешенең каберләре югалмасын дип, Аллаһы Тәгалә ул каеннарны үзе үстергәндер инде. Штәнде авылы халкы аларны күз карасыдай саклап тота.

*1997 елда Балтач районы Штәнде авылында*
*Мәсәгудә Такиевадан (1935 елгы) БДУ студенты*
*Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 344*

### 123. Челтер чишмә

1921 нче ел... Ачлык... Алты яшьлек бер кыз Штәндедән Әрдәгешкә җиләк җыярга дип килә. Инде ничә көн ашамаганлыктан, хәле бетеп егыла. Азрак яткач, торып җиләк ашап та карый. Ләкин хәле беткәннән-бетә генә бара, ярдәмгә чакырырга якын-тирәдә кеше дә булмый. Кыз үлә. Авыл халкы аны шул үлгән урынына җирли.

Күпмедер вакыт үткәч, аның кабереннән чишмә ургылып килеп чыга. Кешеләр бу хәлгә аптырыйлар. Әле дә ул чишмә челтер-челтер агып ята. Бәлки, ул чишмә бер гөнаһсыз сабыйның өзелгән гомерен дәвам итәдер. Кем белә...

*1997 елда Балтач районы Штәнде авылында*
*Мәсәгудә Такиевадан (1935 елгы) БДУ студенты*
*Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 345*

ТОПОНИМИК РИВАЯТЬЛӘР

### *җ) Халыкның шөгыле, тормыш көтү, яшәү рәвеше, йола һәм гореф-гадәтләре турында*

### 124. Силдиби күл

XVII гасыр азакларында Карыш авылы нигезләнгәч, авыл кешеләре тирә-якны тикшереп өйрәнә башлыйлар. Чөнки авыл бу вакытта кара урман эченә урнашкан булган. Кильмай Бикбуринның улы Силдиби ук-садакларын алып, ауга чыгып китә һәм урман эчендәге бер зур күлгә тап була. Аккошлар, үрдәкләр, кыр казлары күп булган бу күл авылдашларымның ауга йөри, балык тота торган урынына, гомумән, халыкның яшәү чыганагына әйләнә.

Күлне аңа беренче тап булган кеше исеме белән йөртә башлыйлар. Ул бик тирән, хәзер тирә-ягындагы урманнар киселеп бетеп, ул ялан уртасында калды, ә заманында, авылга мәчет төзегәндә, агачны шул тирәдән генә алганнар. 1798 елда патша мәчетләр салырга указ чыгарганнан соң, агачлар шул тирәдән генә киселгән, дип сөйлиләр иде авылның аксакаллары.

*1998 елда Балтач районы Карыш авылында укытучы Асия Гата кызы Хариповадан (1945 елгы) БДУ студенты Фәнүзә Садыйкова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 420*

### 125. Гөлчирә чокыры

Элек авырлы хатын-кызлар да урак урырга, печән чабарга йөргән икән. Авылдагы Гөлчирә исемле хатын шушы чокыр янында урак урып йөргәндә, тулгак тотып, кыз бала таба. Шуннан бирле бу чокырны «Гөлчирә чокыры» дип атыйлар.

*1998 елда Балтач районы Бигелде урта мәктәбе музее материалларыннан БДУ студенты Фәндүс Фәхретдинов күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 542*

### 126. Кашыкбаш урамы

Бу урам яныннан гына елга ага. Элекке заманнарда халык, аш ашагач, юарга иренеп, кашыкларын елгага төшереп, баугa элеп куя торган булганнар, икенче ашаганда гына алып менгәннәр. Еш кына кашыклар агып киткән яки югалган. Шушы

хәлләрдән соң гына кешеләр кашыкларын юып алып менә башлаганнар. Башка урамнарда мондый хәл булмаганлыктан, бу урамны «Кашыкбаш урамы» дип йөртә башлаганнар.

*1997 елда Балтач районы Әхмәт авылында*
*Рәис Сөләймановтан (1934 елгы) БДУ студенты*
*Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 564*

## 127. Салкын чишмә

Моннан күп еллар элек Иштирәк авылының Башкорт урамында Галләметдин Таҗетдинов исемле бер кеше яшәгән. Алар ягында су җитешмәгән. Кайсы җирдә генә кое казып карамаганнар, барыбер су чыкмаган. Чөнки бу як – таулы як.

Галләметдин бабай, урам халкына су табып бирмәкче булып, яхшырак урын эзләргә керешкән. Ниһаять, тапкан. Иштирәктән ерак түгел, урман авызында кое казыган. Аның суы шундый салкын, шундый тәмле булган ки, үткән-сүткән бер генә кеше дә аны авыз итмичә узып китә алмаган.

Галләметдин бабай кое янына таш куйган һәм аңа үзенең исемен чокып язган. Ташның бер читенә ул «Салкын чишмә» дип язып та куйган. Шуннан бирле бу коены «Салкын чишмә» дип атап йөртәләр.

Галләметдин бабай чишмәгә багышлап, шигырь юллары да чыгарган.

*Салкын чишмәнең сулары*
*Бигрәк татлы, тәмледер.*
*Туган, үскән җирләрем*
*Күк чәчкәдәй күкрәп тора –*
*Бигрәкләр дә ямьледер.*

*1998 елда Илеш районы Иштирәк авылында*
*Кәшбелгаян Ногмановтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 365*

## 128. Фарсый буасы

Иштирәк авылын икегә бүлеп Көрпә елгасы ага. Урман янындарак ул буып алынган. Бу урын «Фарсый буасы» дип атала.

Буаны Фарсый берүзе тоткан. Ул монда бозауларны, көтүлектән сыерларны алып килеп, су эчерә торган булган. Буаның

суы бик чиста, балыклы, урнашкан урыны да ямьле икән. Кешеләр монда килеп су кергән, балык тоткан, Фарсыйга рәхмәт укыган. Шуннан бирле бу буаны «Фарсый буасы» дип йөртә башлаганнар.

*1998 елда Илеш районы Иштирәк авылында*
*Зөлфирә Ногмановадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 369*

### 129. Ялгыз каен басуы

Элекке заманнарда кешеләргә җир бүлеп бирә торган булганнар. Иштирәк авылыннан ерак түгел бер каенлык Гайса исемле иргә эләккән. Ул, басу эшләргә ниятләп, каеннарны кисеп бетерергә уйлаган. Ләкин, ни өчендер, бер матур гына каенны кисми калдырган. Каен үскән дә үскән. Көннәр, айлар, еллар үткән, аны кисәргә бер кешенең дә кулы бармаган. Шулай итеп, янындагы басуны да халык «Ялгыз каен басуы» дип атый башлаган.

*1998 елда Илеш районы Иштирәк авылында*
*Кәшбелгаян Ногмановтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 377*

### 130. Балкүмгән басуы

Кадер бабай кыргый бал кортларыннан бал җыеп көн күргән. Бал кортларын ул хәзерге кебек умарталарга түгел, ә агач тырысларга туплаган булган. Кышын кортлар туңып үлмәсен өчен, бабай тырысларны җиргә күмеп куйган. Ул урын «Балкүмгән чокыры» дип аталган. Хәзер инде бу урында зур басу. Ләкин басуның исеме шул ук, «Балкүмгән» булып калган.

*1998 елда Илеш районы Кадер авылында*
*Галимә Маликовадан (1918 елгы) БДУ студенты Физәлия Маликова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 384*

### 131. Баязит аланы

Баязит исемле бер ир-егет тау башындагы агачларны кисеп, үзенә утын әзерләгән, йорт-кура тергезгән, дип сөйлиләр. Киселгән агачлар урынында алан хасил булган. Авылга якын урнашканлыктан, яшьләр шушы аланга кичке уенга җыелып күңел ачканнар. Төрле йола бәйрәмнәрен дә шушында үткәргәннәр.

Шулай итеп, борыннан бирле бу урын «Баязит аланы» дип атала.

*1998 елда Илеш районы Кадер авылында Галимә Маликовадан (1918 елгы) БДУ студенты Физәлия Маликова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 386*

## 132. Гайнешлим табуры

Элекке заманда, явымлы ел булганда, Кадер авылы янындагы яланнан ашлыкны амбарга алып кайтып тормаганнар, чөнки ерак булган. Яланда ук, түбәсен ябып, бер ышык җир ясаганнар. Ул «табур» дип аталган. Ашлыкны шул табурга салганнар. Соңыннан гына чистартып, авылга ташыганнар. Табурның хуҗасы Гайнешлим исемле булган (минем ерак бабай ул). Бу яланны хәзер дә «Гайнешлим табуры» дип йөртәләр.

*1998 елда Илеш районы Югары Яркәй авылында Әбәдия Габдрахмановадан БДУ студенты Флорида Гыйльванова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 390*

## 133. Гайса каены

Элекке заманда Иштирәк авылында Гайса исемле бер көтүче яшәгән. Ул малларны иртә таң белән авылдан алып чыгып китә торган булган. Каенлыкта мал-туар җыя торган махсус урын да ясап куйган. Көтүен ул шунда туплаган. Ә үзе читтәрәк торган бер каен янына утырып ашаган, ял иткән. Шул каен төбеннән ул көтүен: «Һ-а-а-й!» – дип кычкырып кузгаткан. Аның тавышы авылга хәтле ишетелеп торган. Шуннан башлап бу ялгыз каенны «Гайса каены» дип йөртә башлаганнар.

*1998 елда Илеш районы Иштирәк авылында Кашбелгаян Ногмановтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 391*

## 134. Кәҗә, Мишәр, Мөгәҗәй урамнары

Тыпый авылын, гадәттә, өч зур урамга бүләләр: Тау як урамы, Үзәк-урта урам, Аръяк урам. Тау ягы урамының бер очы халык телендә «Кәҗә урамы» дип йөртелә. Ә ни өчен соң?

Элек бу урамда бер карт яшәгән. Ул бик күп кәҗә асраган, шуңа да аны Кәҗәкәй карт дип йөрткәннәр. Урамның исеме дә шул заманнардан калган.

Үзәк-урта урам Мишәр һәм Мөгәҗәй очларына бүленә. «Мишәр урамы»на иң беренче булып, җир сатып алып, мишәр татарлары килеп утырганнар. Исеме дә шуннан.

«Мөгәҗәй урамы»ның тарихы да кызык. Элек, ярлыларга дип, өй саен ашлык җыйганнар. Шул ашлык тупланган амбарлар нәкъ әлеге урамда урнашкан булган. Аларны ни өчендер «Мөгәҗәй амбарлары» дип йөрткәннәр. Урамның исемен халык шулай аңлата.

*1998 елда Илеш районы Тыпый авылында*
*Фәһимә Галиевадан (1925 елгы) БДУ студенты*
*Фәнүзә Шабаева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 404*

## 135. Көрпә елгасы

*(1 нче вариант)*

Иштирәк авылын урталайга бүлеп, Көрпә елгасы агып ята. Аның исеме менә ничек килеп чыккан.

Борын заманда бу елга янына бер кеше килеп утыра. Ул монда әзрәк ял итә дә эшкә тотына: талдан савыт-саба ясый башлый. Тал кискәндә, аның кесәсеннән елгага бер-ике бөртек көрпә килеп төшә. Моны күргәч, кешеләр инешкә «Көрпә елгасы» дип исем бирәләр.

*1998 елда Илеш районы Иштирәк авылында*
*Кашбелгаян Ногмановтан БДУ студенты*
*Таңсылу Ногманова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 406*

## 136. Көрпә елгасы

*(2 нче вариант)*

Иштирәк авылына электр кермәгән вакытта, тегермән ташларын әйләндерү өчен, елганың агым көчен кулланганнар. Ярларына берничә су тегермәне корганнар.

Тегермән тартканда, еш кына төрле хәлләр булып торган: йә җил чыгып, көрпәне елгага очырган, йә он җыючы тагарак тулып ташып, көрпәнең беразы суга төшкән. Шуңа да кешеләр елганы «Көрпә елгасы» дип атый башлаганнар.

*1998 елда Илеш районы Иштирәк авылында*
*Кашбелгаян Ногмановтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 407*

### 137. Тимеркәй урамы

Элекке вакытта халык барысын да кул көче белән эшләгән. Иштирәк авылы кешеләре дә үзләренә кирәкле барлык әйберләрне дә үзләре ясаганнар, бары тик тимерне генә эшкәртә алмаганнар. Тимер корал искерсә, эшкә ярамый башласа, ташларга кирәк булган.

Бервакыт авылга нык гәүдәле, дастуен бер кеше килеп төшә. Иштирәкнең икенче башына йорт салып, шунда тормыш кора. Ул халыкның тимерне әрәм иткәннәрен күреп, ярамаган эш коралларын үзенә җыя башлый. Тутыккан тимер-томырны эшкәртеп, аңардан өр-яңа кораллар ясарга тотына. Ул бик оста тимерче була.

Халык моңа нык сөенә, ярдәм сорап килә башлый. Күпләр бу оста янына күчеп үк утыралар. Шулай итеп, яңа урам хасил була. Халык аны «Тимеркәй урамы» дип атый.

*1998 елда Илеш районы Иштирәк авылында*
*Кашбелгаян Ногмановтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 424*

### 138. «Чабатачылар» белән «суганчылар»

Тыпый авылы янында гына элек юкә урманы үскән. Шуңа халык, юкәдән чабата үреп, аларны Үрмәт базарында саткан. Ә Үрмәт авылы сазлыклы җирдә утырганга күрә, монда суган нык уңган. Алар базарда суган белән сату иткән. Шуннан бирле Тыпыйлар Үрмәт халкын – «суганчылар», ә Үрмәтлеләр Тыпый халкын «чабатачылар» дип атый.

*1998 елда Илеш районы Үрмәт авылында*
*Сөгъдә Яһүдинадан БДУ студенты Рөстәм Хисаметдинов*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 699*

### 139. Алтын күпер

Бу күпер, авылдан олы юлга чыккан чакта, сул якта кала. Анда «Кыргыз бүләге» дигән җир бар. Монда элек кыргызлар яшәп киткәннәр. Алтынбикә исемле кыргыз карчыгы Мостафага килгәндә, авылны уратып алган сазлык аша басма сала. Озак

кына вакыт үткәч, монда күпер төзиләр. Шуңа да ул «Алтын күпер» дип атала.

*1997 елда Бакалы районы Мостафа авылында*
*Мөнирҗан Йосыпов (1924–1993) истәлекләреннән БДУ студенты*
*Светлана Медведева күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 346*

### 140. Тимер юлы җире

Екатерина патшалык иткән заманда, Казан шәһәреннән Дүртөйле пристанена тимер юлы үтәргә тиеш булган. Ләкин ул ниндидер сәбәпләр белән төзелмичә калган. Шул юлның Бакалы аша үтәргә тиешле урыны һаман да «Тимер юлы җире» дип атала.

*1997 елда Бакалы районы Мостафа авылында*
*Мөнирҗан Йосыпов (1924–1993) истәлекләреннән БДУ студенты*
*Светлана Медведева күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 346*

## *з) Табигать стихияләре, бәла-каза, афәтләр хакында*

### 141. Көек ялан

Авыл Итәвәш елгасы буена күчкән елларда, Көнтүгеш ягыннан урман янгыны чыга. Ул берничә ай буена дәвам итә. Урман иңе белән яна, сүндерергә халыкның көче җитми. Кешеләр янгыннан качу өчен, йорт әйберләрен арбаларга төяп куеп, йокларга яталар. Ут ялан буйлап килеп, Тушкыр елгасы аша чыгып китә, авылга тими. Янгын үткән урынны тазартып, тары чәчкән кешеләр бередән зур уңыш алалар. Янган, көйгән ялан халык телендә «Көек ялан» исеме белән кала.

*1998 елда Балтач районы Карыш авылында*
*укытучы Асия Гата кызы Хариповадан (1945 елгы) БДУ студенты*
*Фәнүзә Садыйкова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 435*

## *и) Кайчандыр әйтелгән сүзләргә нигезләнеп барлыкка килгән урын атамалары турында*

### 142. Сикияз елгасы

Борынгы заманнарда булган бу хәл. Шулай берчакны безнең якларга ике аучы килеп чыккан. Алар җанвар эзәрлекләп бик арыган һәм талчыккан булганнар. Ял итәргә бер елга ярына

туктаганнар. Вакыт май азагы булган. Аучылар биредә ашап-эчеп, су коенып, төн кунарга да калганнар. Бу урын аларга бик охшаган һәм йокыдан торгач, беренчесе иптәшенә:

– Яхшы елга бу, туган, моңа исем кушыйк әле. Икенче тапкыр килеп чыкканда адашмаска кирәк булыр, – дигән.

Агач ботаклары түшәлгән урыныннан торып, икенчесе:

– Болай ни, яткан җиребез сике шикелле, әле яз вакыты, шуларны берәр ничек бергә кушып исем итик, – дип киңәш биргән.

– Ярый, алай булгач, – дип ризалашкан беренче аучы, – бу елгага «Сикияз» дип исем кушыйк.

Шулай итеп, елга «Сикияз» дип атала башлый. Якын-тирәдәге авылларның исеме дә шуның белән бәйле. Елга башында урнашкан авыл – Югары Сикияз дип, түбәндәгерәге Түбән Сикияз дип атала.

*1997 елда Балтач районы Әхмәт авылында*
*Рәис Сөләймановтан (1934 елгы) БДУ студенты*
*Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 492*

## 143. Иске йорт

Авылның көнбатыш ягындагы ялан-кырлар «Иске йорт» дип атала. Элек Күктау авылы шунда урнашкан булган.

Күрше Яркәй авылы кешеләре килеп, җирләрне басып ала башлагач, Күктау халкы, чәчүлекләрен бирмәс өчен, көнчыгышка таба күченгән. Кешеләр йорт җиһазлары, маллары турында сөйләгәндә: «Иске йортта калган ие», «Иске йортка барып килдем», – дип әйтә торган булганнар. Ул җир, кешеләре күчә-күчә әкренләп бушап калса да, һаман «Иске йорт» дигән атамасын югалтмаган.

*1998 елда Илеш районы Иске Күктау авылында*
*Мәнкия Мулламөхәммәтовадан БДУ студенты*
*Айлия Хәмидуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 481*

## 144. Каракай урамы

Авылның хәтсез генә бер өлешен «Каракай урамы» дип йөртәләр. Моның үз тарихы бар.

Элек бу урамда Хәмидулла мулла нәселе яшәгән. Хәмидулла тугач, әнисе малаен: «Каракаем минем, бәләкәй каракаем», –

дип сөя торган булган. Шул вакыттан алып әлеге көнгә кадәр бу урам «Каракай урамы» дип атала.

*1998 елда Илеш районы Иске Күктау авылында Мәнкия Мулламөхәммәтовадан БДУ студенты Айлия Хәмидуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 482*

### 145. Кортлы саз

Урманлы җирләрдә сазлы урыннарның еш очравы һәркемгә дә билгеле. Бездә дә булган андый урыннар. Шулай берчакны ерак урманга җиләк җыярга баручылар, шушы саздан су эчеп, сусыннарын басарга теләгәннәр. Ләкин су бик пычрак, кортлы булып чыккан. Шуңа да юлчыларга эсседән әлсерәгән килеш юлларын дәвам итәргә туры килгән.

Җиләктән кайткач, алар: «Кояш кыздыра башлагач, сазлыктан су эчкән булган идек, бигрәк кортлы булды», – дип зарланганнар. Шуннан бирле бу саз «Кортлы саз» дип, янындагы урман «Кортлы саз урманы» дип атала башлаган. Тора-бара урманны кисеп, аның урынында басу эшләгәннәр. Ләкин атамасы шул ук, «Кортлы саз» килеш калган.

*1998 елда Илеш районы Илеш районы Кадер авылында Галимә Маликовадан (1918 елгы) БДУ студенты Физәлия Маликова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 485*

### 146. Кызыл таң чишмәсе

Бу чишмә Мәскәү авылында иң салкыны һәм иң чистасы булып санала. Монда хәтта күрше авыллардан да килеп су алганнар. Шуңа күрә биредә кеше һәрчак күп булган.

Шулай бервакыт арып-талып килеп җиткән бер карт, бу кадәр кешене күргәч: «Тиз генә су алып китим дисәң, кызыл таң белән үк килергә кирәк икән монда», – дип әйткән. Шулай итеп, чишмә «Кызыл таң чишмәсе» дип атала башлаган.

*1998 елда Дүртөйле районы Мәскәү авылында Тәнзилә Хуҗинадан (1931 елгы) БДУ студенты Дилара Фәттәхова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 488*

### *к) Шәхси фаҗигаләр турында*

### 147. Хасбулат чокыры

Авылның кайсы җиренә аяк басма, һәркайда да тере тарих ята. Мәсәлән, төньякта «Хасбулат чокыры» урнашкан. Аның үз фаҗигале тарихы бар.

Элекке елларда авыл халкы – ирләр, хатыннар – аркаларына биштәр асып, Яңавылдан әйбер ташыганнар. Юл шушы чокыр аша үткән.

Берчак Хасбулат исемле кеше берүзе Яңавыл ярминкәсеннән кайтып барган. Юлда буран купкан. Хасбулат авыл утлары дип уйлап, тегермәнгә таба киткән һәм адашкан. Шулай итеп, әлеге чокырда туңып үлгән. Шушы вакыйгадан соң бу урынны «Хасбулат чокыры» дип атый башлаганнар.

*1998 елда Борай районы Кәшкәләү авылында*
*Наилә Шәяхмәтовадан (1916 елгы) БДУ студенты*
*Айсылу Муллакаева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 541*

### 148. Каңгылды зираты

Бу хәл бик элек булган. Каңгылды исемле бабай каяндыр су аты сатып алган. Җәйге эссе көннәрнең берсендә ул Танып буена печән карарга төшкән. Ләкин кинәт ат аны туп-туры суга алып кергән дә киткән. Каңгылды бабайны табып, Танып елгасының теге ягындагы бер биек булмаган калкулыкка күмгәннәр.

*1977 елда Борай районы Чишмә-Борай авылында*
*Шәмсинур Миндияр кызы Әхмәтҗановадан (1913 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 149. Мәк тавы

Сикияз авылына Казан ягыннан күчеп килгән Гомәр карт нигез сала. Ул биредә туктап, беренче тапкыр су эчкән чишмә әлегә кадәр «Гомәр чишмәсе» дип атала. Бу кеше бик тырыш, эшчән була. Ул тау башына күп итеп мәк чәчә. Аны үстереп һәм агач кисеп сатып, бик нык байый. Гомәр карт мәк чәчкән тау әлеге көндә дә «Мәк тавы» дип атала.

Ләкин Гомәрнең байлыгына көнләшүчеләр дә табыла. 1898 нче елда Югары Сикияз авылы кешеләре аны каравылап торып, казап үтерәләр һәм акчасын талыйлар.

*1997 елда Балтач районы Әхмәт авылында Рәис Сөләймановтан (1934 елгы) БДУ студенты Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 520*

### 150. Семен күле

Бу күл бүгенге көндә инде корыган булса да, исеме һаман да халык күңелендә яши. 1950 нче елларда ул вакытта 80 яшьләрдәге Миннекәй әби Ханова болай сөйләр иде:

«Без үсеп килгәндә, кыз вакытта (якынча 1880 нче еллар), бу күл янына барырга курка идек. Шомлы бик зур күл иде бу. Тирә-ягы – урман; балан, шомырт, кура җиләге куаклары белән тулган иде. Элек ул күлне «Муеллы күл» дип атарлар иде.

Гасыр башында бу күл янында зур фаҗига булды. Урыс ярминкәсенә баручы Семен исемле купец, ат эчерәм дип, аты белән бергә суга батып үлде. Шул вакыйгадан соң күлгә «Семен күле» дигән исем бирделәр».

*1998 елда Балтач районы Карыш авылында укытучы Асия Гата кызы Хариповадан (1945 елгы) БДУ студенты Фәнүзә Садыйкова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 535*

### 151. Хәния чишмәсе

Бу чишмәнең матурлыгын күреп, сокланып туймассың. Ләкин суын эчәргә ярамый. Сәбәбен халык болай аңлата.

Канлы сугыш елларында Бигелде авылында яшәүче бер кыз әти-әнисеннән мәхрүм кала. Аның исеме Хәния була. Тора-бара бу бала акылга да җиңеләя. Аның үле гәүдәсен шушы чишмә төбеннән табалар. Үзе төшкәнме, әллә кеше зыянымы – моны беркем дә аңлата алмый. Шуннан бирле чишмәне «Хәния чишмәсе» дип атый башлыйлар.

*1998 елда Балтач районы Бигелде урта мәктәбе музее материалларыннан БДУ студенты Фәндүс Фәхретдинов күчереп алган. – Фазлетдинов, 2018, № 542*

## 152. Азнай чокыры

Борын заманнарда авылыбызда Азнай исемле егет яшәгән. Ул бик таза, гайрәтле, үзсүзле, яшьтәшләренә карата рәхимсез булган. Буй җиткән кызларны да үзенә каратып торган. Бер генә авыл егетенең дә аерым гына Азнайга көче җитмәгән.

Шуңа да егетләр, бергә җыелып, Азнайдан үч алырга булалар. Алар: «Сине кызлар көтә», – дигән булып, алдап, Азнайны Салкын чишмә буена чакыралар һәм, барысы бергә аның өстенә ябырылып, кыйнап үтерәләр. Аның гәүдәсен авыл зиратына күмдертмиләр, «14 душ» каенлыгындагы чокырга җирлиләр. Шуннан бирле әлеге урын «Азнай чокыры» дип йөртелә.

*1999 елда Чакмагыш районы Карьяуды авылында Ружидә Хөснетдиновадан БДУ студенты Ирина Насыйрова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 500*

## 153. Әбиләр чокыры

Яңабирде авылыннан ике әби Карьяудыга кунакка киләләр. Бер кич кунгач, ямьле җәйнең кояшлы көнендә кайтырга чыгалар. Юлда боларны төзелеш материаллары төягән «Беларусь» тракторы куып җитә. Карасалар, руль артында – Шәмсикамал әбинең малае. Ул әбиләрне арбага утырта. Бер чокырны узып барганда «Беларусь» авыш юлда кыегая һәм ава. Әбиләр трактор арбасы астында калалар һәм шунда ук җан бирәләр. Шушы вакыйгадан соң чокырны «Әбиләр чокыры» дип атый башлыйлар.

*1999 елда Чакмагыш районы Карьяуды авылында Гайшә Садыйковадан БДУ студенты Ирина Насыйрова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 501*

## 154. Маржа чокыры

Свердловскидан Чакмагышка Бүздәк аша бер маржа кайта. Кулында сатарга дип алган бер сумка буяулары да була. Моның юлында Яңа Биккенә авылы кешеләре очрый һәм маржа алар белән кайтырга уйлый. Аның башына ефәк яулык бәйләнгән була. Яңа Биккенә авылы кешеләре, буяуларына кызыгып, маржаны шул ефәк яулыгы белән буып үтерәләр дә тирән яр астына ташлап китәләр. Бу хәл кыш урталарында була.

Март җитә. Басу каравылчысы Талип, җилдә җилфердәп яткан яулыкны күреп килеп, үле хатынны таба. Гәүдәне Каракөчек авылындагы клубка алып кайталар. Бары тик ире эзләп килгәч кенә хатынның кем икәнлеге ачыла. Үтерүчеләрне тоталар – алар ул вакытта төрле тукымалар буяп, сату иткән булалар.

*1999 елда Чакмагыш районы Калмашбаш авылында*
*Хәдичә Галләмова-Кәлимуллинадан БДУ студенты*
*Ирина Насыйрова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 519*

## 155. Әмин кулы

Иштирәк авылының Тимеркәй урамы башында «Әмин кулы» дип аталган кечкенә урманчык үсеп утыра. Элек монда Әмин исемле картның посадкасы булган. Үләне куе, мал өчен тәмле, туклыклы булып үскән. Әмин карт монда печән әзерләгән. Аның чалгысы бик үткер булган, тиз чапкан.

Берчак шулай печән чабарга дип килгәч, Әмин җирдә кып-кызыл булып җиләкләр пешеп утыруын күргән. Карт чалгысын ташлаган да җиләк җыярга керешкән. Мавыгып китеп, чалгысы яткан җиргә барып чыккан һәм, үзе дә сизмәстән, кулын өздереп алган. Шуннан соң печәнлекне «Әмин кулы» дип атап йөртә башлаганнар.

*1998 елда Илеш районы Иштирәк авылында*
*Кәшбелгаян Ногмановтан БДУ студенты*
*Таңсылу Ногманова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 503*

## 156. Шабай күле

Бу күл Базы елгасы янында гына урнашкан була. Элек аның уртасында шомырт, балан, карагат куаклары үскән утрау да торган.

Бервакыт Шабай исемле кешенең бердәнбер кызы шушы күл эчендәге утрауга керергә уйлый. Ләкин, хәле бетеп, ул суга батып үлә. Кызны шул утрауның читенә күмәләр, ә халык бу күлне «Шабай күле» дип атый башлый.

*1998 елда Илеш районы Рсай авылында*
*Мәгъсүм Кашаповтан (1927 елгы) БДУ студенты*
*Айгөл Сәетова язып алган. – Фазлетдинов, 2018. – № 545*

### 157. Исмәгыйль, Заһид һәм Сәйкәй чокырлары

Бу чокырларның һәммәсе дә кеше фаҗигаләре белән бәйле. Исмәгыйль исемле кеше шушы сазлыклы урында батып үлә. Шуннан соң бу җир «Исмәгыйль чокыры» дип атала башлый.

Ерак юлдан кайтып барганда, Заһид дигән кеше сазлыклы икенче урында батып һәлак була. Сәйкәй атлы ир исә, адашып, өченче чокыр эчендә җан бирә. Шулай итеп, чокырлар аларның исемен ала.

*1998 елда Дүртөйле районы Мәскәү авылында*
*Тәнзилә Хуҗҗинадан (1931 елгы) БДУ студенты*
*Дилара Фәттәхова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 516*

### 158. Разия чокыры

*(1 нче вариант)*

Элек бу чокырда ком яткан. Кешеләр шул комны ихаталарына алып кайтып җәйгәннәр. Ком алырга баргач, җир убылып төшеп, Разия исемле хатынны балчык басып үтергән. Шуннан соң халык бу урынны «Разия чокыры» дип атый башлаган.

*1998 елда Дүртөйле районы Мәскәү авылында*
*Тәнзилә Хуҗҗинадан (1931 елгы) БДУ студенты*
*Дилара Фәттәхова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 527*

### 159. Разия чокыры

*(2 нче вариант)*

Имеш, элек авылда Разия исемле комсомолка кыз яшәгән. Аңа нибары 18 яшь тулган булган. Авылдагы кулаклар аны дошман күреп, шушы чокырда пычак казап үтергәннәр. Кызның үле гәүдәсен өч көн үткәч кенә табып алганнар һәм чокыр аның исемен йөртә башлаган.

*1998 елда Дүртөйле районы Мәскәү авылында*
*Тәнзилә Хуҗҗинадан (1931 елгы) БДУ студенты*
*Дилара Фәттәхова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 528*

## *л) Игелекле затлар, әүлияләр, изге чишмәләр турында*

### 160. Әүлия чишмәсе

*(1 нче вариант)*

Бакалының аръягында бик биек һәм бик матур «Әүлия тавы» бар. Аның исеменең тарихы мондый. Бик элек Кизгән авылына

бер егет укырга йөргән. Аңа нибары унҗиде яшь булган. Ләкин аны зур бәла көткән: кышкы салкын буранда ул адашып, туңып үлгән. Егетне яз көне эзләп табып, шул тау башына күмгәннәр. Күп тә үтмәгән, кабердән салкын чишмә бәреп чыккан. «Егет изге булгандыр», – дип уйлап, халык тауга да, чишмәгә дә Әүлия исемен биргән.

*1998 елда Борай районы Бакалы авылында*
*БДУ студенты Гөлназ Биктиева язып алган.*
*Информаторы билгесез. – Фазлетдинов, 2018, № 612*

### 161. Әүлия чишмәсе

*(2 нче вариант)*

Авылдан ерак түгел, биек тау башында «Әүлия чишмәсе» бар. Ул үз суын теләсә кемгә эчерми, тик охшаган кешесенә генә тәтетә. Бу чишмә турында халыкта шундый риваять яши.

Элекке заманда бер карт белән әби җәен урманда печән чабып йөргәннәр. Алар сусаганнар, алҗыганнар. Кичкә табан хәлдән таеп кайтып егыла торган булганнар. Арып кайтып килгәндә, карт үзе дә сизмәстән егылып китә. Күтәрелеп караса, ерак түгел генә бер чишмә агып ята. Урманда бер тамчы су күрмәгәнгә, алар йөгереп барып, сусыннарын басалар. Әби белән бабайга хәл кереп китә, яшәреп киткәндәй булалар. Шулай итеп, алар эшне бик җиңеләйтәләр.

Ләкин бервакыт карт чишмәнең корый башлавын күрә. Ул аны чокып та карый, чистарта да, ташлар да сала. Әмма чишмә барыбер юкка чыга.

Вакыт үтә... Бер елны корылык килә, ашлык булмый. Авыл халкы ачлы-туклы кыш чыга. Икенче елга карт белән кортка тагын печән чабарга киләләр. Карасалар, чишмә янә челтерәп агып яткан була. Әби белән бабай моңа бик аптырыйлар. Бу юлы чишмә корымый, саф суы белән әби-бабайны ел буе сөендерә. Бу елны уңыш та уңа, ашлыклар да бик күп була. Халык мул тормышта кыш чыга.

Зирәк карт бу күренешнең серенә төшенә. Ә ул болай икән: коры ел киләсе булса – чишмә корый, ә инде, киресенчә, мул уңыш көтелсә – чишмә тамып кына ага башлый икән. Шуңа

күрә дә әби белән бабай чишмәне «Әүлия чишмәсе» дип атый башлыйлар.

*1998 елда Борай районы Кәшкәләү авылында Наилә Шәяхмәтовадан (1916 елгы) БДУ студенты Айсылу Муллакаева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 614*

### 162. Изгеләр чишмәсе

Кайчандыр бездә бик изге кеше яшәгән. Ул үлгәч, аны хөрмәтләп җирләгәннәр. Шул ук көнне аның баш очыннан чишмә бәреп чыккан. Бу чишмә көньякка, кыйблага карап аккан. Суы бик чиста, шифалы булган. Каза күргән кешеләр, Аллаһтан ярдәм сорап, изге теләкләр теләп, шушы елгага акча салганнар һәм теләкләре кабул булган.

1882 нче елда безнең якларда Кояш тотыла. Халык: «Кояшны җеннәр каплап алды», – дип, урак уруларын ташлап, мәчеткә җыялалар: намаз укып, теләкләр телиләр, җеннәрне куркытыр өчен тимергә тимер сугалар. Ә аннан соң «Изгеләр чишмәсе»нә җыелып, хәер салалар. Аларның теләкләре кабул була. Җеннәр Кояшны «азат» итәләр.

*1997 елда Балтач районы Штәнде авылында Мәсәгудә Такиевадан (1935 елгы) БДУ студенты Гөлсинә Кәлимуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 616*

### 163. Әүлия кабере

Элек авылда еш-еш ут чыгып торган. Моның сәбәпләрен беркем дә юньләп белмәгән.

Шулай бервакыт авылда зур янгын куба. Күп мал-мөлкәт, йорт-куралар көлгә әйләнә, кешеләр һәлак була. Авылда яшәүче әүлия кыз да шунда янып үлә. Ул кыз тылсым көченә ия була, үзе бик акыллы, саф күңелле икән. Аның гәүдәсен хөрмәтләп авыл читендәге яр башына – тау битенә күмәләр. Шуннан соң авылда янгын чыгу туктала. Хәзер «авылны ут-күздән әүлия кабере саклый», диләр.

*1998 елда Илеш районы Иске Күктау авылында Мөнәздәха Хәмидуллинадан (1920 елгы) БДУ студенты Айлия Хәмидуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 611*

### *м) Кеше һәм хайваннар дөньясы арасындагы мөнәсәбәтләр турында*

### 164. Әхмәр кулы

Авылның көньягында, иген басулары арасында «Әхмәр кулы» дип аталган басу җәелеп ята. Аның атамасы турында шундый риваять бар.

Заманында авылыбызда Әхмәр исемле бик көчле кеше яшәгән. Бер төнне Әхмәр бабай сыер үкерүенә уянып китә һәм тышка чыга. Тавыш килгән якка барса, ни күрсен: әлеге кулда бер сыерга аю һөҗүм итеп маташа! Әхмәр бабай күсәк белән аюның башына суга. Аю җиргә ава. Ләкин тиз аңына килә һәм Әхмәргә ташлана. Алар арасында көрәш озак бара. Аю Әхмәрнең кулын чәйни. Шулай да бабай аюны күсәк белән тукмый һәм сөйрәп үз йортына алып кайта. Аю гәүдәсен бозау абзарына кертеп ташлый. Бу хәл турында беркемгә дә хәбәр салмый, йокларга ята.

Иртән хатыны торып сыер саварга чыкса, абзарда ниндидер зур килбәтсез нәрсәнең бозау янында йөргәнен шәйли. Хатыны тиз генә ишекне ябып, ирен уята һәм бу хәл турында сөйли. Шул вакытта гына Әхмәр бабай аюның үлеп бетмәгәнлеген исенә төшерә һәм абзарга чыгып йөгерә. Шушы вакыйгадан соң бу кулны «Әхмәр кулы» дип атап йөртәләр.

*1998 елда Борай районы Кәшкәләү авылында*
*Наилә Шәяхмәтовадан (1916 елгы) БДУ студенты*
*Айсылу Муллакаева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 591*

### 165. Бизәр тавы

Авыл янындагы бу тау моннан күп еллар элек көртлеккә бик бай була. Авылның Рамазан исемле бер кешесе, шушы тауга сунарга йөреп, көртлек ата. Бу хәл көн дә диярлек кабатлана. Кошлар, куркышып, бу таудан бизәләр, икенче урынга күчеп китәләр. Менә шуңа да бу урын «Бизәр тавы» дип атала.

*1998 елда Илеш районы Рсай авылында*
*Мәгъсүм Кашаповтан (1927 елгы) БДУ студенты*
*Айгөл Сәетова язып алган. – Фазлетдинов, 2018. – № 444*

КӨНКҮРЕШ ВАКЫЙГАЛАРЫ ТУРЫНДА

## 166. Шапыр күле

Кәшкәләү авылы янындагы тау башында түгәрәк күл бар. Ул «Шапыр күле» дип атала. Аның исеменең барлыкка килү тарихы мондый.

Элек бу күл янында Миңлеәхмәт исемле бер кеше яшәгән. Аның гаиләсе зур булган, ә үзе мактанырга, арттырып сөйләргә яраткан. Миңлеәхмәт абзый Кизгәнбаш базарына йөри торган булган. Бервакыт ул базардан конфет алып кайта (ә ул вакытта конфет-прәннек бик сирәк татыла торган затлы ризыктан исәпләнелгән). Ризыктан балалары белән авыз иткәч, ул: «Конфетны туйганчы ашадык, калганын күлгә чыгарып сиптек», – дип мактанган. Шуннан соң халык күлне «Шапыр күле» дип атап йөртә башлаган.

Бу күлнең уртасында зур утрау урнашкан икән. Аның күчеп йөри торган «гадәте» дә булган. Ул да «Шапыр утравы» дип йөртелгән.

*1998 елда Борай районы Кәшкәләү авылында*
*Наилә Шәяхмәтовадан (1916 елгы) БДУ студенты*
*Айсылу Муллакаева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 589*

## 167. Идрис сазы

Элекке заманнарда була бу хәл. Эссе бер көнне авылның Идрис исемле бер карты, өстенә тун киеп, печән чабарга китә. Күп тә үтми, коеп яңгыр ява башлый. Карт эшен ташлап тормый, тунын әйләндереп кия дә печән чабуын дәвам итә. Хәтсез ара үтеп тирләгәч, ул тунын салып, якындагы агач ботагына элә. Бер туктамый яуган яңгыр тунны нык юешләп авырайта, һәм ул җиргә килеп төшә.

Бу вакытта карт өс киеме барлыгы турында бөтенләй оныткан була. Эшеннән арып туктаган арада, туны эленгән урынга күз салса, ни күрсен: агач төбендә соры бүре ята! Тун бүре булып күренә моңа.

Карт: «Бүре бар, бүре бар!» – дип сөрән сала башлый. Аның тавышына күршеләре җыела. Ләкин алар бернинди бүрене дә

күрмиләр, ә бары тик агач төбендә яткан тунны гына табып алалар. Шуннан бирле бу урын «Идрис сазы» дип атала.

*1998 елда Илеш районы Рсай авылында*
*Мәгъсүм Кашаповтан (1927 елгы) БДУ студенты*
*Айгөл Сәетова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 562*

## 168. Разыя таллары

Сугыш елларында Разыя исемле хатын тракторда эшләгән. Бервакыт, саз аркылы чыкканда, аның тракторы батып кала. Разыя югалып калмый, юл аркылы тизрәк таллар кисеп сала һәм тракторны чыгара. Ә таллар сазда тамыр җәеп, үсеп китәләр. Бу атама шуннан килеп чыккан.

*1998 елда Илеш районы Тыпый авылында*
*Фәһимә Галиевадан (1925 елгы) БДУ студенты*
*Фәнүзә Шабаева язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 581*

## 169. Мөхәммәтдин батыр

Элек Йонны авылында атаман булып Мөхәммәтдин Зәйнетдинов исемле кеше торган. Ул гаять зур гәүдәле, көчле ир булган. Үзенең кул көче белән таудан беркем дә күтәрәлмәслек олы таш чокып алып, шуны ихата коймасына багана итеп утыртып куйган.

Бу пәһлеван белән шундый хәл булган, имеш. Бервакыт аның күршесе Гыйлаҗетдиннең җигү аты ялгыш кар базына төшә. Шулчак ярдәмгә шушы Мөхәммәтдин килеп җитә. Ул баз өстенә килеп баса һәм атның корсак астыннан аркан белән урап тотып, аны иреккә чыгарып куя.

*1998 елда Илеш районы Йонны авылында*
*Рүзил Мәгъдәновтан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 593*

# ЛЕГЕНДАЛАР

## ЗООГОНИК ЛЕГЕНДАЛАР

### 170. Аюлар каян килеп чыккан?

Элек бер тылсымчы егет яшәгән. Ул билбавына кыстырып һәрчак хәнҗәр йөрткән. Кешеләр арасында үзен кыен сизә башласа, ул урманга китә торган булган. Хәнҗәрен җиргә кадап, ниндидер сихер сүзләре әйтә икән дә аюга әйләнә икән. Аю кыяфәтендә рәхәтләнеп йөреп туйгач, хәнҗәрен кире кулына алса, кабаттан кешегә әверелә икән. Бервакыт бер алама кеше аның аюга әйләнгәнен күреп алган һәм җиргә кадалган хәнҗәрне тартып алып, суга ыргыткан. Егет кайтса, хәнҗәре юк. Эзлиэзли хәле бетә, ләкин таба алмый. Егет аю кыяфәтендә кала. Шулай итеп, җирдә аюлар килеп чыга.

*1997 елда Борай районы Борай авылында*
*БДУ студенты Луиза Усаева язып алган.*
*Информаторы билгесез. – Фазлетдинов, 2018, № 637*

### 171. Ни өчен тирәк агачы җимешсез булып калган?

Иң тәү башта тирәк агачы да башка җимеш агачлары шикелле җимеш бирәсе булган, буйга-сынга да алар белән бер чамада гына үскән, ди. Тик ул ни өчендер, тиктомалдан үзалдына һаваланып китеп, минсенергә тотынган: «Мин башкалар ише генә түгел, мин алар белән тиң түгел», – дип, лыбыр-лыбыр сөйләнергә керешкән. Сөйләнә торгач, шуның белән күңелләре төрләнеп китеп, җилсез көндә дә җилферди башлаган. Менә шуннан, бер дә хәтәр эреләнеп, борынын тиешеннән артык күккә чөеп, тотынган, ди, үсәргә, тотынган, ди, үсәргә. Шулай

киерелә-сузыла торгач, һәммә җимеш агачларыннан да биегрәк, калкурак булып киткән, ди.

Тик аның болай үз дәрәҗәсеннән чамасыз артык үсүе үзенә файдага булып чыкмаган, ди. Аның шулай: «Мин – минме икән, мин кем икән?» – дип, үзенә-үзе шаккатып торган чагында гына, агачларга җимеш-чикләвек өләшү башланган, ди. Алмагач – үзенең алмасын, чикләвек агачы – үзенең чикләвеген, шомырт, балан, миләшләр дә, бары да, бары да үз җимешләрен алып, җимешләнеп беткәннәр. Тик үзенә-үзе исе киткән тирәкнең генә моны күрергә вакыты булмаган, башын-борынын югары күтәрү аркасында, җимеш өләшкәндә коры торып калган да куйган, имеш, ди.

Шуның өчен дә иске шагыйрьләрдән берсе әйткән: «Тирәктәй, син коры калма кирәктән», – дигән. Бу сүздә дә шулай корыга масаюга тирәкне мисалга китергәннәр шул инде.

*1970 елда Чакмагыш районы Таш Калмаш авылында*
*Разия Турьяновадан (1899 елгы) БДУ студентлары язып алган. –*
*ТХИ РЛ, № 300; Фазлетдинов, 2018, № 641*

### 172. Кандала каян барлыкка килгән?

Саранбайга кунаклар килгәч, нәрсә суярга белмәгән. Мич башында яткан песине суеп пешергән дә кунаклар алдына утырткан. Кунаклар моны күреп ачуланган. Саранбай оятыннан бүрәнә ярыгына кереп киткән, ди. Шуннан бирле кешене чагып йөри, ди. Кандалага әйләнгән, ди.

*1998 елда Илеш районы Югары Яркәй авылында*
*Әбәдия Габдрахмановадан БДУ студенты Флорида Гыйльванова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 639*

### 173. Тартай белән кысла ничек килеп чыккан?

Элек бер гаилә яшәгән. Ире гел кыска әйбер кия икән. Хатыны аңа: «Тарт, тарт!», – ди икән. Ире барыбер тыңлашмаган, кыслага әйләнгән. Хатыны тартай булган.

*1998 елда Илеш районы Югары Яркәй авылында*
*Әбәдия Габдрахмановадан БДУ студенты Флорида Гыйльванова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 645*

## 174. Үрмәкүч белән чебен каян барлыкка килгән?

Бер кыз: «Иренәм, иренәм», – ди икән гел. Аңа: «Иренсәң, иргә чык», – дип киңәш биргәннәр. Бу кыз кияүгә чыккан. Кияүгә чыккач та иренә икән. Бер эш тә эшләми, ди. Кияве: «Өс-баш та тузды, гел иренеп кенә утырма, җеп җегерлә әзрәк», – дип әйткән, ди. Урманга барып каба ясап алып кайткан, ди. Хатыны бер генә орчык җеп җегерләгән дә бүтән җегерләми, ди. Ире: «Күпме җегерләдең әле?» – дип сорагач, мич артыннан теге бер орчыкны алып, әллә ничә мәртәбә күрсәтә, ди. «Менә берәү, менә тагы берәү», – дип әйтә, ди. Ире: «Бик күп җегерләгәнсең», – дигән. «Мин сиңа урманга барып, киләп агачы ясыйм», – дип әйткән, ди. Урманга барган да бер агачка чаба да чаба икән. Шулчак аның колагына: «Җүләр, киләп агачы ясаган кешенең хатыны үләр», – дигән сүзләр ишетелгән, ди. Шуннан ир өенә кайткан да, хатынының җебен урманга алып барган, ди. Агачтан агачка теге җепне урый, ди. Урый торгач, бу ир үрмәкүчкә әйләнгән, ди. Хатыны, моны эзләп, урманга барган. Барган да җепкә уралган. Шуннан бу хатын чебенгә әйләнгән, ди.

*1998 елда Илеш районы Югары Яркәй авылында Әбәдия Габдрахмановадан БДУ студенты Флорида Гыйльванова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 646*

ДИНИ ЛЕГЕНДАЛАР

## 175. Якуп пәйгамбәр

Бер кеше сырхап ята икән. Пигамбәр узып китеп бара икән. Теге кеше: «Минем урында син булсаң нде», – ди. Шулай итеп Якуп пигамбәрнең шушы кешенеке кебек тәннәре кабарып чыга. Өч хатынының икесе аерылып китә. Шуннан соң яшь хатыны чәч толымын кисеп, иренә ашарга таба. Бер көнне хатыны ашарга алып кайтса, Якуп пигамбәр урынында булмый. Хатыны эзләп чыгып китә. Тау башыннан таба.  Шулай итеп, Якуп пигамбәр 18 елдан соң терелә.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында Шәмси Каюм кызы Гариповадан БДУ студентлары язып алган*

## 176. Тәкъдир

Элекке заманда Сөләйман исемле бер патша булган. Ул бервакыт әйткән: «Көнбатыш кызын көнчыгыш җегете алырга тиеш». Озак та үтми, бу патшаның кызы туа. Вакыт үтә, кыз үсә матур булып. Ләкин көннәрдән бер көн кызны сәмруг кош урлап китә.

Шул заманда көнчыгыштагы бер патшаның улы да матур гына булып үсеп килә икән. Бер көн җегет әтәсенә әйтә: «Әтәй, минем диңгезгә төшәсем, кәмәдә җөрисем килә», – ди. Әтәсе риза була: «Улым, берүк саклана күр, диңгездә давылга очрап, кәмәң каплана күрмәсен, һәлакәткә җулыгуың бар», – дип, киңәшләр бирә.

Җегет кәмәгә утырып диңгезгә чыга, балык тота башлый. Бу эш белән шулхәтле мавыга, дажы кәмәнең диңгезгә эчкә керүен дә искә алмый. Ә кәмә эчкә керә дә китә. Ул җегетне бер ярга алып чыга. Җегет җарга төшә, тирә-җагына каранырга тотына. Күрә бу, җакында гына бер агач үсеп утыра, ә башында зур ояга ошаган бик матур нәрсә. Барса, анда бик чибәр кыз утыра. Кыз, җегетне күргәч, аннан сорый: «Син адәм затымы, җен затымы?» – ди. Җегет әйтә: «Мин адәм заты, син дә миңа ошагансың, син дә адәмдер», – дип җавап бирә. Кыз: «Минем әни – бик зур бер кош. Канат җилпегән тавышы өч чакрымнан ишетелә. Ул ике башлы. Бер башы минем белән сөйләшә, ә берсе – кошларча», – ди.

Икәү сүләшеп туйгач, җегет кәмәсе җанына китә. Бик ачыккан була, диңгездә тоткан балыгын ашарга тотына. Бер мәлне «гөжт-гөжт» иткән тавыш ишетелә башлый. Теге кош очып кайта икән. Бераздан гөпердәп әкәмәт зур кош килеп тә куна. Кыз кошка әйтә: «Әни, минем җирдә җөрисе килә, рөхсәт ит әле», – ди. Кош разрешать итә. Кош яңадан очып китү белән, җегет агач җанына килеп тә җитә. Кыз агач башыннан төшәргә ояла, чөнки ул шәрә була. Агач башында торган килеш кенә сүләшәләр.

Кичкә таба кош кайта. Кыз аңардан үзен агач башыннан төшерергә-мендерергә зуррак әйбер алып кайтуын сорый. Кош китә дә ат тиресе алып кайта, аны бик әйбәтләп киптерә.

Шуннан кош көн дә киткән чагында кызны шул ат тиресенә утыртып төшерә, ә кайткач, күтәреп мендерә. Җегет гел кыз җанына килә. Бер-берсен бик җаратышалар. Вакыт үтә. Боларның балалары туа.

Бервакыт Сөләйман патша кошны чакыра. Чакыра да, кошка әйтә: «Аллаһның тәкъдирен боздыңмы?» – ди. Шуннан кош ат тиресен күтәреп китерә. Тирене ачып җибәрәләр. Ачсалар, анда кыз белән җегет, урталарында бала ята. Шуннан инде билгеле була. Аллаһның тәкъдире бозылмаган: көнчыгыш җегете көнбатыш кызын алган булып чыга.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Сөләйман Агиевтан (1887 елгы) БДУ студентлары язып алган*

## 177. Сөләйман пәйгамбәр белән Бәлхис патша

Берзаман Сөләйман пәйгамбәр сәяхәткә чыгарга була. Аның шундый йорты булган: җилгә командовать иткән, йорт-кошлары белән кояшны и(л)теп куйган, җә туктатып торган.

Бервакыт Сөләйман һөдөһөт кошын су алырга җибәрә. Һөдөһөт очып барганда бер йорт күрә дә, нигә килгәнен дә оныта. Бәлхис исемле патша йорты була бу. Кояш көтә дә көтә, ә һөдөһөт юк. Кайтып кергәч, Сөләйман аңа бик ачулана, башыңны кисәм, ди. Шуннан кош үзенең күргәннәрен сүләп бирә: «Бер йорт күрдем, – ди, – үзем кебек бер хәдимче күрдем», – ди. Шуннан һөдөһөт за минут пәйгамбәргә су табып китерә. Сөләйман намаз укый, тәһарәт алгач. Шуннан һөдөһөткә кәгазь бирә: «Йоклаганда, патша хатынның күкрәгенә куй». Һөдөһөт барып куя да чыгып китә.

Иртән патша хатын уяна, күрә – кәгазь. Ала да укып карый. «Әгүзе бисмилла»ны укый алмый. Атасы – җен, димәк. Һөдөһөтен чакыра да: «Кем дә булса килдеме?» – дип сорый. Тегесе әйтә: «Минем кебек бер хәдимче килгән иде, тик аның бернәрсәсе дә юк иде», – ди. «Минем янга кил, миңа бигаять бир, миңа хатын бул, үзем патша булам», – диелгән кәгазьдә.

Шуннан патша хатын тора да кызларга җегет киеме киендерә. Җегерме малай, җегерме кыз булалар. Һәрберсенә икешәр кир-

печ тоттыра. «Пәйгамбәр булса – алмас, патша булса – алыр», – ди. Сөләйманның һөдөһөте тыңлап кына тора да кайтып сөйли.

Сөләйман бер җакка алтын, бер җакка көмеш кирпеч тездерә. Тегеләр аптырыйлар. Сөләйман исә аларга: «Үземдә дә алтын күп», – ди. Шуннан Сөләйман боларга бит юарга куша. Кызлар битләрен сул кул белән юалар. Сөләйман шунда ук кызларны, җегетләрен танып ала. Тегеләр каршында яшел корт энҗене живо бораулап чыга (ә моны кеше дә, җен дә тишәлмәскә тиеш була). Шуннан Сөләйман боларга: «Барыгыз, кайтыгыз, патшагыз үзе килсен», – ди. Ул да булмый, гыйфрит Бәлхиснең тәхетен монда алып килеп тә җиткерә. Сөләйман җулга көзге җәйдерә, чтубы күренсен өчен. Бәлхис, су дип белеп, күлмәген күтәрә. Шуннан Сөләйман күреп кала: аягы җөнле.

Шуннан җеннәр моны күреп калалар да: «Әгәр бу Бәлхис безнең патшаның хатыны булса, без мәңге кол, хәерче булырбыз», – дип, үтерергә уйлыйлар. Җәбраилны чакыралар. Җәбраил килә. Сөләйманга әйтә: «Кяфер була яздың бит», – ди.

Шуннан инде Сөләйман шайтаннарга Бәлхисне үтерергә куша. Алар аны тотып үтерәләр.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Сөләйман Агиевтан (1887 елгы) БДУ студентлары язып алган*

## 178. Тылсымлы йөзек

Сөләйман Галиәссәлам, тышка чыкканда, йөзеген хатынына бирә, ә кергәч – кия торган була. Бер көнне Абез дигән шайтан Сөләйман сурәтенә керә дә, хатыныннан йөзекне алып кия һәм патша урынына кереп утыра. Сөләйман үзе керә, хатыныннан йөзеген сорый. Хатыны әйтә: «Йөзегеңне миннән алдың бит, саташтыңмы әллә?» – ди. Шуннан шайтаннар пәйгамбәрне өйдән бөтенләй куалар. Сөләйман нишләсен, өйдән китә. Елга буенда балыкчылар очрый. Балыкчылар аны эшкә алалар. Хезмәт көненә һәр балыкчыга үзе теләгән бер балык тия.

Ә Сөләйман йортындагы хәдимчеләр эшнең нидә икәнен сизеп калалар. «Бу бит Сөләйман пәйгамбәр түгел, шайтан бит бу!» – диләр. Шайтан моны ишетә дә тизрәк тәхеттән сыза. Елга

аша чыгып барганда, моның йөзеге суга төшә дә китә. Ә аны бер балык йота.

Бу көнне балыкчыларга балык бигрәк тә күп эләгә. Балык күп эләккән көнне дип, Сөләйманга иң зур балыкны бүләк итәләр: «Яхшы эшләдең, бездән сиңа бүләк, яхшы да хезмәт иттең», – диләр.

Сөләйман балыкны ачып караса, аның эчендә үзенең йөзеген күрә. Шуннан, аны алып, кулына кия. Тәһарәт ала да Корьән укый башлый. Моның янына бөтен кошлар җыела. Йөзеге кулында булгач, барлык права үз кулында инде. Шуннан ул җилләргә тәхетен китерергә куша. Һөдһөт кошы бу турыда кайтып белдерә. Тәхетен дә момент китереп бирәләр. Сөләйман пәйгамбәр әйбәт кенә тора башлый. Берзаман моның янына Газраил килә. Пәйгамбәр сорый: «Нигә килдең? Кабыс кылыргамы, зират алыргамы?» – ди. «Кабыс кылырга» – ди.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Сөләйман Агиевтан (1887 елгы) БДУ студентлары язып алган*

**179. Чупа ябалак турында хикәят**

Сөләйман патшаның хатыны кошлар сөягеннән сарай салдырырга куша. «Синнән бер поминка калыр», – ди ул иренә. Шуннан Сөләйман риза була. Ул бөтен патшаларны җыйдырта. Тик бер Чупа ябалагы гына килми кала. Ярар, моны да китертәләр. Сорау алалар моңардан: «Вәт, нишләп килмәдең син чакырган вакытта?» Ябалак әйтә: «Ә мин коры җирме, юеш җирме күбрәк икәнен чутладым», – ди.

– Соң, кайсысы күп булды, – диләр.

– Юеше, әлбәттә.

– Шул гынамы эшләгән эшең?

– Юк, – ди ябалак. – Мин тагын корыган агач белән чи агачны чутладым.

– Кайсы күп инде?

– Корысы күбрәк. Мин бер ботагы коры булган агачны да корыга чутладым, – ди ябалак.

– Тагын нәрсә чутладың?

– Тагынмы? Тагын ирләрме, хатыннармы күп икәнен чутладым.

– Кайсы күп булып чыкты?

– Хатыннар күбрәк булды, – ди ябалак.

– Бәй, нишләп алай?

– Ир булып та хатыннар кебек көчсез, ләчтит сатып йөргән ирләрне дә хатыннарга чутладым, – дип җавап биргән ябалак.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Сөләйман Агиевтан (1887 елгы) БДУ студентлары язып алган*

## 180. Фиргәвен турында хикәят

Багдадтан ары Хөрәсән дигән бер авыл була. Шунда Багур исемле бер бәндә яши. Ул чыныдан чыккан ялкау була. Шул хәтле ялкау була, алмагач төбенә ята да: «Алма пеш, авызыма төш!» – ди. Алма авызына төшсә – ашый, әгәр читкә төшсә – аны алырга иренә.

Аның Вәлид исемле улы була. Хатыны озакламый үлә. Бу кешеләр турында патшага сообщить итәләр. Патша аларны алдыра да алмагачлар арасына кертә. Багур һаман элеккечә ята бирә. Авызына төшсә – ашый, төшмәсә – юк. Ә улы исә авызына төшми, читкә тәгәрәгәнен дә алып ашый. Патша аны «нахал!» дип куа.

Шуннан Вәлид Багдадка китә. Бер тимерчегә очрый да аңардан эш сорый. Тимерче:

– Нинди эш инде сиңа? – дип уйланып тора да ала моны үзенә. Иң элек тамагын туйдырып ала. Вәлид бу тимерчедә күмер яндыручы булып эшли. Шуннан Вәлид иске-москы белән киенгәндәй итә. Бер көнне тимерче Һуман әйтә:

– Эшләгән ашарга җитми, әйдә Мисырга киттек. Анда яшелчә дә, кавын да күп, – ди.

Шуннан болар күп уйлап тормыйлар, китәләр. Баралар, баралар да зират янына туктыйлар. Боларга зират казырга кушалар. Казырга тотыналар. Монда үлүче кеше бик күп икән, шуңа күрә зиратны яллап казыталар. Көненә күпләп зират казып, ару гына акча эшлиләр, рәтләнеп китәләр.

Бердән бер көнне патшаның кызы үлә. Патша хезмәтчеләренә әйтә:

– Кызым дөнья куйды, барыгыз, зират казыгыз! – ди.

Хезмәтчеләр зиратка киләләр, тик мондагы зират казучылар аларны кертмиләр.

– Патша башта бездән сорасын, – диләр алар.

Патшаның хезмәтчеләре кайталар да бөтенесен сөйләп бирәләр. Патша зират казучыларның берсен чакырырга боера.

Һуман:

– Вәлид, син бар, – ди.

Вәлид:

– Һуман, син бар, – ди.

Шулай тарткалаша торгач, Вәлид барырга вынужден була. Ул төскә бик чибәр. Бара. Патшага бу егет ошап китә. Ул Вәлидне үзенә башмакчы итеп ала. Вәлид әйбәт кенә хезмәт итә, шулай ару гына торалар. Бер мәлне патшаның вәзире үлә. Торалар да Вәлидне советник итеп куялар. Патша белән дус булып яшиләр.

Бер көнне патша әйтә:

– 37 ел патшалык иттем. Үземчә гадел генә булдым. Халык минем турында нинди фикердә икән? Бар, Вәлид, базарда йөреп, ишетеп кайт шуларны, – ди.

Вәлид китә, йөреп кайта да болай ди:

– Халык сине алай гадел булды, тик менә бер дә ашка чакырмады, – ди.

Ә үзе Вәлид халыкка:

– Вәт, патша агу салып ашка чакырачак сезне, ашамагыз, – ди.

Шуннан бөтенесе коралланып килә дә патшаны үтерәләр. Аның урынына патша итеп Вәлидне куялар. Аңа Фиргәвен дип исем бирәләр. Бик күп гомерләр үтә. Фигәвен инде 500 ел торган була. Аның сакалы биш карыш, үзе бер карыш була. Ул аллалык дәгъвасы дә кыла башлый. Үзен:

– Мин – Аллаһ! – дип белдерә.

Бервакыт Нил корый, бөтен елгалар, коелар корый. Халык җыелып килә дә:

– Син Аллаһ түгел, әгәр Аллаһ булсаң, суны корытмас идең, – диләр.

Шуннан патша әйтә:

– Сез минем алда гөнаһлы. Шуның өчен сәҗдә кылыгыз, – ди.

– Бәй, ничек? – ди халык.

Патша боларга:

– Башыгыздан салыгыз да, «дай бог, помилуй, господи», диегез, – ди. Халык нәкъ патша кушканча эшли. Фиргәвен үзе бер бүлмәгә керә дә, сакалыннан алып: «Ярабби, сулар килсен», – дип тели башлый. Шулай тели дә, Нилгә дәрья кайта. Тормыш тагы җайга салына: әпи дә бар, су да бар.

Фиргәвен бер көнне төш күрә. Төшендә бер кеше моны тота да башын борып ала. Иртән ул бөтен ворожайкаларын җыя да төшен сүли. Ворожать итәләр, патшаның үзенә әйтергә куркалар. Шуннан берсе әйтә:

– Менә бер бала туачак, син шуннан үләчәксең. Синең урының аңа булачак.

Шуннан инде Фиргәвен бөтен хатыннарны да исәпкә ала һәм туган бер баланы үтертә бара. Менә бер хатынга бала табарга вакыт җитә. Ул баласын тау тишегендә тудыра, шунда асрый. Баласын тукландыра да кайтып китә, ә баласы шунда кала. Унбиш көннән соң бала аякка баскан. Инәсе моны күреп гаҗәпләнә:

– Бәй, нигә син шундый?

– Менә шундый инде, – ди улы.

– Әллә шайтан алыштырдымы сине? – ди инәсе.

– Нигә, әни, юк. Синең Аллаң кем, минем Аллам кем?

Инәсе кайта да бөтенесен иренә сүләп бирә. Аны да улы янына алып бара. Ире әйтә:

– Син нинди бала?

– Менә шундый инде, – дип чыгып баса улы.

Шуннан әтисе аны сандыкка сала да дәрьяга агызып җибәрә. Фиргәвен сараендагы ике кыз агып килүче сандыкны күреп алалар. Патша хатыны әйткәч, аны тотып алалар. Анда бала ятканын күргәч, патша әйтә:

– Менә минем башка җитәчәк бала шушы, – ди.

Патша хатыны баланы үтертергә каршы төшә. Бала каршына алтын белән ут куялар. Шайтан аның күзен каплый. Бала утны ала. Судан алгач, аңа Муса дип исем бирәләр.

Муса үсә төшкәч, ат белән чыгып йөри башлый. Бер көнне атка атланып кайтып килгәндә күрә: бер мөселман белән җәбрай сугыша. Муса атыннан төшә дә җәбрайне үтерә. Икенче көнне тагын шундый хәлгә тап була. Тагын аралашырга атыннан төшә. Шуннан патшага: «Улың кеше үтерә!» – дип барып зарланалар.

Муса бөтенләй башын алып чыгып китәргә мәҗбүр була. Бер көн, ике көн, өч көн, дүрт көн бара. Бер кое янына барып чыга ул. Ниндидер бер байның хезмәтчеләре киләләр дә, зур таш булатны ачып, куйларын эчерәләр, аннары, таш белән ябып, кире китәләр. Бераздан кое янына ике кыз килә. Коены ачарга тырышалар, ну, ачалмыйлар. Шуннан Муса килә дә аларга җәрдәм итә. Кызлар рәхмәт әйтеп кайтып китәләр. Кайталар да:

– Тирәк төбендә бер җегет коены ачып, куйны эчертте, – диләр. Әтәсе кызын җегет артыннан җибәрә. Сафура ояла-ояла гына бара. Җегеткә әтәсе аны чакыруы турында әйтә һәм үзе белән әтәсе сараена алып китә. Әтәсе бай була аның.

– Син нинди җегет? – дип сорый аңардан кызларның этисе.

– Вәт, шулай-шулай, – дип, егет үзе турында сөйләп бирә.

– Ярый, алайса. Син миңа хезмәтче булырсың минем зур куй көтүем бар. Ала бәрәннәр туса – синңа, агы – миңа, – ди бу.

Егет ризалаша. Бәй. Бөтен куй аланы бәрәнли. Бөтенесе дә җегеткә була. Бай әйтә:

– Бәхетең бар икән, җегет, – ди.

Аңа ул кызын да бирә. Туган иленә кайтырга да рөхсәт ала. Кайтып җитә бу. Ну, үзләренең йортына берничек тә үтәлми, өй бөтен яклап бикле. Ничек итсә итә, өйгә керә бу. Инәсе белән күрешә, ә әтәсе өйдә булмый. Инәсе аңа энесенең пәйгамбәр булуын әйтә.

Озак та үтми, Мусага да пәйгамбәрлек хәбәре килә. Фиргәвен бу турыда ишеткәч, моңа бик хәтәр яный. Мусаның бабасыннан калган таягы булган икән, янау белән таяк аждаһа-

га әйләнә. Фиргәвеннең моңа бик тә ачуы чыга. Бу турыда ул Мөхәммәт галиәссәламгә әйтә:

– Таяк аждаһа булды, – ди.

Фиргәвеннең советчиклары да Фиргәвенгә:

– Син дә аждаһа яса, – диләр. – Өч көн срок куй. Өч көннән соң тау янына Мусаны чакыр и аның каршында аждаһа ясаттыр сихерчеләреңнән.

Өч көн үтә. Муса тау янына бара. Фиргәвен бөтен сихерчеләрен җыйдыра да өрдертә. Бер тау аждаһа барлыкка килә. Шуннан Муса: «Нишлим икән?» – дип, Аллаһка киңәш итә. Аллаһ аңа таяк ыргытырга куша. Шуннан Муса таяк ыргытуы була, бик зур аждаһа барлыкка килә. Ул бөтен еланнарны берьюлы каба йота.

Бер тау аждаһа ясаучы сихерчеләр мөселман динен кабул итәләр. Фиргәвен бөтен мөселманнарга каладан чыгып китәргә боера. Шул мөселманнардан барлыгы унике полк җыела. Китәләр болар, барып җитәләр Нилгә. Артларына борылып карасалар – Фиргәвеннең войскасы.

– Ярабби, инде нишлим, – дип, Муса тагын Аллаһтан киңәш сорый. Аллаһ аңа:

– Таягың белән диңгезгә сук, – ди.

Муса шулай эшли. Шуннан унике юл барлыкка килә. Муса диңгез аша үтә торган юл белән китә. Муса диңгезне чыгып беткәндә, Фиргәвен үз гаскәре белән диңгезнең нәкь уртасында гына була әле. Аллаһ аларның барысын да тюленьгә әйләндерә. Тюлень – Фиргәвен токымы иде.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Сөләйман Агиевтан (1887 елгы) БДУ студентлары язып алган*

## АЛЫПЛАР ТУРЫНДАГЫ ЛЕГЕНДАЛАР

### 181. Иш тавы

*(1 нче вариант)*

Борын заманда әле без яшәгән җирләр урынында зур диңгез булган. Шул диңгез уртасыннан ике тау калкып торган. Бу таулар ике бертугандай булганнар. Алар өстендә матур агачлар

үскән, кошлар сайраган, диңгез дулкыннары тау битенә бәреләп, аның белән уйнаганнар.

Көннәрдән бер көнне олы бер балык ике тау арасына юнәлгән. Ул тауларның уртасыннан йөзеп үтмәкче булган. Ләкин акылсыз, җүләр балык үзенең зурлыгын исәпкә алмыйча, таулар арасында кысылып калган. Күпме генә тырышса да, балык тау арасыннан чыга алмый, бик каты кысыла. Балык янындагы ике тау аның канаты чаклы гына була. Шулай кысылып, балык тиздән зур тауга әйләнә, ә ике як кырындагы таулар аның дәвамы булып калалар. Гасырлар узгач, үткән-сүткән кешеләр:

– Кара әле, нинди зур иш тау, – дип, гаҗәпләнеп китә торган булганнар. Шуннан бирле бар кеше дә Карабаш авылы янында урнашкан бу балык-тауны «Иш тавы» дип йөртә башлый.

*1998 елда Илеш районы Карабаш авылында*
*Сания Хаҗиевадан БДУ студенты Таңсылу Ногманова*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 627*

### 182. Иш тавы
*(2 нче вариант)*

Элек без гомер иткән җирдә бик эре гәүдәле кешеләр яшәгән. Аларны «Иш нәселе кешеләре» дип йөрткәннәр. Бу алыплар тамакларын безнең кебек үк эшләп туйдырганнар. Шуларның берсе эшләп арыгач, ял итәргә туктаган һәм, чабатасын салып, «Салкын чишмә»дә аякларын юган. Чабатасын салганда коелган туфрактан зур тау барлыкка килгән. Ул тауны бездә «Иш тавы» дип йөртәләр.

Иш нәселе кешеләре, ашаганнан соң, теш араларын безнең кебек нечкә шырпылар белән чистартып азапланмаганнар. Моның өчен алар үсеп утырган агачларны файдаланганнар. Аларга тамыры белән агач тартып чыгару – безгә үлән өзү кебек җиңел булган. «Салкын чишмә» буенда күп еллар элек төбе-тамыры белән тартып чыгарылып, череп бетеп яткан агачларны Иш нәселе теш чистартыр өчен алган икән.

*1998 елда Илеш районы Яңа Күктау авылында*
*Хәбибрахман Кәшбуллиннан (1910 елгы) БДУ студенты*
*Рәйлә Нигмәтуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 628*

МИФОЛОГИК ХИКӘЯТЛӘР

## 183. Убыр белән очрашу

Шулай бервакыт кыш көне кич белән репетициядән кайтып киләм. Тышта буран. Капка төбенә килеп җиттем. Карыйм, капка төбендә кап-кара кечкенә бер эт ята. Өстендә бер генә дә кар бөртеге юк. Ул этне жәлләдем дә, урыныннан кузгатмыйча, койма өстеннән кердем. Анда көрт салып, сукмак ясалып беткән иде инде. Шуннан өйгә кереп, ишекне япкан гына идем, бер нечкә генә тавыш әкрен генә: «Ярый әле шәфкатьле булдың, миңа тимәдең, исән котылмаган булыр идең», – диде. Бу тавышны квартираның хуҗасы да ишетте. Күрәсең, убыр эт кыяфәтенә кергәндер инде.

*1977 елда Борай районы Абдулла авылында*
*Клавдия Александр кызы Низаметдиновадан (1921 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 184. Абзар иясе

Сыер бозауларга тиеш. Мин кич белән карап кердем дә, йоклап киткәнмен. Берәү тәрәзә кагуга уянып киттем. Чыксам, сыер бозаулаган, бозау басып тора. Күршеләрдән дә сорашкан идем, мине уятмадыгызмы, дип – берсе дә уятмаган. Абзар иясе килеп уяткандыр, дип уйлыйм инде үзем.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Бибимәүлиха Габдулла кызы Халитовадан (1890 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган;*
*1998 елда Илеш районы Иске Күктау авылында*
*Мәнкия Мулламөхәммәтовадан БДУ студенты*
*Айлия Хәмидуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 654;*
*2018 елда Илеш районы Ишкар авылында туып үскән БДУ студенты*
*Эльза Хөснуллинадан (1999 елгы) Илдус Фазлетдинов язып алды*

## 185. Зират иясе

Мин җиденчене генә тәмамлаган идем әле. Аннан соң укырга туры килмәде. Кыш көне, төнге сәгать берләрдә, бер карт укытучы белән күрше авылдан, җыелыштан кайтып киләбез. Бер зираттан үтәргә кирәк. Шул турыга җиткәч, бәләкәй генә

бер эт чыкты. Эт әле чананың астына кереп китә, әле ат өстеннән сикереп чыга, әле үзебезнең өстән сикереп үтә. Ат өректе һәм авылга кайтканчы чабып кайтты. Бераз баргач кына, әлеге эт кире зиратка кереп киткән иде. Зират иясе булды бугай. Безнең борчыганны яратмады.

*1977 елда Борай районы Абдулла авылында*
*Клавдия Александр кызы Низаметдиновадан (1921 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 186. Мунча иясе

*(1 нче вариант)*

Бервакыт тагын шулай төнге сәгать уникедә генә эштән кайтырга туры килде. Квартира хуҗасы мунча яккан иде.

Иптәшкә кече кызын ияртеп, мине мунчага җибәрде. Фонарь алып барган идек. Лампаны да кабызып куйдым. Шулай юына башлагач, кыз әйтә: «Апа, кара әле, таш сикерә!» – ди. Карасам, чынлап та, таш сикерә. Мин: «И, чукынчык нәрсә!» – дип кычкырып җибәрдем. Таш бераз туктап торды да тагын сикерергә тотынды. Аннан-моннан юынып, киенеп чыгып киттек. Ишекне ябуым булды, теге таш «шап» итеп ишекка килеп бәрелде. Монысын тагын нәрсә дип аңларга буладыр, белмим. Күрәсең, мунча иясе булгандыр инде.

*1977 елда Борай районы Абдулла авылында*
*Клавдия Александр кызы Низаметдиновадан (1921 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 187. Мунча иясе

*(2 нче вариант)*

Мунча иясе түбәдә яши, ә өй иясе – морҗа башында. Бар кешеләр дә мунча кереп беткәч, төнге сәгать уникедән соң мунча иясе мунча керергә бара. Мунчадан соңгы булып чыккан кеше ләүкәдә бер чүмеч эссе су калдырырга тиеш. Шулай итсәң, мунча иясе йорт хуҗаларына рәхмәт укыр, шул су белән юыныр да, үзенең минлеге белән чабынып чыгып китәр.

Су калдырмасаң, ул ләгънәт укыр. Бар савытларга пычрак кулларын, аякларын тыгып, болгатып бетерер, мунчаны пычратып чыгып китәр, диләр.

Иртән, теге чүмечтәге суны «бисмилла» әйтеп чыгарып түгеп, чүмечен юып куярга кирәк. Мунча иясен ачуландырсаң, чирләрсең, тәнең кычытыр, чәчең коелыр, дияр иде әни.

*1998 елда Илеш районы Иске Күктау авылында*
*Мәнкия Мулламөхәммәтовадан БДУ студенты*
*Айлия Хәмидуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 668*

## 188. Мунча җене

Бу вакыйга 1965–1970 елларда булган. Ишкарда бер хатын белән бер ир яшәгән, ди. Алар икесе дә «Сигнал» дип аталган колхозда эшләгәннәр. Бер кич шулай хатыны иреннән иртәрәк кайткан да мунча яккан. Өйдәге эшләрен бетергәнче, мунча да әзер булган. Ирен озак кына көткән. Төнге унике дә тулып киткән. Түзмәгән, киткән бу хатын мунчага. Ә мунчага барса, тегендә ире юынып утыра, ди!

Кергән бу хатын, иренә сораулар бирә икән. Ә ире бер сүзсез юынуын дәвам итә, ди. Теге ир су алырга торган, ә моның артыннан койрыгы чыгып тора, ди. Хатын койрыгын күреп, мунчадан чыгып йөгергән, ди. Шул вакытта капкадан ире кайтып кергән.

Бу хатын соңыннан гына аңлаган мунчада җен белән бергә утырганын. Бу хәлдән сон, хатын берүзе уникедән соң мунчага бармас булган, ди.

*2018 елда Илеш районы Ишкар авылында*
*Әгъния Әдиятуллинадан (1939 елгы, элекке савучы)*
*БДУ студенты Эльза Хөснуллина язып алган*

## 189. Юл иясе

Миңа бик озак чит җирләрдә йөрергә туры килде. Бу вакыйга Казахстаннан кайтып килгәндә булды. Кулымда – унике көнлек балам. Әниләргә кайтып барабыз. Ул вакытта транспорт юк бит инде. Кайта-кайта, вакыт кич булды, караңгы төште. Күрше авылга җиттем, тагын алты-җиде чакрым җир кайтасы бар. Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы. Шулвакыт кайдандыр кояш баешындагы кебек кызыл яктылык күренде. Шул яктылык, мин авылга кайтып җиткәнче, алты-җиде метр ераклыкта минем

юлымны яктыртып килде. Авылга керү белән яктылык юкка чыкты. Нәрсә булды – үзем дә аңламадым. Әллә юл иясе шулай ярдәм итте?

*1977 елда Борай районы Абдулла авылында*
*Клавдия Александр кызы Низаметдиновадан (1921 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 190. Куркыныч «өчпочмак»

Безнең Ишкар авылы аша олы М-7 трассасы үтә. Бу юлда бик еш кына төрле-төрле фаҗигаләр булып тора. Авылның башында «өчпочмак» дип аталып йөртелә торган бер начар урын бар. Анда һәрвакыт нинди дә булса юл фаҗигасе була. Күп кенә кешеләрдән ишетергә туры килде, янәсе, төнлә шушы урында бәләкәй бала тавышлары ишетелә һәм ак туй күлмәге кигән кыз юл буйлап йөри, ди.

*2018 елда Илеш районы Ишкар авылында*
*Азат Хөснуллиннан (1966 елгы, элекке милиция хезмәткәре)*
*БДУ студенты Эльза Хөснуллина язып алган*

### 191. Адаштыра торган урман

Берничә ел элек булган хәл бу. Ничәнчедер елның 8 март бәйрәме көнне һава торышы бик начар булган. Ачы җил, күз ачкысыз буран. Шунлыктан юлда булган барлык машиналар да туктап беткәннәр. Район үзәге – Югары Яркәйгә эшкә төшкән кешеләр, кайтмыйча, эшләрендә кунып калганнар. Бер ир: «Барыбер кайтам!» – дип, җәяү, Игъмәт урманы аша кайтып киткән. Үзе шушы Игъмәт авылында яшәгән булган ул.

Ләкин кайтырга дип чыгып китсә дә, өенә кайтып җитәлмәгән. Бу ирне озак кына эзләгәннәр – тапмаганнар. Кар эрегәч, үзе яшәгән авылның басуы янында үле гәүдәсен авылдашлары табып алганнар. Ничә ел Игъмәттә яшәп, шушы урманны иңләп-буйлап йөреп, бу ирнең адашып үлүенә бөтен кеше аптыраган. Шушы вакыйгадан сон, Игъмәт урманын «адаштыра торган урман» дип йөртә башлаганнар.

*2018 елда Илеш районы Ишкар авылында*
*Лиза Хөснуллинадан (1969 елгы, элекке тәрбияче)*
*БДУ студенты Эльза Хөснуллина язып алган.)*

### 192. Өй иясе

Әни сөйли торган иде, һәр йортта өй иясе бар, дип. Ул йортта тәртип ярата. Сызгырганны, кычкырганны яратмый. Андый кешеләрне төнлә саташтыра.

Ашап туйгач, ризыкларыңны җыеп, өсләрен каплап куярга кирәк, югыйсә, шайтаннар, төкерекләрен чәчеп, табак-савытларны, ашамлыкларны ялыйлар.

*1998 елда Илеш районы Иске Күктау авылында Мәнкия Мулламөхәммәтовадан БДУ студенты Айлия Хәмидуллина язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 671*

### 193. Өй иясен чакыру

Элек без яңа өйгә күчкәндә, өй иясен дә үз яныбызга чакыра идек. Башта төрле-төрле ризыклардан мул итеп сый-хөрмәт әзерлибез. Бөтен гаилә белән өстәл тирәсенә утырабыз. Өстәлнең бер кырыена өй иясенең өлешен дә куя идек: аш, чәй-шикәр, ипи һ.б. Шуннан берәребез табагачка атланып, тышка чыгып китә дә:

– Өй иясе, өйгә кер! – дип, йорт тирәли әйләнеп йөри. Аннан ул ишек ачып, өй иясен алдан «кертә» иде. Без:

– Әйдә, өй иясе, үз урыныңа түрдән утыр, – дип, аны табын янына чакыра идек. Шуннан соң өй иясе йортта яши башлый һәм гел тынычлык, иминлек кенә китерә, имеш.

*1998 елда Илеш районы Исәмәт авылында Нажҗия Шәмсүмовадан БДУ студенты Гүзәлия Маликова язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 673*

### 194. Җен

Безнең авылда элек җеннәр дә яшәгән. Әнием сөйли торган иде, ул аларны үз күзләре белән күргән.

Бервакыт караңгыда авыл урамнарының берсеннән, ташландык йорт кырыннан үтеп барган ул. Кинәт өй эченнән гәүдәсе кешенекенә охшаган йонлач бер нәрсә килеп чыккан. Авызы сап-сары, тешләре, йоннары күмердән дә карарак, ди. Бу нәрсә әнинең каршысына йөгереп чыккан да кинәт юк булган. Әнием сүгенә-сүгенә юлын дәвам иткән. Җен-фәлән күзеңә күренсә, сүгенергә куша иде ул. Алар шуннан курка, ди.

Бервакыт шулай, үзем фермада учетчик булып эшләгәндә, төнлә дежурга китеп барам. Авылда Суфиян бабайның зур эте бар иде, Юлбарыс исемле. Ул эт әллә нинди сәер холыклы иде.

Туры юл дип, чокыр-чакырлардан, куаклар, корыган әремнәр арасыннан барам шулай. Кинәт каршымда гына йонлач адәмгә охшаган бер әйбер пәйда булды. Мин куркып туктап калдым. Шулай да әзерәк алга атлаган булдым. Кинәт теге йонлач нәрсә Суфиян абыйның эте – Юлбарыска әйләнде. Тагын куркып туктадым. Бераздан янә бер-ике адым алга атладым. Теге эт күзләрен тутырып миңа карап торды да шайтан таягына әйләнде... Әллә күземә күренде, әллә чынлап шулай булды. Ләкин ул этне авылда бүтән бөтенләй күрмәдем. Бәләкәй чакта, кичен зират яныннан үтеп китеп барганда, эчтә утлар янганы күренә иде. «Әнә, фәлән әби кабереннән чыккан, күзләрен яндырып карап тора», – дип сөйлиләр иде...

*1998 елда Илеш районы Иске Күктау авылында*
*Мәнкия Мулламөхәммәтовадан БДУ студенты Айлия Хәмидуллина*
*язып алган. – Фазлетдинов, 2018, № 660*

## СӨЙЛӘКЛӘР

### 195. Мин Тукайны күрдем

Тукайны мин Күнгер ягындагы Уса авылында күрдем. Ул инде җиткән егет иде. Асрау кызыбыз әйтә: «Әнә шул егет Тукаев инде». Бу вакытта Тукай веса янында басып тора иде.

Мин аның янына барып, ныклап үзе белән сөйләшә алмадым. Ул вакыта, без яшь чакта, ирләргә йөзне күрсәтү юк иде. Яннарына да бару юк иде. Минем белән дә шулай булды. Мин Тукайның шигырьләрен белә идем. Күбесен яттан белә идем. Шундый зур шагыйрьне үз күзем белән күргәч, үземне бәхетле итеп саныйм.

*1977 елда Борай районы Кузбай авылында*
*Дөррия Вахитовадан (1884 елгы, Пермь өлкәсенең Байсин*
*авылында укыган) БДУ студентлары язып алган*

### 196. Ленин белән очрашу

1915 елда сугышка бардым. Аннан 1918 елның март аенда гына кайттым. Карпат тауларында йөрдек. Ашарга юк иде, таш кимереп яттык. Без Карпатта чакта ук патша өчен сугышмагыз, дигән язу бар иде.

Шунда безнең янга Ленин барды. Аны без көн буе көттек. Дүрт рәт итеп тезеп куйдылар. Ленин нәкъ минем каршыма гына килеп төште. Безнең аралар 4-5 метр чамасы гына иде. Ленинны 28 немец офицеры көтә иде. Лении алар белән перемирие  ясарга килде. Ул безнең белән сөйләшеп тормады, исәнләште дә китте.

*1977 елда Борай районы Кодаш авылында*
*Габбас Хәйбрахман улы Хәйбрахмановтан (1895 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 197. Җеп еланы

Миңа бер 17–18 яшьләр булгандыр инде. Малайлар белән бергә су керергә бардык. Минем судан чыккач, бөтен тәнемне карап чыга торган гадәтем бар иде. Карасам, уң кулыма бер кыл еланы кереп бара. Аны бездә тагы «җеп еланы» дип тә йөртәләр.

Моны күргәч, бик нык курыктым. Шул килеш абыем янына йөгереп бардым. Абый шытырдытып тартып алды. Ә аны алай алырга ярамай икән. Бәләкәй бер агач кисәген куеп, әкрен генә бөтерә-бөтерә, еланны шунда уралдырырга кирәк. Шуннан үзе чыгып бетә, ди. Еланның башы кулның тиресе эчендә калган. Ул өрелеп шеште.

Шул елан, кояш кыздырганда, эт өргән саен балалый икән. Кулымның авыртуы йөрәккә төшә башлады. Шуннан без әни белән Кузлов тегермәненә киттек. Ул тегермән безнең авылдан биш чакрым ераклыкта иде. Кояш кыздыра. Кулым тагы шешә башлады. Тегермән марҗалары шомырт агачының көлен кулга ябарга куштылар. Яптым, бер файдасы да булмады. Шуннан сыер сөтен эретеп, кулны шуңа тыгып, тыныч урында утырырга кушты берәү. Һәм шулай эшләдем дә. Кулыма эремчек куеп, тыныч җиргә кереп яттым. Бераздан карасам, дүрт җеп еланы чыккан. Тагын шулай итеп тыныч кына урында утырдым. Минем кулдан 11 җеп еланы чыкты. Шулар арасында инә елан да бар иде. Шулай итеп, кулым төзәлде. Бик озак еллар ярасы бетмичә йөрде.

*1977 елда Борай районы Абдулла авылында*
*Гыйлемхан Таһир улы Таһировтан (1907 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 198. Кулак калдыгы

Сугыш вакытында безне, өч хатынны, Кузбайдан Караидел районына утын хәзерләргә җибәрделәр. Мине старший итеп куйдылар. Теге ике хатын – яшь кенә солдаткалар. Атлар-фәләннәр юк. Алты көн бардык. Кайчак атына эләгеп китәбез, кайчак җәяү элдерәбез. Шулай алты көн бардык.

Кыш буе эшләдек. Башка җирләрдән дә киләләр. Кыш бит. Суык. Сәгать тугызларда эш башлыйбыз. Кисеп аударган агачны хатыннар белән җыелышып сөйрәп чыгарабыз. Ирләр фронтта.

Без тырмашабыз инде. Шулай кыш буе эшләдек. Ашау юк инде. Карточка белән бирәләр. Как сөяккә калдык. Шулай да әйбәт эшләдек. Ударник ясадылар безне. икәү генә калдык. Беребез түзмәде, бахыр, качып кайтып китте, чыдый алмагандыр инде.

Шулай яз җитте. Безне кайтара башладылар. Җыендык та кайтырга чыктык. Үзебез куркабыз. Безгә бер генә юл кайта. Үзе тар гына. Бер урманга кунарга туктадык. Ашарга ипи генә инде. Бер котелок бар иде, шуның белән су кайнатып эчәргә булдык. Арылган булгандыр инде. Икебез дә йоклап киткәнбез.

Уянып китсәм, күземә күренәме, дип торам! Безнең авылдан 30 нчы елларда бер кулакны раскулачивать иткәннәр иде. Авылның мәзине иде ул. Шуның малае Габбас икән бу. Битен сакал баскан, көчкә таныдым. Ул да таныган икән. Аларны раскулачивать иткәндә, мин дә бар идем. «Исәнме, Әдилләтәй!» – ди. Мин әйтәм: «Бик шәпбез». Үзе әзмәвердәй ир. Куркыта да. Иптәшем уянды. Ул-бу булса дип,  бер агач кисәген алып куйдым. Теге башта әйбәт кенә сөйләшә иде. Минем дә ачуы килеп:

– Безнең ирләр сугышта, син нишләп йөрисең? – дигәч кызып китте.

– Төкерәм мин синең сугышыңа, Совет властеңә! – дип, минем өскә килә. Итек кунычында пычагы да бар. Миңа да кыюлык каян килгәндер, китереп күкрәгенә төрттем бит, әй. Миннән мондый эшне көтмәгәндер инде, әллә үзем ныграк бирдем, егылды-китте бит бу!

Без иптәшем белән кача башладык. Теге куа килә, хәлебез бетә башлады. Йөгереп, бер текә тауга менеп киттек. Төнлә бит бу. Бер агач төбенә постык. Куркып ятабыз инде. «Тотса, үтерә бу безне»,  – дип. Бәхет бераз бар икән: күрмәде бу безне, йөгереп ары китте. Иртәнге якка без үзебез дә Кузбайга кайтып җиттек. Силсәвиткә барып сөйләдек. Икенче көнне милиция килде.

Бездән Габбасны сораштылар. Бер-ике көн үткәч, хәбәр килде: тотканнар кулак калдыгын. Ул, чынлап та, сугыштан качып йөргән икән.

*1977 елда Борай районы Кузбай авылында*
*Әдия Барый кызы Нәбиевадан БДУ студентлары язып алган*

### 199. Мулла яхшы булмый, козгын кош булмый

Муллалар алар бит – алдакчылар. Элек бездә Мирзаһит мулла Тупиев бар иде. Алама, икейөзле кеше ңде. 1930 елда мин өйләндем. Үземнең комсомолец вакыт, ә эти-әни – дин кешеләре. Алар туйны, никах укытып, муллалар белән ясамакчылар иңде. Мин якын да бармыйм.

Бер көнне шулай әти әйтә: «Муллай, – ди, – бер литр аракы алып кайт әле», – ди. Алып кайттым. Карыйм: өйдә бабай буласы кеше белән мулла Мирзаһит утыралар. Тегеләр качып кына никах укыганнар икән. Миңа да әйтмәгәннәр. Бабай: «Бәхетле булың, улым», – диде дә кайтып китте.

Мулла белән эти эчәләр. Исереп алдылар бит болар! Мулла абзый да исерде. Минем янга килде дә: «Алдагы елга да килергә язсын, улым», – ди. Янәсе, бу хатынны ташлатып, икенче елга да никах укымакчы була. Якасыннан эләктереп алып, җилтерәтеп чыгарып җибәрдем хәчтерүшне. Бераз капка төбендә таптанып торды-торды да җырлый-җырлый урам буйлап кайтып китте. Менә сиңарга мулла, менә сиңарга изге кеше. Мулла – кеше түгел, козгын кош түгел шул. Үзләре «алла» диләр, үзләре җинаять ясыйлар. Минем аларны бәләкәйдән җаным сөймәде, әле дә күрәсем дә килми үзләрен.

*1977 елда Борай районы Кузбай авылында*
*Муллаян Нәби улы Нәбиевтан (1908 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 200. Ат эзләгәндә

1914 елны беренче империалистик сугыш була бит. Шуннан минем ике абзый да сугышка китә. Ике ат була безнең. Баерак чак. Көз көне, атларны карарга бер малай йөртәбез. Кичтән атларны җибәрәбез. Атлар юк бердән бер көнне. Инәй котыра:

– Атларны да таба алмыйбыз, – ди. – Шәмсемөхәммәт кызлары сабан да сөрә әле, – ди.

Атны эзләп, мин киттем урман ягына, сеңлем – Калмашка. Ул елны игеннәр уңган иде. Шуннан киттем. Томанрак көн иде. И йөримен, и йөримен. Көн кыска. Бер нәрсә күренми. Кар-

лы-бозлы яңгыр ява. Бер якка тоттым да киттем. Чабатаның да киндерәләре өзелде, оекчан калдым. Һаман барам.

Берзаман ут күренде. Авыл булып чыкты бу. Безнең авылга охшамый. Койма ярыгыннан бер мунчадан ут күренә. Тавыш-тын юк. Ишеген ачтым. Кеше юк. Ут бар. Биткә җылысы бәреп тора. Мунчага кереп утырдым, ләүкәсенә. Эреп утырам. Һаман кеше юк. Чикмәнне таш өстенә куйдым.

Йокылы-уяулы утырам. Аяк тавышы. Таш артына качтым. Ишек ачылды да бер кыз, бер егет керде. Боларны күргәч, әзрәк җан керде. Ул догалар укыйм. Кыз кулында бер төен.

– Сиңа күчтәнәч бу, – ди кыз егетенә.

Икесе чөңгелдәшәләр генә. Аларның әкрен генә сөйләшкән тавышына эреп, йоклап киткәнмен. Бер заман егет кызга:

– Кола ялан бит монда, – ди.

Мин моны ишеткәч:

– Абзыкай, минем атлар да юкмы анда? – дим.

Минем тавышны ишеткәч, тегеләр ничек атылып чыкканнарын да сизмәделәр. Мин ләүкәдән төштем. Тегеләрнең төене калган, бәхеткә каршы. Төендә бер пол аракы, күчтәнәчләре бар. Йөзеп, пирогларын, ипи кисәкләрен ашадым да аннары ятып йокладым. Иртән иртүк тордым.

Мин кунган мунчаның хуҗалары бик бай кешеләр, күрәсең. Бик яхшы йорт, урыс капкалар. Урамга чыккач, бер кешене очраттым. Аңардан:

– Бу кем йорты? – дип сорадым.

– Ул йорт Габидулла хаҗилар йорты, балам, – ди. – Нишләп йөрисең, иртән иртүк? – ди.

Шуннан мин үземнең хәлне аңа аңлатып бирдем.

– Менә безне үткәч, Шаргаен яланы бар. Ике ат йөри иде анда. Син, балам, шунда гына бар, – ди.

Аңарга рәхмәт әйттем дә авылдан чыктым. Әкрен генә барып җиттем. Атлар каенга терәлеп торалар. Иплән кенә атларны тотып, бер пол аракыны кесәгә тыгып, авылга юнәлдем. Кайтып җиттем. Сеңлем әз генә йөргән дә кайткан. Ә мин кайтмагач, бик борчылганнар өйдәгеләр. Мин кайтып кергәч, и елаш, и

күреш башланды. Теге пол аракыны күрше Солтангәрәй абзыйга бирдек. Шуннан соң аның малайлары булыша башладылар.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында укытучы-пенсионер Зыяда Латыйповадан БДУ студентлары язып алган*

### 201. Тун тиреле каз

Югары очтагы Солтан Сакаев сугыштан иртәрәк кайтты. Нәкь казларның утырган чорында кунак җыйдылар. Без дә бардык. Хатыннар астында каз утырган сәкегә утырдылар, тезелешеп. Каршыларындагы аракыны эчмичә, сәке астына – банкага салалар икән болар. Ә каз тегене банкадан эчеп барган.

Кунаклар ашадык, эчтек тә таралыштык. Солтанның хатыны, табын җыештырып йөргәндә, банканы күргән. Казга караса, каз таралып төшеп оясында үлгән.

– И Аллаһ, утырган чагында гына ниләр булды икән? – дип бик кайгырышалар.

Шуннан казны көллеккә чыгарып ташлыйлар. Хатыны, уйлап тора да: «Әз булса да йоны булыр», – дип йолкып ташларга була. Инәсе дә каршы килми. Йолкып, чыгарып ыргыталар да йокларга яталар.

Иртән берәү ишек шакый. «Кем булыр?» – дип, ишек ачсалар, шәрә каз басып тора. Фатыйманың коты чыга. Бианай карчык эшнең нидә икәнен аңлап ала. Инде шәрә казны унике күкәйгә утыртып булмый бит. Тиредән тун тегеп утырталар болар.

Каз бәбкәләрен чыгара, үстерә. Бу тун тиреле каз җәй буе авылда, Түбән урамда башка казларны куркытып йөри.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында укытучы-пенсионер Зыяда Латыйповадан БДУ студентлары язып алган*

### 202. Рамазан ае килгәч

Безнең авылда бер бабайның кызы була. Бабайлар кунакка барырга җыеналар, кызга каклаган казны күрсәтәләр дә әйтәләр:

– Озын-озын Рамазан ае килер, – диләр. – Бу казны шул вакытта ашарбыз, – диләр һәм әлегә ашамаска кушалар.

Әтиләре кунакка киткәч, боларга ишек шакыйлар. Кергән кеше Рамазан исемле була. Ул боларның сөйләшкәннәрен тыңлап тора да керә, һәм кыз моңа казны ашата.

Бабай кайткач сорый:

– Кая каз?

– Мин аны Рамазанга ашаттым, – дип җавап бирә кыз.

– И аңгыра! – ди бабай.

Ә Рамазан әйтә:

– Аңгыраңны ачтырдым инде, – ди.

*1970 елда Чакмагыш районы Тозлыкуш авылында*
*Шаһибәк Биктимеровтан (1881 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 203. Ике такмак

Элгәре безнең авылда персидәтелнең малае көндез генә эшләп йөри икән, ә бухгалтер малае көндез дә, төнлә дә эшли икән. Шуларга атап такмак чыгарганнар:

*Безнең авыл – зур авыл,*
*Иске Ихсанга кая ул.*
*Көндез веялка әйләндерә,*
*Төнгелеккә – каравыл.*

Беренчесе тагын кешене өйрәтергә бик оста булган. Аны да такмаксыз калдырмаганнар:

*Бикмөхәммәт – тәл-тәл җимеш,*
*Бик шәпсең бит бүтәнгә.*
*Алла бирсә, гомерең булса,*
*Арыш чәчмә түтәлгә.*

*1970 елда Чакмагыш районы Тозлыкуш авылында*
*Шаһибәк Биктимеровтан (1881 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 204. Мич чыгаргач

Авылда бер карт булган. Бервакыт ул мәдрәсәгә килеп керсә, шәкертләр суык су белән тәһарәт алып утыралар икән. Бу мәдрәсәнең миче дә юк, ди. Шуннан теге карт әйтә:

– Сез кайсыгыз – кирпеч, кайсыгыз – су, кайсыгыз балчык китерсәгез, мин сезгә мич чыгарып бирер идем, – ди.

Шулай итеп, шәкертләрнең кайсысы – балчык, кайсысы – ком, кайсысы су китерә. Карт көн ярымда пичне чыгарып бирә. Ягып җибәрәләр. Бер могҗиза сымак була, ди.

– Бабай, нәрсә бирәек сиңа? – дип сорыйлар шәкертләр.

Бабай:

– Миңа бернәрсә дә кирәкми, тик сез минем иман белән генә китүемне теләгез, – дигән, ди.

Шәкертләр шулай дип кычкырып, теләп җибәргәч, бабай үксеп-үксеп еларга тотынды, ди. Күңеле тулып киткән инде, күрәсең.

*1970 елда Чакмагыш районы Тозлыкуш авылында*
*Разия Фәхретдин кызы Камалиевадан*
*(1905 елгы, өчьеллык белеме бар)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 205. Яшканың үлеме

Күзәй авылында марилар яши. Марилар бер-берсенә хыянәт итмиләр. Алар йомшак кына итеп эндәшкәнне яраталар.

Гражданнар сугышы вакыты. Күзәй авылына Яшка исемле коммунист килеп төшкән. Ул, акларга каршы көрәшү өчен, отряд җыярга җибәрелгән кеше була. Аның шундый эш белән йөргәнен сизеп алганнар. Күзәйнең бай марилары Иске Якшый авылы байларына килеп әйткәннәр. Иске Якшый авылыннан Зәки һәм Бәшир картлар Күзәй авылына киткәннәр. Алар барып, Яшкага: «Сыпыр моннан яхшы чакта!» – дигәннәр.

Яшка каршылашкач, аны кулга алганнар. Авылның старостасы Нуретдин карт Гайнетдингә җибәргән. Газиз карт, Гайнетдин бергәләп Яшканы волостька җибәргәннәр.

Юлда барганда, Балтач белән Күзәй авылы арасында аны тукмаганнар, эшен бетереп куйганнар. Аны Танып елгасы буена күмгәннәр.

Яшканың күкрәк сөякләрен сындырып бетергәннәр. Әнисе жаловаться итеп караган. Аңа бер-ике капчык бодай биреп

котылганнар. Яшка бик яхшы, батыр кеше булган. Әгәр ул әле исән булса, Уфада яки Москвада эшләр иде.

*1964 елда Балтач районы Иске Яхшый авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

**206. Яшка батыр**

1918 ел. Минем сугыштан кайткан еллар иде. Авылда каты көрәш бара. Халык аңсыз бит инде. Аларга яңа тормыш турында аңлатырга кирәк иде. Аңсыз халык һәрбер яңа тәкъдимгә каршы төшә, тавыш куптара. Актив кешеләр дә авылда күп түгел, дошманнар һәрбер активны үтерә торалар. Мин кайтып төшкәч, күрше Рәхмәтуллин Хәйрулла:

– Кил әле монда, сине бульшевик дип әйтәләр, дөресме? – ди.

Мин әйтәм:

– Дөрес, – дим.

Мин әйтеп тә бетмәдем, китереп бирде бу минем маңгайга. Күздән утлар күренеп китте шул, балалар. Мине халык аралап алды. Моннан соң минем бик тә ачу чыкты. Үз-үземә әйтәм: «Болар белән бик нык көрәшергә кирәк», – дип уйлыйм.

Шул көнне үк күрше мари авылындагы коммунист Яшка янына киттем.

Ул бик актив кеше иде шул. Бөтен тирә-яктагы авылларны оештырып, агарту эше алып бара иде. Ну, туганнар, аңа бер дә булышучы кеше булмады шул. Ул үзе бик гайрәтле, достоин кеше иде. Буйга артык озын булмаса да, көчле, юантык кеше булыр иде. Ул күренүгә кайбер кешеләр куркып карыйлар, кайберләре сокланалар, ә дошманнар теш кайрыйлар. Килә иде дә кулларын селки-селки сөйләргә тотына иде. Аның сүзе аңлаешлы, вупше аңлатып сөйли торган иде ул. Менә шул Яшка белән инде без бергә көрәшне башладык.

Бердән бер көнне Яшка бер болынны чаптыра башлаган икән. Халык аның кем өчен чаптыруын да сорап тормый, кычкырына башлый. Дошманнар:

– Нәрсә карап торасыз, давай, үтерергә кирәк, чаптырмыйбыз! – дип даулаша башлыйлар. Халык Яшкага таба йөгерә. Моны күреп, мин дә йөгердем. Юлда күршене очрадым.

Ул әйтә:

– Кая йөгерәсең, барма, үтерерләр бит үзеңне! – ди.

Мин аны тыңладым, бармый калдым. Яшканы тотып, старостага китерделәр. Ул вакытта староста Газиз карт иде. Ул Яшканы кирәкмәгән кешеләргә тотып җибәрә. Ике авыл арасындагы күпергә җиткәч, Яшканы үтереп, күпер астына тыгып куялар. Аны күренеп торган  аякларыннан тартып чыгардык. Икенче көнне аны халык яхшылап, кадерләп күмеп куйды. Куркыныч булды ул вакытта, әй балалар.

Юк шул, онытылмый Яшка, халык арасында аның исеме һаман йөри. Халык аны «Яшка батыр» дип атый.

*1964 елда Балтач районы Иске Яхшый авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

## МӘЗӘКЛӘР

### 207. Мәтык

Бер кияү әбисенә кунакка барган. Ул күп ашый торган булган. Әбисе моны туйдыра алмый аптыраган. Коймак пешергән дә: «Мә, тык!» – дип, алдына китереп куйган. Кияүгә коймак бик ошаган, ди. Өенә кайткач: «Әби мәтык пешергән иде, бик тәмле була», – дип сөйли икән.

### 208. Гөбе боткасы

Бер кияү әбисенә кунакка барган, ди. Әбисе киявен дөге бәлеше белән сыйлаган. Кияүгә дөге белеше бик нык ошаган, моңа кадәр ашап караганы булмаган икән. «Нәрсәдән бу бәлеш?» – дип сорагач, әби кеше: «Дөгедән», –дигән. Кияү моны «гөбе» дип ишеткән. Өенә кайткач, гөбене ваклаган да, әнисенә бәлеш пешерергә кертеп биргән.

*Әлеге мәзәкләрне 1977 елда Борай районы Чишмә-Борай авылында*
*Сәвия Шәйсолтан кызы Муллагалиевадан (1915 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 209. Аңгыра кияү

Бер яшь кияү, кәләше янына килеп, дүрт көн кунган, ди. Икенче атнаны килгәч, теге кызның өен тапмый икән бу.

– Аларның капка төбендә кара сыер ятып тора иде, бу өйнең капка төбендә кара сыер юк, – дип әйткән, ди.

*1977 елда Борай районы Чишмә-Борай авылында*
*Җәмилә Вәлинур кызы Газизовадан (1913 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 210. «Ике генә каптым ич!»

Янгир исемле кияү бабаларына кунакка барган. Бик оялып кына ашаган. Шуннан ярты тәекмәкне алган да күтәрмә астына кереп утырган. Бик шәп кенә яңгыр ява башлаган. Бабалары күтәрмә алдына чыккан да: «Яңгыр ишә-ә-ә», – дигән. Ә Янгир күтәрмә астыннан: «Ишә ишми ни, ике генә каптым ич!» – дип әйткән, ди.

### 211. Оялчанлык

Борын кияүләр ашка барганнар, ди. Кайткач, берсе икенчесеннән сорый икән:

– Ашы тәмле идеме?

– Нигә үзең ашамадыңмени?

– Калагым юк иде.

### 212. Тапкырлык

Бер гармунчыны аш мәҗлесенә чакырганнар. Уйный да уйный икән. Моны ашарга да уйнарга кыстыйлар икән. Теге бернәрсәгә кагылмыйча, тик утыра, ди. «Нигә ашамыйсың?» дигәч, «Кашыклылар кашыкларын куйсыннар әле, миңа кашык бирсеннәр әле», – дигән, ди, егет.

*Әлеге мәзәкләрне 1977 елда Борай районы Кузбай авылында*
*Факия Нури кызы Әхмәтовадан (1903 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 213. «Кайсы тирәдә туктыйм?»

Хуҗа Насретдин хатыны белән йоклап ята икән. Хатыны Хуҗага: «Тегеләйрәк кит әле» – дип әйткәч, Хуҗа торган да киенеп чыгып киткән. Ике көн баргач, бу бер авылдашын очрата икән.

– Әй син, минем хатынны күреп әйт әле, кайсы тирәдәрәк туктыйм икән мин?

*1977 елда Борай районы Чишмә-Борай авылында*
*Мөбәрәк Гарифҗан улы Мөхәммәтҗановтан (1906 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 214. Тыйнак кияү

Кияү, беренче тапкыр әбиләренә кунакка килгәч, тартынып ашамый утыра икән. Шулай көн буе йөреп, йокларга яткач, моның бик нык ашыйсы килгән. Өйдәгеләрнең йокыга китүен көткән дә, әкрен генә торып, мичтәге вак бәлешләргә үрелгән. Үрелүе булган – мич буенда сөялеп торган кисәү агачының аркасына килеп төшүе булган. Аны-моны уйлап тормаган кияү. «Әбием сизеп калып, кирәкне бирә икән», – дип уйлап, тизрәк кычкырып җибәргән.

– Әби, берне генә алам дигән идем бит!

Бу тавышка өйдәгеләр бар да сикерешеп торганнар, ди.

## 215. Шунда ук бар идеңмени?

Оныгы әбисен һәрвакыт шаяртырга ярата икән. Бервакыт шулай, әбисе, бик мавыгып китеп, үзенең яшь чагында ничек килен булып төшүен сөйли икән.

– Менә без, бабаң белән икәүләп, кашувкага шушылай янәшә утырып, кыңгыраулы пар атлар белән генә урам буйлап чаптырып капка төбенә килеп туктадык...

Шулвакыт оныгы, әбисен бүлдереп, тизрәк җөпләргә ашыккан:

– Әйе шул, әбекәй, әле дә хәтеремдә, мин йөгереп чыгып, капка ачкан идем, әйеме?

Әбисе исе китеп оныгына карап торган да:

– Соң, шайтан малай, син шул вакытта ук бар идеңмени әле? – дигән, ди.

## 216. Кызганган

Бер шофер машинасын бик кызу йөртә торган булган. Бервакыт ул юл буйлап җәяү барган әбине куып җиткән дә, аны кызганып, кузовка утырткан һәм җилдереп алып та киткән. Гадәте буенча, машинасын бик кызу куган бу. Килеп җиткәч, әбидән:

– Я, әбекәй, иркенләп ял итеп килдеңме бераз? – дип сорый икән.

Әби:

– Рәхмәт, балам, ял иткәндәй булмасам да, бигрәк иркенләп килдем. Машинаң тартмасының бөтен почмагында да булып чыктым, – дип, ыңгыраша-ыңгыраша капкага таба атлаган.

**217. Кашык бушагач**

Әминә исемле хатын бер табын итеп кунак чакырган икән. Кунакларны бик кыстап ашата икән бу. Ләкин күршесендә утырганы, никадәр кыстаса да, ашамый утыра икән.

– Ашы бигрәк тәмле, әз генә булса да ашап кара, – дип, кунаклар да кысташа башлаган.

Ахрысы, түзмәгән кунак:

– Һәй, бигрәк түзем түгелсез дә икән! Ашармын, Аллаһ боерса, менә Әминәдән кашык кына бушасын, – дигән, ди.

Карасалар, хуҗа хатын күршесенең кашыгы белән ашап утырган, имеш.

**218. Кунакчыл хуҗа**

Берәү кунак чакырган икән. Табынын бик матур әзерләгән. Юк нәрсә үзе бар икән. Гел генә татлы нәрсәләр ашап утырган бер кунакка ачуы килеп, хуҗа хатын:

– Өстәлдәге курмы өчен түгел, фурмы өчендер, – дип әйтеп куйган, ди.

Ә үзе, кинәт кенә ашаудан туктаган кунакларны күреп, бик аптыраган икән.

**219. Салкын канлы**

Бер укытучының укучылар арасында бер дә почеты юк икән. Халык моңа бик аптырый. «Бик түземле, салкын канлы кеше бит, югыйсә. Нигә алай соң?»

Бервакыт укучылар бакчада эшлиләр. Арадан бер шугы, әлеге укытучының иелгәнен күреп, «шап» итеп артына тибеп киткән. Укытучы, салкын канлылыгын сакларга тырышып, үгетләгән тавыш белән:

– И, шушы Фәһимнең гадәте, – дип, малайның артыннан сөйләнеп калган.

### 220. Аңласаң, аңла...

Бер юлчы караңгыга калгач, якындагы авылда торган танышларына кереп, кунып чыгарга булган. Танышлары бик ачык чырай күрсәтми генә, юлчыны ишек төбенә иске-москы киемнәр салып, йокларга яткырганнар.

Юлчы, арыганга күрә, бик сайланып тормаган, җәйгән урынга ятып йоклаган.

Иртә белән юлчы уянгач, танышлары моннан сорыйлар икән:

– Я, кем, ничегрәк йокладың?

– Рәхмәт, хуҗалар, сугып үтергәндәй йокладым, – дип, юлчы саубуллашып чыгып киткән.

*Әлеге мәзәкләрне 1970 елда*
*Чакмагыш районы Үрнәк авылында*
*Зөһрә Бәшировадан БДУ студентлары язып алган*

### 221. Аю тоткан

Ике кеше урманга киек ауларга барганнар. Берсе чокырга төшкән дә:

– Мин аю тоттым! – дип кычкырган.

– Өстерәп чыгар монда, – дигән икенчесе.

– Ул чыкмый, – дигән теге.

– Ул чыкмаса, үзең чык.

– Мине дә чыгармый шул.

### 222. Наданлык

Бер надан кеше муллага мәчеттә:

– Бер дә китап сүзе сөйләмисең, китабыңны актарып кына утырасың, – дигән.

Мулла:

– Сез мин сөйләгәнне тыңламыйсыз, мин сез уянсын дип, китапларны актарам да кәгазьләрне шыгырдатам, – дип җавап кайтарган.

*Әлеге мәзәкләрне 1970 елда*
*Чакмагыш районы Яңа Коты авылында*
*Рәйсә Миһрановадан БДУ студентлары язып алган*

### 223. Диктант язганда

Беренче класс укучылары беренче мәртәбә диктант язарга әзерләнәләр. Укытучы болай ди:

– Хәзер без, балалар, күрмичә язачакбыз. Моңа кадәр күреп язган идек.

Бер малай диктант барышында укытучыга:

– Апа, карагыз әле, Рәдиф күзен ачып яза, – дигән.

### 224. Физкультура дәресе

Укытучы физкультура дәресендә велосипед йөрткәндәге хәрәкәтләрне ясата. Ә бер малай дәрес вакытында туктап кала. Укытучының: «Нигә туктадың?» – дигән соравына малай:

– Мин таудан төшеп барам, – дип җавап бирә.

### 225. Сәүдәгәрләр

Ике сәүдәгәр юлга чыккан, ди. Шуларның берсе ничек тә булса, иптәшеннән алда барып җитеп, товарын кыйммәткәрәк сатарга уйлаган, ди. Шуннан атын бөтен көченә куып, иптәшен артта калдырып киткән. Шәһәргә килеп җитәр алдыннан, моның аты сөрлегеп, аягын аксаткан. Нишләсен, туктап хәл җыярдан башка чара калмаган.

Атын уртача гына юыртып килгән сәүдәгәр, моны куып җитеп узып барганда, кабаланучы болай дигән.

– Ник ашыгасың, атыңны хәл җыйдыр.

– Мин атымны аксагач кына хәл җыйдырам, – дип җавап биргән, ди, икенче сәүдәгәр.

### 226. Сыерга бозау ашату

Бер авылда печәнгә бик кытлык икән. Ләкин болар ничектер мал асрыйлар икән. Берчак боларга ерак туганнары килеп төшкән. Туганы сорый, ди:

– Апа, ничек итеп мал асрыйсыз, үзегездә печән үсми?

Апасы:

– Туганым, бозауны сыерга ашатабыз да, шулай сыерны асрыйбыз, – дигән.

Егет аптырашта калган. Һәм бик озак баш ватып йөргән. Икенче вакыт тагын сораган бу:

– Ничек итеп бозауны сыерга ашатасыз?

Апасы:

– Энем, бозауны сатабыз да, печән сатып алабыз. Шулай итеп, «бозауны сыерга ашату» була инде ул, – дигән.

**227. Юри генә әйттем**

Берәү Уфага баргач, базардан он алган, ди. Агыйдел аша боздан чыкканда бу:

– Әгәр мин чыгып җиткәнче боз ярылмаса, бөтен фәкыйрьләрне җыеп, шушы оннан икмәк пешереп ашатыр идем, – дигән.

Агыйделне чыгып җитәрәк, үзенең исән-имин котылуын күреп:

– Әй, ашатам менә, үземнең дә балаларым күп әле, – дип уйлый икән. Шулай дип әйтүе була, боз шартлап китә. Шуннан бу:

– Әй, юри генә әйткән идем, әллә ышанды да, шартлый башлады, – ди икән.

*Әлеге мәзәкләрне 1970 елда Чакмагыш районы*
*Яңа Калмаш авылында Гөлчирә Хәсән кызы Вәлиевадан (1885 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

**228. Барыбер үлгән инде**

Бер бабайның тавыгы үлгән. Ул аны карчыгыннан йолкыткан да, тазарттырып базарга сатарга алып киткән. Сатып торганда, бу тавыкны урлыйлар.

– Тавыкны урлаганнар, – ди, куркып, малае.

– Ярар, улым, ул барыбер үлгән иде инде, – дип җаваплый бабай.

*1970 елда Чакмагыш районы Имәнлекул авылында*
*Шафикъ Салиховтан (1894 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

**229. Контужен булган**

Бөек Ватан сугышы башлангач, бер авылның председателе сугышка киткән. Озак та үтмәгән, аннан әнисенә хат килгән.

«Бару белән контужен булдым, эшләр яхшы, борчылмагыз», – дип язган икән улы.

Бу хатны укыгач та, әнисе, күршеләргә кереп:

– Башлы кеше башлы инде ул. Малаем монда да персидәтел булып эшләгән иде, инде тегендә дә «контужен» итеп куйганнар, – дип мактанып йөри, ди.

*1970 елда Чакмагыш районы Имәнлекул авылында*
*Шәйхулла Ягъфәровтан (1907 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

**230. Жикет хакында**

Элегрәк, кием юк чагында, жикетны магазиннан табуы кыен булган. Бер әби җитеп килгән кызы белән генә торган. Аның иптәш кызлары жикет сатып алганнар кайдандыр. Бу әбинең кызы да жикет сорый башлаган, ди.

– Әни, әни, жикет алыйк әле, жикет! – дип әйтә, ди.

Бу әби аптырауга калган:

– И-и балакаем, ни хәл итим икән соң?!

Уйлаган-уйлаган да күршесенә кергән.

– И, Шәмсекамәр җаным, ни хәл итим икән, кызым җегет сорый, – дигән. – Ни соратучы юк, – ди икән.

Теге күрше аңлап алган да:

– И күршем, ул җегет түгел, жикет сорыйдыр, – дигән.

*1970 елда Чакмагыш районы Тозлыкуш авылында*
*Мәрзия Саттаровадан*
*БДУ студентлары язып алган*

# ӘКИЯТЛӘР

## ХАЙВАННАР ТУРЫНДА ӘКИЯТЛӘР

### 231. Үткер кияү

Төлке әйткән була: «Мин песигә чыктым әле», – дип, аюлар-бүреләр нинди кияүгә барганын сорагач. «Мыеклары болай, бөтен җәнлекләрне ашап бетерәм дип әйтте», – ди.

«Без аның белән ничек яшәрбез инде?» – дип, барлык җәнлекләр дә уйга кала. «Без аны кунакка чакырыйк, дус булырбыз», – диләр. Бүре – бер сарык, аю бер мичкә бал алып киләм, ди. Әзерләнеп беттеләр, ди. Кем чакырырга тиеш соң? Аю курка: «Минем йоннарым озын», – ди. Бүре тагын курка: «Әнә, куян барсын», – ди.

Мескен куян нишләсен, китте инде песи белән төлкене чакырырга кунакка. Килгәннәр болар. Песи: «Мало, мало», – дип әйтә, ди. Аю менеп китте дә агач башына, җәнлекләр барысы да таралышып качып беттеләр, ди.

Куян ылыс астында утыра. Песи белән төлке бер җиргә җайлашып утырдылар, ди. Бүре әйтә: «Бер җөннәрем дә калмаган, агачка сызырылып беткән», – ди. Куян мескеннең койрыгы өзелеп калган. Барысы да бер җиргә җыелып утырганнар да: «Айһай, бу кияү бик тә үткер, харап икән бу кияү», –диләр икән.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Бибимәүлиха Габдулла кызы Халитовадан (1890 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 232. Песи белән тычкан балалары

Тычкан балалары әйтә: «Әни, азрак урамга чыгып уйнап керик әле!» – диләр, ди. Тычкан-ана ризалыгын биргән.

Балалары урамнан кергәч, әйтәләр моңар: «Әнкәй, бер матур нәрсә күрдек, кояшта ялтырап ята».

Әнисе: «И балакайларым, ул нәрсә безне ашый торган нәрсә, әнә шул безне яшәтми инде», – ди икән.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Бибимәүлиха Габдулла кызы Халитовадан (1890 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 233. Үткер песи

Песи бик үткер нәрсә икән ул. Бервакыт бер әдәмнең авызына елан кергән. Теге елап, сөйләнеп йөри, ди: «Изгелеккә – явызлык бармы, юкмы?» – дип, ди.

Күрә, агач башында бер песи утыра. Шул песи янына бара, ди, бу. «Изгелеккә – явызлык бармы?» дип сорый, ди. Песи әйтә: «Колагым ишетми, кычкырыбрак әйт», – ди. Тегесе килеп кычкырыбрак әйткән иде, ди, песи еланны тартып та алды, ди. Менә песигә ышансаң-ышан!

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Бибимәүлиха Габдулла кызы Халитовадан (1890 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 234. Аю белән төлке

Борын бер заман аю урманда бер тургайны тотып алган, ди.

– Тукта әле, – ди ул. – Өченче көн төлке үрдәк тотып мактанган иде, мин дә аңа барып мактаныйм әле.

Аю, тургайны алып, төлке янына киткән, ди. Ә төлке аның тургай алып килгәнен күптән күзәтеп торган булган, ди.

Төлке:

– Аю дус, тапканың нәрсә була? – дип сораган.

Аю тешләрен кысып кына:

– Тургай, – дигән.

Төлке:

– Аю дус, ишетмәдем, бүген йоклаганда, баш астына таш куеп йоклаганмын, колакларым тонган, кычкырыбрак әйтче, – дигән булган, ди.

– Тургай! Тургай!

– Берсен генә дә ишетмәдем шул, авызыңа су капкан кебек сөйлисең. Ачыграк әйтсәң ни була, аю дус, – дигән төлке.

Аю бу юлы авызын тутырып:

– Тургай, тургай! – дип әйтүе булган, авызындагы тургай «пыр-р» итеп очып та киткән.

Төлке:

– Ә, ишеттем, тургай дисең икән, – дигән булган, ди.

Ә аю:

– Ишетүен ишеттең дә бит, тик тургайны очырттырдың шул, – дигән.

Шуннан төлке акыл өйрәтмәкче булып:

– Мактана белмисең, аю дус! – дигән, ди. – Дөресен әйткәндә, син – шыр тиле, сиңа «тургай» дип әйтмәскә иде, ә «кош» дияргә кирәк иде, шул чакта авызың да ачылмас иде, тургай да очмас иде, – дигән, ди.

*1970 елда Чакмагыш районы Таш Калмаш авылында*
*Разия Турьяновадан (1899 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 235. Кәҗә белән аю

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер кәҗә. Аның дүрт баласы булган, ди. Бу кәҗә, балаларына сөт җыяр өчен, көн дә кырга чыгып китә икән.

*Кырдан кырга йөримен,*
*Кыр җимеше китерәмен.*
*Саздин сазга йөримен,*
*Саз җимеше китерәмен.*

Кәҗәнең такмаклый-такмаклый кырга сөт җыярга киткәнен аю белеп калып, аның балалары янына килә. Һәм кәҗәнең сүзләрен кабатлый:

*Кырдан кырга йөримен,*
*Кыр җимеше китерәмен.*
*Саздин сазга йөримен,*
*Саз җимеше китерәмен.*

Кәҗә бәтиләре, «әни кайтты» дип шатланышып, ишек ачалар. Аю килеп керә дә дүрт кәҗә бәтиенең берсен ашый.

Икенче көнне кәҗә балаларына тагын сөт җыярга китә. Кәҗәнең такмаклавын ишетеп, аю тагын кәҗәнең йорты янына килә дә:

*Кырдан кырга йөримен,*
*Кыр җимеше китерәмен.*
*Саздин сазга йөримен,*
*Саз җимеше китерәмен, –*

дип кәҗәнең сүзләрен кабатлый.

Шулай ишекне ачтырып, тагын бер кәҗә бәтиен ашый. Инде кәҗәнең түзеп торыр хәле калмый. Йорты эргәсенә тирән итеп чокыр казый да ут яга, ә өстен чыбык-чабык белән каплый. Шуннан бер бәтиен аюны үзләренә кунакка чакырырга җибәрә.

Кәҗә бәтие:

– Аю бабай, аю бабай, сине әни чәй эчәргә чакырган иде, – ди.

Аю:

– Тукта әле, бүрегемне киим.

– Аю бабай, аю бабай, әни сине майлы ботка ашарга чакырды.

– Тукта әле, тунымны киим.

Аю бик кузгалмагач, кәҗә бәтие тагы кабатлый:

– Аю бабай, аю бабай, әни сине майлы ботка ашарга чакырды.

– Тукта әле, пимамны киим.

Шуннан кәҗә бәтие белән аю юлга чыкканнар, ди. Йорт янына килеп җиткәч, кәҗә бәтие чыбык-чабык өстеннән сикереп чыккан да:

– Аю бабай, әйдә, син дә сикер, – дигән.

Сикереп чыгыйм дигәндә генә, аю чокырга төшеп киткән. Һәм ут эчендә яна башлаган:

– Ай, башым, – ди аю.

Аңа каршы кәҗә:

– Ә, минем балаларымның башын ашаганда, яхшы иеме?

– Яхшы, яхшы ие.

– Ай, корсагым, – ди аю.

– Минем балаларымның корсагын ашагында, яхшы иеме?

– Яхшы, яхшы ие.

– Ай, аркам.

– Ә, минем балаларымның аркасын ашаганда, яхшы иеме?

– Яхшы ие.

– Ай, аякларым, – ди аю, көч-хәл белән.

Аңа каршы кәҗә:

– Ә минем балаларымның аякларын ашаганда, яхшы иеме? – дип сорау бирә.

Ниһаять, аюның җавап бирер хәле калмый, ул янып бетә. Янып беткәннән соң, аның аркасы – каретага, алгы аяклары – тырмага, арткы аяклары – кисәү агачына, корсагы – җилпүшкә (иләккә), күзләре – шарга, башы тупка әйләнә.

Менә шушы карета, тырма, җилпүшләрне файдаланып, кәҗә әле булса бәтиләре белән дөнья көтә, ди.

*1970 елда Чакмагыш районы Бәшир авылында*
*Шәмсинур Хисамиевадан (1885 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 236. Бал корты ничек кәҗәне җиңгән?

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер әби. Аның кечкенә генә яшелчә бакчасы булган. Бакчада җиләк-җимеш, яшелчә котырып үскән.

Бервакыт әбинең бакчасына кәҗә кергән. Әби куып-куып караган да чыгара алмаган. Кәҗә тәмам теңкәсенә тигән, һәм әби, елый-елый, урман буйлап киткән. Аңа урманда йонлач аю очраган. Аю:

– Әби, ник елыйсың? – дигән.

Әби хәлне сөйләп биргән. Аю әбине нык жәлләгән һәм аңа ярдәм итәргә булган. Шуннан болар икәүләшеп бакча янына килгәннәр. Аю бик усал итеп кәҗәгә:

– Кәҗә, яхшы чакта чыгып кит, югыйсә, мин сине тотам да ашыйм! – дигән.

Кәҗә моңа шылт та итмәгән. Аеруча кәефләнеп, кәбестә яфракларын кимерүен дәвам иткән. Бераздан үзенең яраткан җырын җырлап җибәргән һәм:

– Ме-ә-ә, ме-ә-ә, мөгезем көмеш, күзем пыяла, үзем дивана, сөзермен дә үтерермен, – дигән.

Аю, моны ишеткәч, җан-фәрманга урманга чапкан. Әби мескен нишләсен, тагын урманга киткән. Бара торгач, моңа бер ач бүре очраган.

– Әби, ник елыйсың? – дип сораган.

– Әй, ничек еламыйсың инде, бакчама кәҗә керде дә, һич куып чыгарып булмый үзен, – дигән әби.

Бүре:

– Әби, мин куып чыгарырмын, – дигән.

– Аю барды, куып чыгаралмады, син ничек куып чыгара алырсың икән, – дигән.

Ләкин бүре үз сүзендә нык торган, һәм болар бакчага яңадан килгәннәр. Кәҗә һаман да ваемсызланып рәхәтләнеп ашап йөри икән. Бүре нык гайрәтләнеп:

– Кәҗә, чык бакчадан, мин сине хәзер тотам да ашыйм, – дигән.

Кәҗә исә моңа койрыгын да селкетмәгән. Элеккечә җавап биргән:

– Мөгезем көмеш, күзем пыяла, үзем дивана, сөзәрмен дә үтерермен.

Бүре моны ишеткәч, койрыгын бот арасына кыстырып, урман буена сыпырткан. Әби тагын ялгызы калган. Өметсезләнеп, елап җибәргән. Шул чак чәчәктән-чәчәккә кунып, бал җыеп йөргән Нечкәбил әбине күреп ала һәм янына килеп куна.

– Җ-ж-ж..., әбекәем. Нинди кайгыга тарыдың? – дип сораган. Әби аңа хәлне сөйләп биргән. Ә Нечкәбил аның хәлен белгәч:

– Бер дә курыкма, әби, хәзер мин аны куып чыгарам, – дигән.

– Син нечкә генә көеңә куып чыгарырсың микән соң? Аю барды – куып чыгара алмады, бүре барды – куып чыгара алмады, – дигән әби.

Шулай да Нечкәбил белән әби бакча янына килгәннәр. Бал корты Нечкәбил киртәгә кунган да:

– Угымны кадармын, күзеңнән язарсың, чыгып кит яхшы чакта, кәҗә! – дигән.

Кәҗә моңа каршы:

– Мөгезем көмеш, күзем пыяла, үзем дивана, сөзәрмен дә үтерермен, – дигән.

Бал корты:

– Карап карыйк, – дигән һәм угын төзәп, туп-туры кәҗә өстенә килгән.

Кәҗә, мөгезләрен тырпайтып, дошманын сөзәргә хәзерләнгән. Ләкин бал корты бик нечкә, һәм җитез булганга, кәҗәнең әле алдына, әле артына төшкән һәм, кәҗә шәйләмәгәндә генә, аның уң күзен чагып та алган. Кәҗә авыртуга түзә алмыйча, киртәдән сикереп чыгып, урманга йөгергән. Шуннан бирле явыз кәҗә әбинең бакчасы ягына борылып та карамаган.

Ә әби белән бал корты Нечкәбил бик тату гомер итә башлаганнар. Нечкәбил бөтен семьясы белән әбинең чәчәкле бакчасына күчеп килгән, ә кәҗә исә үлгәндә, үзенең балаларына бакча ягына бармаска дип, васыять әйтеп калдырган.

*1970 елда Чакмагыш районы Рәҗәп авылында*
*Миңьямал Идрисовадан (1898 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## ТЫЛСЫМЛЫ ӘКИЯТЛӘР

### 237. Үги ана белән малай

Бер агайның өч баласы булган. Хатыны белән тигез генә гомер иткәннәр. Хатыны чирләп киткән, озак та тормыйча вафат булган. Шуннан бу агай бер ялгыз хатынга өйләнгән, ди. Ә үги ана малайны бер дә яратмаган.

Бер көнне бу малайны бик нык кыйнаган. Шуннан бу бала кошка әйләнеп очып киткән.

Вакыт үткән. Бер көнне өйләренә бер кош очып килгән. Әтисе башы очына килгән дә авызын ачарга кушкан, аңа бер калак май каптырган. Кыз туганнарының авызларына да берәр калак бал каптырган. Чират үги анага килеп җиткән. Ул авызын зур итеп ачкан. Шулвакыт бу кош аңа бер кап энә каптырган. Үги

ана шунда ук егылып үлгән. Кош исә яңадан агайның малаена әверелгән икән.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Фәрхикамал Мөзиповадан (1904 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 238. Явыз патша һәм тереклек чишмәсе

Борын заманда яшәгән, ди, бер патша. Ул тирә-якка явызлыгы белән дан тоткан. Үзенең хезмәтчеләрен бер дә юкка гына җәзага тарткан. Шул ук вакытта ул бик саран, комсыз да булган. Һәрвакыт башка патшалар алдында иң мактаулысы, иң хәзинәлесе булып күренәсе килгән.

Шушы ук патшалыкта бер ярлы малае яшәгән. Ул бик зирәк, акыллы икән. Бик күп тылсымлы нәрсәләр белгән. Ләкин могҗиза эшләү өчен, асылташ кирәк икән. Ә бу егетнең һичнинди байлыгы юк.

Бервакыт патша үзенең хезмәтчеләрен җыеп алган да:

– Минем озак гомер яшисем килә. Моның өчен нишләргә икән, белегез шуны. Әгәр тапмасагыз, җәзага тарттырачакмын, – дип әйткән, ди.

Хезмәтчеләр көн туу белән шуны белгән кешене эзләп киткәннәр. Көннәрдән бер көнне әлеге егетне табып, патша каршына китереп бастырганнар.

– Син беләсең икән дөньяда бөтен могҗизаны. Әйт, миңа ничек озак яшәргә? – дип сорый икән патша.

Егет әйткән:

– Җир йөзендә бер чишмә бар. Аннан су эчкән кеше әҗәлне үзе теләми торып үлми. Ләкин ул чишмә – караңгылыкта. Анда юлны яктыру өчен, асылташ кирәк.

Патша үзенә иң яхшы атларны хәзерләргә кушкан. Ике йөз акбуз ат иярләнгән. Ләкин егет шул вакыт әйтә:

– Кызыл айгырлар иярләгез, аларның күзләре үткен була караңгыда.

Егетне тыңладылар. Иярләделәр кызыл атларны, чыгып киттеләр кояш чыгышы ягына. Юлда барганда, бик чибәр кыз очра-

ган. Ул ап-ак атка утырган икән. Моны күргәч, патшаның аты туктады һәм кузгалмады. Патшаның моңа бик нык ачуы килде:

– Алыгыз аны! – дип кычкырды.

Патшаның хезмәтчеләре кызга ташландылар. Кыз каты яраланды. Егет кызны таныды: ул тереклек чишмәсенең хуҗасы иде. Ул патшаны сынарга гына теләгән иде.

Ярый, шуннан җиттеләр болар бик караңгы җиргә. Егет, кулына асылташ алып, алга китте. Ә патша куркып, арттарак калды, чөнки куркыныч, бик караңгы иде. Хезмәтчеләр егет артыннан атладылар.

Асылташны җиргә куйгач, караңгылык юкка чыга. Алар алдында тереклек чишмәсе пәйда була. Егет һәм хезмәтчеләр чишмәдә юыналар, суын эчәләр. Чират патшага җитә. Ләкин ул чишмә янына килү белән су акмый башлый. Асылташ та патшага юл яктыртмый. Шулай итеп, патша үзенең комсызлыгы, явызлыгы аркасында, мәңгелек караңгылыкта торып кала. Ә башкалар яңадан илгә кайталар. Егетне патша итеп куялар.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Әхмәтсафа Закир улы Закировтан*
*(1903 елгы, бирелдә беренче булып колхоз оештыручы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 239. Ал чәчкә

Бер байның өч кызы була. Бу бай сатуга чыгып китә. Сатуга чыгып китәр алдыннан, байның кызы өч кызы аңа әйберләр сатып алырга кушалар. Беренче кызы калпак алырга куша, икенчесе – балдак, өченчесе – ал чәчкә.

Бай чыгып китә. Ике кызына калпак, балдак алып, әйбәт сату ясап, кайтырга чыга. Өченче кызына ал чәчкә таба алмый. Бай караңгы бер урманга җитә. Бу урманда аңа юлбасарлар очрый. Байны талыйлар һәм китеп югалалар.

Бай бер тау янына килеп чыга. Тау итәгендә ул янып торган ал чәчкә күрә. Өченче кызы кушкан ал чәчкә була бу. Бай чәчкәне өзеп ала, шулвакыт давыл чыга, һәм бай кара өермә арасында торып кала. Өермә басылгач, бай үзенең каршында дию пәриен күрә. Ул төскә бик ямьсез була. Дию пәрие аңа:

– Син минем бердәнбер куанычымны югалттың. Мин бары тик шушы чәчкәгә карап, юанып яшим, – ди. Дию пәриенең ачуы килә, ул байны өзгәләп ташларга әзер була.

Бай диюгә каршы:

– Минем иң кече кызым, мин сатуга чыгып киткәндә: «Миңа бүләккә ал чәчкә алып кайт», – диде. Менә мин ал чәчәкне күрдем һәм аны өзеп алдым, – ди.

Дию пәрие бераз тынычлана һәм байга әйтә:

– Бар кайт, кече кызыңа ал чәчәкне бир, тик ул минем яныма килергә тиеш. Әгәр дә кече кызың килергә теләмәсә, беренче яки икенче кызың килсен, – ди.

Бай кайтып китә. Кызлары аталарын күреп бик шатланалар һәм үзләренең бүләкләрен алалар. Беренче кызы – балдак, икенче кызы – калпак, өченчесе – ал чәчкә. Бай кызларына әйтә шунда дию пәриенең әмерен. Беренче һәм икенче кызы дию пәрие янына китәргә теләмиләр. Кече кызы шунда ук риза була. Туганнары белән хушлашып, кыз дию пәрие янына китә.

Дию пәрие, кызның күзенә күренмичә, читтән генә аңа карап йөри. Кызны иң затлы әйберләрдән киендерә. Кыз дию пәрие янында бик озак тора. Тора-бара туган якларын, әтисен, апаларын сагына һәм дию пәриеннән кайтып килергә рөхсәт сорый. Дию пәрие аны җибәрә, күп итеп бүләкләр бирә. Кызга ул бер балдак бирә, шушы балдакны салса, шунда ук дию пәрие янында була. Дию пәрие кызга: «Өч көннән кайтырсың», – дип әйтә.

Туганнары бик сөенешәләр, бигрәк тә кызның атасы сөенә. Кызның апалары сеңелләреннән бик көнләшәләр, чөнки ул дөньяда булмаган, күзгә күренмәгән киемнәр кигән була, алып та кайткан була.

Өч көн сизелми дә үтеп китә. Кыз дию пәрие янына китәргә җыена башлый. Апаларының аны җибәрәселәре килми, һәм алар сәгатьне өч сәгатькә артка җибәреп куялар. Кыз, берни белмичә, тыныч кына йөри бирә.

Дию пәрие кызны көтә, ә кыз һаман юк. Өч көн узып китә, өч сәгать көтәсе кала дию пәриенә. Өч сәгать узып китә, дию

пәрие кызның алдаганын белә һәм үлә, чөнки, кыз кайтмаса, ул үләргә тиеш була.

Кыз, апаларының алдаганын сизеп, тиз генә кулындагы балдагын сала. Балдагын салуы була, дию пәрие патшалыгына килеп чыга. Кыз дию пәриен эзләргә керешә. Озак эзли ул аны һәм, ниһаять, бер куак төбендә табып ала. Дию пәрие үлгән була.

Кыз дию пәриенең башыннан сыйпый һәм елап җибәрә. Аның күз яшьләре йөзенә таму белән, дию пәрие чибәр егеткә әверелә. Кыз куркып сикереп тора һәм куаклар арасына кереп китә. Егет кыз артыннан иярә. Алар бер-берсен шушы илдә табышалар. Бу чибәр егетне сихерче сихерләп, дию пәриенә әйләндергән булган икән. Әгәр дә аны берәр кыз яратса, ул үзенең хәленә кайта торган булган. Егет белән кыз үзләренең бәхетен менә шулай табалар.

*1977 елда Борай районы Тангатар авылында*
*Маһира Исламовадан БДУ студентлары язып алган*

## 240. Кыз һәм патша

Яшәгән, ди, патша. Бу патша олы гына яшьтә булуга карамастан, һаман да өйләнмәгән, ди. Моның бик яхшы денщигы була. Патша, денщиктан уңдым, дип, сөенеп бетә алмаган. Патша торуга һәр нәрсә үз урынында, киемнәр чистартылган, итекләр ялтырап тора. Ә, икенчедән, егет бик яхшы аучы булган. Һәр баруында иңсәсен тутырып кош-кортлар, җәнлекләр алып кайта торган булган. Ул – Әхмәт атлы булган.

Бердән бер көнне Әхмәт, эшен бетергәч, патшадан рөхсәт сорап, урманга охотага чыгып китә. Көнозын йөри, ләкин берни дә ата алмый.

– Ни булды бүген миңа? Нинди хәерсез көн туры килде? Хәзер патша алдына ничек кайтам инде, – дип, егет бик нык күңелсезләнеп кайтырга чыга. Чөнки аның бервакытта да буш кул белән кайтканы булмый. Урман эче буйлап бик озак барганнан соң, кайтыр юлга чыгу өчен борыла һәм борылса, каршындагы агач башына күзе төшә. Агач башында ниндидер бер зат утыра икән.

– Син кем буласың? Ни эшләп агач башында утырасың, төш хәзер, исән каласың килсә!

– Егет кеше, атма мине, минем сиңа зур ярдәмем тияр, – дип, теге зат иясе телгә килә.

Агач башыннан төшсә, егетнең каршында тиңдәш булмаган гүзәл, сылу бер кыз басып тора. Егет, үзенең барлык борчылуларын онытып, кызга омтыла һәм аны үз өенә алып кайта.

Иртә белән патша йокыдан уянса, берни дә хәзер түгел. Моның ачуы килә. «Ни эшләп болай булган, кая китеп югалды икән, кайтканы да күренмәде», – дип уйлый патша. Патша үзенең хезмәтче кызын чакырып сораша, ләкин ул да берни дә белми. Кызны егетнең яшәгән бүлмәсенә җибәрә. Кыз барса, ни күрсен: егет бик сылу кыз белән йоклап ята. Кыз моны патшага сөйли.

– Әйдә, булмаса, без аларны парлап чәйгә чакырыйк, ниндирәк кыз икән ул, – дип, патшаның да бу кызны күрәсе килә башлый.

Патшаның хатыны юк бит инде. Патша чәйгә чакыргач, Әхмәт шатланып китә, ничек итеп хезмәтчесенең күңелен күрә, дип уйлап та бетерми.

Хатыны:

– Ашыкма, безнең алда зур сынаулар тора әле, патша хәйлә белән чакыра, – ди.

Болар баралар. Патшаның бу кызга шунда ук күзе төшә һәм бернигә карамый үзенә алырга була. Аның таныш бер карчыгы була, бу карчык бик усал һәм шул ук вакытта бик хәйләкәр дә була. Патша моңа барын да сөйләп бирә. Уйлашалар.

– Без аны, беләсезме, кая җибәрик? Кораб белән алты еллык юлга чыгарыйк. Диңгез артындагы утрауда алтын кыр үрдәге бар, шуны алып кайтып бирсен. Өч ел барыр, өч ел кайтыр. Юл кирәк-яракларын барын да әзерлә.

Патша шулай эшли дә. Әхмәтне чакырта һәм барын да сөйләп бирә. Егет бик күңелсезләнеп өйгә кайта, хатынына барын да сөйли. Хатыны аңа кулындагы алтын йөзеген салып бирә.

– Менә сиңа алтын йөзек, югалтма. Өч көн баргач, ярты төн уртасында, корабның бортындагы тәрәзәсенә чирт һәм ике

егет килеп чыгар да: «Ни боерасыз?» – дип сорарлар. Син шул вакытта әйтерсең, – ди хатыны.

Егет шулай эшли дә һәм, алтын үрдәкне кулга төшергәч, төн уртасында тагын чиртә, һәм болар белән алты елга киткән кешеләр алты көндә урап кайталар. Патшага барып әйтәләр. Егет тә алтын кыр үрдәген патшага илтеп тапшыра. Патша яңадан да бу карчыкны чакыра.

– Нихәл итәбез? Алты елга җибәргән кораб алты көндә урап кайтты бит.

– Кайда да булса, җир йөзендә кешегә күренми торган бүрек бар. Ул безгә шуны алып кайтып бирсен. Син аңа азык та, кеше дә бирмә, бары тик юлына җитәрлек акча гына бир, – ди карчык.

Патша бу юлы да карчык әйткәнчә эшли һәм Әхмәтне чакырта. «Алты елсыз таба алмассың», – дип, егетне зур кайгыга сала. Тагы да кайтып хатынына сөйли. Хатыны бу юлы киемнәр һәм тастымал бирә.

– Син, кайда гына юынсаң да, шушы тастымалга сөртен, үзең белән бергә йөрт, – ди хатыны. Һәм тагы да бер туп бирә. – Менә хәзер чыккач та, шушы тупны җиргә бәр, ул кайсы якка тәгәри, син дә шул якка бар. Ул син туктасаң – туктар, син барсаң – барыр.

Егет бара-бара, бик озын юллар үтә, кара урманнар, елгалар кичә, кеше үтә алмаслык чытырманлыклар аша туп артыннан үтеп чыга. Кара урман аша чыккан вакытта, егетнең күзенә зур бер йорт чагыла, караса, туп та шул якка тәгәри икән. Туп күтәрмәгә барып менә, һәм егет тә туп артыннан барып менә. Боларга каршы йөгерешеп өч кыз чыга. Берсе кулына җиз комган тоткан, икенчесе сөлге тоткан, өченчесенең кулында – сабын. Егетне бик яхшылап юындыралар, сөртенергә вакыт җиткәч, егет барып үз сөлгесен алып сөртенә. Кызлар өчесе дә сөлгегә карап торалар да йөгерешеп кереп китәләр. Боларның әниләре дә бар икән. Кызлар әниләренә сөйләп бирәләр:

– Әни, безгә бер егет килгән иде, без аны юындырдык, ул үз сөлгесенә сөртенде, ә сөлгесе безнең түтинеке, – диләр.

Егет монда куна кала һәм барын-барын да сөйләп бирә. Үзенең бүрек эзләп йөрүен дә, ничек табарга икәнен дә сораша.

Әби:

– Ярый, балам, ятып йоклыйк, иртә булгач хәл итәрбез. Төнге эштән иртәнгесе хәерлерәк, – дип йокларга яткыра.

Әби иртә белән тастымалны селкеп сызгырып җибәрә. Моның янына барлык җәнлекләр җыела. Әби барыннан да сорый, ләкин бүрекне берсе дә белми.

– Ә барыгыз да килеп беттегезме соң? – дип, кабаттан да сорый әби. Бер саз бакасы алга чыга да, үзенең иптәшен чирләп торуын һәм килә алмавын әйтә. Әби баканы алып килергә куша. Бака килгәч, аңардан сораша. Бака бу бүрекнең диңгез теге ягындагы бер өйдә барлыгын әйтә.

– Алай булгач, син егетне итеп куй инде.

Иртә белән егет уянгач, әби ничек барырга икәнен сөйли. Үзе белән ике литр сөт алырга куша. Егет яр кырыена бара, һәм аны анда бака көтеп тора. Егет ярты литр сөтне бакага эчерә дә үзе бака өстенә утыра. Бака моны диңгезнең теге ягына чыгарып куя. Егет бераз барганнан соң, каршысында зур бер йорт күрә һәм өйгә керә. Керсә, өйдә беркем дә юк. Егет шкаф артына кереп поса һәм көтә башлый, кем кайтыр икән, дип. Бервакыт ике егет кайтып керәләр.

– Безгә ашарга бир. Без бик нык ачыктык. Егет качып кына карап тора. Каршыларында өстәлдә ашамлыклар хәзер була. Ашап бетерәләр, чыгып китәләр болар. Алар чыгып киткәч, егет качып торган җиреннән чыга да ашарга сорый һәм, тамагы туйгач, бик зурлап рәхмәт әйтә.

Бүрек телгә килә.

– Син яхшы кеше булдың әле, рәхмәт әйтәсең. Минем хуҗаларым беркайчан да әйткәннәре юк иде, – ди.

Егет аңа алып китәргә килгәнлеген әйтә. Бүрек берсүзсез риза була. Егет бүрекне үзе белән бергә ала да чыгып китә. Һәм икенче ярты литр сөтне бакага эчерәләр дә диңгезне йөзеп чыгалар. Бакага рәхмәт әйтеп, егет үз юлына китә. Бик озын юл үткәч, егет бик матур бер аланга туктый. Бер кораб үтеп бара икән. Болар өстәл һәм азык-төлекләр күреп аптырап калалар. Корабларын туктаталар, егет янына киләләр. Кораб капитаны

егеттән сораша: «Ризыкларны каян алдың ялан уртасында?» – дип сорый. Егет үзенең бүреге барлыгын әйтә. Кораб капитаны үзенең кесәсеннән шырпы чыгарып күрсәтә.

– Әйдә алышыйк. Кирәк вакытта теләгән кадәр гаскәр җыя аласың.

Егет риза була, болар алышалар да үз юлларына китәләр. Егетнең корсагы ачкач, бүрек исенә төшә.

– Мин монда, синең белән барам, – ди бүрек.

Шәһәргә кайтып җитәрәк, егет чатыр корып җибәрә. Кесәсеннән шырпы кабын бәрә һәм гаскәрләр барлыкка килә.

Егет озак йөргәч, патша кызны үзенә хатынлыкка алырга әзерләнә. Төрле юллар белән кулга төшерергә тартыша, ләкин кыз бик хәйләкәр була. Кыз егетнең кайтканын белә һәм тәрәзәсеннән кош булып очып керә.

Болар хәзер дә бик яхшы яшиләр ди. Шәһәр читендә зур сарайларда, күп гаскәрләр белән егет патшалык итә, хатыны ярдәм ит, ди. Әле дә булса бик яхшы яшәп яталар, ди.

*1964 елда Балтач районы Иске Яхшый авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

## 241. Яман хатын

Бер патшаның хатыны үлә. Үлә дә өйләнә бер кызга. Өйләнгәч, боларның малайлары туа. Аны хәдимчегә бирәләр, карап үстерергә. Ә малай үскәч, укырга да бирәләр. Шул вакытта патшаның хатыны, комсызланып, малайны үтертергә була: «Зур малай, – ди, – үскәч, миңа дигән бөтен мал-мөлкәтне, йорт-җирне, алтын байлыкларын үзенә алыр, лутчы котылырга кирәк», – ди.

Малайның укытучысы ворожать итеп карый да, эшнең нәрсәдә икәнен белә. Шуннан ул малайга: «Өеңә кайткач, беркемгә бер сүз әйтмә. Әгәр әйтәсең икән, дөнҗадан җугаласың», – ди.

Шуннан, җарар. Малай җыена да кайта. Кайтса, ичмасам, беркемгә бер сүз дәшми. Бәй, моны, сүз дәшмәгәне өчен, төрмәгә җабалар. Ә патшаның хатынына шул гына кирәк. Ул патшага: «Башыңа җитәчәк ул, үтерт җәтрәк шуңыйнчы», – ди. Патша үзенең җакыннарын, советникларын җыя. Шуннан инде

малайга хөкем чыгаралар. Патша баш чабучыга улының башын чабарга куша. Баш чабучы әйтә: «Соңыннан үкенерсең, патша, бер сәгатькә булса да отложить итик», – ди. Шуннан: «Җегетнең укытучысын китертергә иде», – ди ул. Ә малай һаман дәшми. Укытучысын чакырталар моның. «Нәрсә булды?» – дип сорыйлар аңардан. Укытучы бөтенесен дә сөйләп бирә: «Менә мин ворожить итеп карадым. Шулай-шулай. И әйттем, что син, бер авыз сүз әйтмә, дип». Шуннан укытучы патшаның хатыны турында бөтенесен дә әйтә: «Синең хатының, әгәр ул кайтса, миңә жить итәргә көн калмый, дип угрожать итә», – ди. Аннан инде малай да ниләр күргәнен сөйли.

Шуннан инде патша приказ бирә: урманнан мышый тотып алып килегез! Аның приказы буенча дикий мышый тотып алып китерәләр дә, патша хатынын мышыйның аягына бәйләп җибәрәләр.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Сөләйман Агиевтан (1887 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 242. Ятим бала һәм сары ат

Борын-борын заманда бер бабай булган. Ул бабайның карт хатыны үлгән дә яшь хатын алган. Карт хатыныннан бер баласы калган. Инәсеннән малаена васыять итеп бер сары ат калган.

Яшь хатын баштан ук үги малайны да, атны да яратмаган. Алардан котылырга теләгән. Моның өчен чирләгән булып кыланган.

– Шул сары атны суеп ашатсаң, мин терелер идем, – дигән ул иренә, кеше әйтүе буенча.

Шуннан ул үз баласын да, үги баласын да сабакка җибәргән. Үз баласына – Коръән китабы, ә үги баласына «Иман шарты» биргән. Теге үги бала «Иман шарты»н да, Коръәнен дә белгән, үз баласы берсен дә белмәгән. Моның үз малае кайтып җылаган, гарьләнгән булган. Шуннан соң бу хатын абзарга барганчы энә казаган юлга. Үз малаена әйткән:

– Син ул малайны шушы юлдан алып бар, аның аягына энә кадалыр, – дигән.

Үги малай аты янына чыгып:

– И, аткаем, нигә ашамыйсың? – дип сораган.

Сары ат әйткән:

– Мин ашар идем лә ул. Синең анаң юлыңа энә казата, – дигән. – Син абзарга юлдан барма, гел көрттән бар, – дигән.

Малай исән-сау абзардан кергән, энә кадалмаган. Теге хатын тагын чирләгән.

– Шушы ат итен ашамыйча, мин терелмим, – ди икән.

Малайлар икесе дә сабакка барырга әзерләнгәннәр. Үги малай аты янына чыккан да:

– И, аткаем, тагын ни булды, нигә ашамыйсың? – дигән.

Ат:

– Ашар идем дә, мине бүген суярга әзерләнәләр, – дигән. – Син кайтканда, минем аягым бәйләүле булыр. Син миңа атланып ындыр буеннан гына бер урап кайтыйм әле, дип сора.

Бу малай сабактан кайткач әйткән:

– Инәкәемнән калган бер сары атым иде, сез суйганчы, ындыр буеннан бер урап килим әле, – дигән.

Атына атланган да суккан. Ат койма аша чыгып качкан. Хатын итне ашый алмыйча калган. Ат өстендә барганда, малай сары алтын канат күргән. Малай аттан сораган:

– Бу канатны алыйммы?

– Алсаң ал, миңа авырлык булыр, – дигән.

Шуннан ниндидер бер җиргә барып, патшаның капка төбенә атын бәйләп куйган малай. Патша бу малайны үз янына чакыртып керткән. Малайдан атын үзенә бирүне сораган. Малай исә:

– Үлсәм үләм, тик атны бирмим, – дигән. Ә патша моны төрлечә алдарга тырышкан. Тик малай барыбер атын бирмәгән.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*укытучы-пенсионер Зыяда Латыйповадан*
*БДУ студентлары язып алган*

### 243. Көчек һәм хатын

Борын-борын заманда бер картның ике хатыны булган. Бердән бер көнне бу картка әрмислеккә хәбәр килгән. Шуннан соң беренче хатынын чакыртып керткән дә әйткән, ди:

– Мин киткәч, нәрсә эшләрсең?

Хатын әйткән:

– Килгән-кергәнне каршы алырмын, киткәнне озатырмын.

Икенче хатынын чакырган:

– Мин киткәч, нәрсә эшләрсең?

Ул әйткән:

– Син киткәч, мин ука чәчле, энҗе тешле бала табармын.

Хатыннар әйткән сүзләрендә торалар. Карт хатын яшь хатыннан көнләшеп, алтын чәчле, энҗе тешле баланы суга сала. Бу бала агып китә, аның урынын эт баласы ала. И җылый, ди, и җылый, ди, бу бала. Карт хатын әйтә, ди:

– Ул эт баласы тапкан, шуңа җылый.

Бу иркәй шул көчек белән яшь хатынын караңгы бурага илтеп ташлаган. Бу бураның ишеге дә, тәрәзәсе дә тишелмәгән була. Көчек юлда бер кеше күргән дә:

– Безгә тәрәзә тишеп бир әле, – дигән.

Бу иркәй ишек тә, тәрәзә дә тишеп биргән. Хатынга ул әйткән:

– Бер җирдә бер бия бар, ул тычкан саен колынлый.

Көчек бу бияне алып кайткан. Болар байый башлаганнар. Бервакыт бер юлаучы, боларга кереп, чәй эчкән. Ул әйткән:

– Идел буенда ак биләүгә биләнгән, ука чәчле, энҗе тешле бала ята, сез аны алып кайтыгыз.

Эт аны күтәреп алып кайткан. Хатын тагын да ныграк байый башлаган. Тагын бер юлаучы кергән чәй эчәргә, һәм ул әйткән:

– Менә фәлән-фәлән җирдә бер алмагач бар, сез шуны алып кайтыгыз. Ул агачның яфраклары биегәндә, алмалары кул чаба; алмалары биегәндә, яфраклары кул чаба.

Хатын шулай итеп көннән-көн баеган, ә теге ир ярлылана барган. Бу ир яшь хатын янына килергә йөри, ди. Көчек әйтә, ди:

– Әти килә, эти килә! Хатын әйткән:

– Икесен дә ал. Алар икесе дә мине баетты. Әгәр алмасаң, кирәкмисең, – дигән.

Шулай булса да, ир хатын сүзен тыңламаган. Шуннан соң аны хатын куып чыгарган да, үзе рәхәтләнеп яши, ди.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*укытучы-пенсионер Зыяда Латыйповадан*
*БДУ студентлары язып алган*

**244. Ятимә кыз**

Борын-борын заманда бер бабай булган, ди. Аның бер ятим кызы да бар иде, ди. Ул баласын тары төяргә җибәргән, ди. Тарысын бик әйбәт итеп төйгән, ди. Ә үги инәсе төймәгән ярманы кушып ботка пешергән, ди.

– Эш рәте белмәгәч, моны ничек итеп тормышка бирәбез, – ди икән үги инәсе. Шуннан соң кызның егете әйткән, ди:

– Үзебезгә баргач, боткасы әйбәт булыр. Мин аны үземә кәләшкә алам.

Бу кызны тормышка биргәннәр. Башта кыз белән кияү үги инәләрен кунакка чакырганнар. Ятим кыз бик яхшы хөрмәт итеп озаткан. Шуннан соң үги инәләренә кунакка барырга булганнар. Кияү бармаган, кыз баласы белән киткән. Инә кеше һаман бу кыздан көнләшә, ди.

Ул кызны мунчага җибәргән, ә үзе, кыз барганчы, мунчага кереп качкан. Кыз чишенгәч кенә, бик каты пар салып, ишекне бикләп кайтып киткән. Теге кыз селәүчен булып, һавага очкан, ди.

Кияү хатынын алырга килгән. Үги инә кеше ятим кызның киемнәрен үз кызына киендереп биреп җибәрә. Тик үги кызның баласы и җылый, и җылый, ди. Имезеп тә карый, әмма бала туймый, ди.

Кияү кешенең сеңлесе дә булган була. Бу кыз җиңгәсеннән шикләнә торган була. Баланы юату өчен, ул аны көн саен яланга алып чыга торган була. Монда ул җырлый, ди:

*Селәүчән микән, бу микән?*
*Аның әнкәсе ул микән?*
*Таш имчәкле, ком сөтле,*
*Имезсә дә туймый икән.*

Анасы шушы җырны ишетеп, төшеп имезә икән.

Кияүнең сеңлесе болар турында абыйсына сөйләп биргән. Иртәгәсен кияү, кыз һәм бала яланга өчәү барганнар. Абзыйсы үз хатынын алып кайткан, ә тегенең кызын өеннән куып чыгарган. Кияү белән ятим килен әле булса дөбердәтеп дөнья көтеп яталар, ди.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында укытучы-пенсионер Зыяда Латыйповадан БДУ студентлары язып алган*

## 245. Усал хатын

Борын-борын заманда булган, ди, бер усал хатын. Аның ире дә, балалары да булмаган, ди. Ул хатын бик усал, ялкау булган, ди. Шулай да, тормыш авырая башлагач, иргә чыккан бу. Ире кайтканчы, урамда йөргән, төнлә генә кайткан бу, ә ире кайтуга ашарга да, эчәргә дә юк ди. Берзаман төнлә кайткан да зарлана башлаган.

– Бу эш кайчан бетәр икән, һич кенә дә бетереп булмый, – ди икән.

Моны ире ничек итеп үтерү турында уйлый башлаган. Бер көнне ул хатынын урманга алып баргач, асарга уйлаган, ди, ләкин җәлләгән дә кире кайтып киткән бу. Кайтканда, бер коега очраганнар. Ул коеда Дию пәрие яшәгән, ди. Бу пәрине кешеләр чыгара алмыйлар икән. Теге хатын, чәчләрен туздырып, коега төшеп киткән. Дию пәрие, моны күреп, коты алынып чыгып качкан.

Хатынны, җепкә бәйләп, коедан алырга уйлагач, моның ире җепне кисеп төшергән. Шуннан бу хатынның эше дә беткән. Ә ире әле булса да рәхәт гомер итә, ди.

*1970 елда Чакмагыш районы Таш Калмаш авылында*
*Разия Турьяновадан (1899 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 246. Алтын балалар

Яшәгән, ди, ике кыз, алар бик дус булганнар, ди. Менә бер заман алар сөйләшеп утыралар, ди.

Берсе әйтә, ди:

– Мин патша малаена барсам, ел саен игезәк армеецлар табар идем.

Икенчесе:

– Ә мин патша малаена барсам, ел саен сигез алтын куллы, алтын колаклы балалар табар идем, – ди икән.

Боларның сөйләшкәнен патша малае тыңлап торган, ди. Ул атасына кайткан да атасына бөтенесен сөйләп биргән, ди. Әтисеннән:

– Кайсысына өйләнәем? – дип сораган.

Әтисе:

– Улым, армеецлар үзебездә дә күп, алтын куллы, алтын колаклы бала таба торганына өйлән, – дигән.

Патша малае алтын куллы, алтын колаклы бала таба торганына өйләнгән. Алар бик матур тормыш иткәннәр.

Менә кызның бала табар вакыты җиткән, патша малае кендек әбисе алырга киткән. Бу әби дә, аның кызы да боларның тормышларына бик көнләшеп яшәгәннәр. Әби, килгәндә, үзе белән ике көчек алып килгән. Кызның яңа туган алтын куллы, алтын колаклы балалары урынына бу көчекләрне салып куя һәм патша малаен балаларын күрергә чакыра. Патша малае, көчекләрне карагач, бик кайгыра, ләкин бер сүз дә әйтми. Әби алтын куллы, алтын колаклы балаларны үзе белән алып китә.

Менә кызның янә бала табар вакыты җитә. Патша малае тагын бара әби янына. Әби бу юлы да ике көчек алып килә, шуларны «балалар» дип, патшага күрсәтә, ә алтын малайларны үзе белән алып китә. Патша малае тагын бер сүз дә әйтми. Тик патша гына:

– Өченчесендә дә көчекләр тапса, болай калдырып булмас, – ди.

Менә кызның өченче тапкыр бала табар вакыты җитә. Патша малае тагын килә әбигә, әби тагын килә көчекләр алып, кызның балаларын тагын алып китә бу.

Инде өченчесендә дә көчекләр булгач, патша түзми, бөтен шәһәр алдында кызны аттырырга була. Җыела мәйданга бөтен шәһәр халкы. Халык җылый, кызны кызганып. Әби алып киткән балалар, аңардан качып китеп, әниләре каршына басалар, бөтен шәһәр халкы шакката. Ә теге көчекләр әбине барып талый башлыйлар. Патша да, патша малае да эшнең нәрсәдә икәненә төшенәләр. Патша малае хатынын, улларын ала да өенә юнәлә. Ә көчекләр шәһәр халкы каршында әбине талап үтерәләр.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Йомран авылында*
*Фәтхия Сәетгәрәй кызы Гыйләҗевадан (1901 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 247. Кара сыер һәм үги кыз

Борын-борын заманда бер бабай яшәгән. Аның хатыны һәм бер кызы, кара сыеры булган, ди. Көтмәгәндә, хатыны үлеп китеп, кызы ятим калган. Карт яшь хатынга өйләнгән. Бу хатын үзе белән элекке иреннән калган кызын алып килгән. Менә бер-заман яшь хатын кунакка барырга җыенган. Китәр алдыннан, бер пот җитен калдырган да, үзе әйләнеп кайтканчы, киндер эрләп куярга кушкан.

Кыз, елый-елый, киндер эрләргә утыра. Йокламый-нитми ,ике көн, ике төн эрли. Ләкин җитен бер дә кимеми. Үги ана кайтырга бер генә көн кала. Үзенең кайгысын сөйли-сөйли, әнисеннән калган кара сыерын ашатып йөргәндә, сыер телгә килә һәм:

– Кайгырма, кызыкаем, үзем булышырмын. Мин җитенне чәйни барырмын, киндер итеп чыгара барырмын, – ди.

Кыз бик шатлана. Үги ана калдырган җитен шулай итеп эрләнеп бетә, кыз аны матурлап юып та куя.

Яшь хатын кунактан кайта, үги кызының эшен күреп, бик аптырый, ышанмый кызга. Кара сыерның кызга булышканын күрше хатын күргән була, һәм ул бу турыда үги анага әйтә. Үги ана бик ачулана һәм үч алырга була. Бер көнне ул чирләгәнгә салышып ята.

– Карт, чирләдем, күрәзәгә бар, – дип, картын чыгарып җибәрә.

Карт китә. Хатыны урнысыннан торып, түшәк япмасын ябына да, карттан алда юлга чыгып утыра һәм бабайдан сорый:

– Бабай, күрәзәгә барасыңмыни, мин үзем – күрәзә, ни өчен килгәнеңне дә беләм, – ди. – Син кайт та, кара сыерыңны суеп, итен карчыгыңа ашат, шулай итмичә ул терелмәс, – ди.

Карт бик кайгырып, башын иеп кайтып киткән. Үги ана, бабайдан алда кайтып, түшәгенә яткан. Карты кайткан.

– Күрдеңме күрәзәчене? – дип сораган.

– Күрдем, терелер дип әйтте, – дигән бабай.

– Юк, алай түгел, кара сыер итен ашарга кушты! – дип кычкырган усал карчык.

Бабай яраткан хатыныннан калган кара сыерны бик жәлләсә дә, яшь хатын кысымы астында суярга мәҗбүр булган. Кыз бик

елаган, кайгырган, кара сыер яныннан китмәгән, аңа болай дип җырлаган:

*Чыр-чыр казан кайныйдыр,*
*Әнкәй пычак кайрыйдыр.*
*Кара сыер-анакай,*
*Сине суярга уйлыйдыр.*

Кара сыер кызны юаткан.

– Елама, елама, балакай, итемне ашама, сөягемне кимермә, эт авызында күрсәң дә, кош авызында күрсәң дә, сөягемне тартып ал, – дигән.

Кыз кара сыерның сөякләрен җыеп, бер урынга күмә, аның сөякләре бердәнбер көнне алмагач булып үсеп чыга.

Менә берзаман үги кызга яучы килә. Ул инде бик уңган һәм матур булып үсеп җиткән була. Үги ана моңардан бик көнләшә. Менә кияүләр килә, үги кызны көймәле арбага утыртып алып та китәләр. Явыз карчык болар кузгалып китү белән артларыннан:

– Әй, туктагыз әле, кызымда йомышым бар! – дип кычкыра. Һәм шул рәвешле үги кызны чакырып ала. Аны кәкүккә әверелдереп очыра, ә аның урынына үз кызын утыртып җибәрә. Чөнки аның кызын берәү дә сорамаган була.

Үги кыз да югалып калмый, киявенең артыннан оча да, куып җитеп, атының дугасына кунып кычкыра. Кияү кеше бу гаҗәп хәлгә бик аптырый, кошны куып та карыйлар, ләкин ул китми. Шуннан кияү кеше бу кошның гади кош түгел, ә үз хатыны икәненә төшенә, чөнки аңа үги кыз үги анасының явызлыклары, сихер белән эш итүе турында сөйләгән була. Киявенең кулы тию белән, кәккүк яңадан кешегә әверелә. Алар икәүләп үги ананың кызын тере килеш җиргә күмәләр дә кайтып китәләр. Кызның кабере өстенә ак чәчәк үсеп чыга.

Берникадәр вакыт вакыт үткәч, үги кызның баласы туа. Алар әтиләрен кунакка чакыралар. Үги ана, «үз кызымның баласына» дип, күп итеп бүләкләр алып килә. Барасы юл ерак булганга, карт белән карчык бер урында туктап, атны ашатып-эчертеп, үзләре дә ял итеп алмакчы булалар. Атларын ашарга җибәрәләр. Шулчак карт юл буенда гына үсеп утырган ак чәчкә күреп ала.

Бу чәчкә аңа бик ошый, һәм ул аны өзәргә тели. Карт кагылу белән чәчәк телгә килә:

*Тартма, тартма, атакай,*
*Кендекләрем авырта, –*

ди.

Карт белән карчык бу җирне чокый башлыйлар һәм карчыкның кызын табалар. Кызны ашаталар, эчерәләр. Ул аларга ничек итеп шушы хәлгә төшүен сөйләп бирә. Кызны үзләре белән кунакка алып китәләр.

Үги ана, өйгә кермәс борын, үги кызын чакырып ала да, аны тагын кәккүк итеп очыра. Монда бераз кунак булалар да, үги ана үз кызын калдырып, тынычланып кына кайтып китәләр. Үги ананың кызы бер эш рәте дә белми, тукмач та кисми, идән дә юмый, баланы да юындырмый. Өйдә ирнең сеңлесе була, ул бөтен эшне башкара. Ул зирәк кенә кыз була, җиңгәсенең кәккүк булып йөрүен белеп кала да, баласын күтәреп, үги кызны эзләргә чыгып китә.

Менә һавадан тезелешеп кыр казлары очып бара. Сеңел кеше алардан:

*Очыгыз, казлар, очыгыз,*
*Күрмәдегезме, кәккүкне? –*

дип сорый.

Казлар аңа:

*Күрдек, күрдек кәккүкне,*
*Аргы толпа артында*
*Камка турка кисәдер, –*

дип җавап бирәләр.

– Әйтегез кәккүккә, баласы бик елый, килсен әле, – ди кыз.

Кәккүк очып килә дә баласын имезеп китә. Ике көн шулай дәвам итә. Үзенең хатынын бик сагынган ир дә уйлана, әниләре булуга карамастан, балаларының елавына да аптырый һәм күзәтә башлый.

Күзәтә торгач, хәлне төшенә. Кайта да сумала кайната. Икенче көнне кәккүк утырачак урынга сумала сылап куя. Кәккүк килә, тунын сала, бала имезә. Имезеп беткәч, караса: туны ябышып калган. Ире шулчак аның янына килә һәм өйгә алып кайта.

Икенче көнне базарга барырга җыена. Хатыннарыннан аларга нәрсә кирәклеген сорый. Карт хатыны – күлмәк, яшь хатыны ат сорый. Сораган әйберләрен алып кайтып бирә ир кеше. Яшь хатын моңа бик шатлана:

– Әткәйләргә кунакка барам, – ди.

Ләкин ир белән хатын үзләренә шулкадәр күңелсезлекләр китергән үги ана кызын шул көе генә кайтарып җибәрмиләр. Аны ат койрыгына тагалар һәм, шулай итеп, мәсхәрә булып кыз кайтып китә, шуның белән әкият тә бетә.

*1970 елда Чакмагыш районы Йомран авылында*
*Сәвия Хәмәтдиновадан (1903 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 248. Байдогыш әкияте

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер карт белән карчык. Боларның бер кызлары һәм бер кәҗәләре генә булган, ди. Бердән бер көнне карт белән карчык бик каты авырып китkәннәр һәм, күп тә тормый, дөнья куйганнар икән, ди. Ятим калган кыз, кәҗәсен ияртеп, ил буенча чыгып киткән. Юлда очраган кешеләр моннан:

– Нишләп йөрисең, кызым? – дип сорыйлар икән.

Боларга каршы кыз:

– Улсызга ул булам, кызсызга кыз булам, – дип җавап бирә икән.

Шулай йөри торгач, бер карт белән карчык бу кызны үзләренә кызлыкка алганнар, ди.

Болар, кызның әти-әнисе кебек, бик фәкыйрь яшәгәннәр, өстәвенә, карт бик комсыз кеше булган. Кыз, боларда бераз торгач, картның күңеленә шик төшә. «Бу кыз чыгып китсә, кәҗәне дә алып китә, мин моны суеп ашап калыйм», – дип уйлый.

Үзенең суеласын алдан сизеп, кәҗә көне-төне бакыра башлый. Ә карт:

– Бакырмасын шул – авызына таш кергән, суеп ашарга кирәк аны! – ди.

– Куй, карт, кызыбызның бердәнбер юанычы, бердәнбер куанычы, бакырсын, әйдә, – ди карчык.

Әлбәттә, әти-әнисенең төсен хәтерләтеп торган кәҗәне кызның да суйдырасы килми.

Ләкин карт үзенекен итә, мескен кәҗәне суя. Кәҗәнең итен ашаганнан соң, сөякләрен кыз, елый-елый, яр куенына илтеп сала. Үзе күз яшьләре аша болай дип такмаклый икән:

*Бабай пычак кайрыйдыр,*
*Казанда ит кайныйдыр. –*
*И, Байдогыш, Байдогыш,*
*Сала санак җыйдыгыч,*
*Яр куенына куйдыгыч.*

Сөякләрне яр куенына ташлый да, кыз елый-елый борылып кайтып китә. Аның зарын Байдогыш ишетеп тора да, комсыз бабайга нәфрәте туа. Һәр көн саен Байдогыш, йорт кыегына кунып, мондый юлларны кабатлый башлый.

*Бабай пычак кайрыйдыр,*
*Казанда ит кайныйдыр...*

– И, явыз, бар әле, чыгып ку шуны, карчык, – ди карт.

– Кит әле, – ди карчык.

– Кызым, бар әле, чыгып ку шуны, – ди карт.

– Кит әле, – ди кыз.

Болар тыңламагач, карт үзе чыгып китә. Картның: «Һи, явыз!» – дип кычкыруы була, Байдогыш бабайның башына тегермән ташы төшерә. Бабай үлгәннән соң, әби белән кыз иркенләп яши башлыйлар. Әле булса да рәхәтләнеп дөнья көтәләр, ди.

*1970 елда Чакмагыш районы Йомран авылында*
*Бибинур Хәмидуллинадан (1907 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 249. Алтын балдак

Бер патша белән вәзир ауга чыгалар һәм, юлда барганда, алтын балдак табалар. Патша әйтә: «Кем үз гомерендә иң күпне күргән, бу балдак шуңа була», – ди. Башта вәзир сөйләргә була.

Бу кеше патша вәзире булганчы, авылда торган була. Аның дүрт аты була. Менә шулар арасыннан берсе иртән торуына көн дә манма су була. Ул ни уйларга да белми. Шулай, бер төнне сак-

лап торырга була. Төн уртасы җиткәч, хатыны моның ипләп кенә тора да атлар янына чыга һәм, иң яхшы атка атланып, урман ягына таба чаба. Икенче көнне дә шул ук кабатлана. Өченче төнне вәзир моның артыннан китә. Кара урман эченнән бик озак баргач, теге хатын бер өйгә кереп китә. Вәзир бу урынны билгеләп, кайтып ята. Таң алдыннан гына хатыны кайта. Икесе дә берни сиздермичә йөриләр. Базар көне якынлашкач, вәзир хатынына:

– Базарга куна барам, юл кирәкләрен әзерлә, – ди.

Бу базарга бармый, ә төнлә хатыны килгән йортка бара. Тәрәзәгә килеп:

– Юл күрсәтегез инде, адаштым бит, – ди.

Өйдән юл күрсәтергә бер кеше чыга. Вәзир моның башын кисеп, капчыкка сала. Шулай итеп, капчыкта җиде баш җыела. Болар сихерче кешеләр булалар.

Базар вакыты үткәчрәк, вәзир кайтып керә. Каршысына хатыны чыга:

– Миңа базардан ни алып кайттың? – ди.

– Сиңа карбызлар алып кайттым, кая әле салырга савытлар бир, – ди.

Һәм башларын савытка бушата. Хатын моны күреп:

– Минем җан кисәкләремне нишләттең?! – ди. Һәм кулындагы чыбыгы белән:

– Эт бул! – дип, иренә суга.

Шул минутта ук вәзир зур кара эткә әйләнә. Хатын бу этне куып чыгара. Ашарга бирми, һәм эт өйдән чыгып китәргә мәҗбүр була.

Бу вәзирнең бик бай энесе була. Ул караван белән шушы авыл кырыеннан үтеп йөри торган була. Һәм эт, энесе үтмәсме дип, бик озак көннәр шушы юл буенда саклап ята. Көннәрдән бер көнне караван бу авыл кырыенда туктап хәл җыя. Бу эткә сөякләр ташлыйлар. Ашап-эчеп ял иткәч, юлларын дәвам итәләр. Эт, сөякләр кимереп, юл буенда ятып кала һәм шулчак сөякләр арасыннан бер бәләкәй генә алтын балта таба. Бу аның энесенең сөяк ватып ашый торган балтасы була. Эт моны авызына каба да караван артыннан чаба. Караванны куып җитеп, энесенең

кырыеннан чаба. Аны күреп алалар да туктыйлар. Теге бай хәзер уйга кала:

– Бу гади генә эт түгелдер, я өйрәтелгән, я тылсым белән эткә әверелдерелгән кешедер, – ди. – Әгәр син эткә әйләндерелгән кеше икәнсең – бездән калма, әгәр өйрәтелгән гади эт икәнсең – безнең белән барма, кал, – ди.

Эт болардан калмыйча барган да барган. Бу этне тылсымчы бер әбигә күрсәткәннәр. Тылсымчы, дога укып, яңадан кешегә әверелдергән. Вәзир булачак егет барысын да энесенә сөйләп биргән. Моңа бер тылсымлы таяк биргәннәр.

– Ни рәвешкә кертәсең килә, шуны әйтеп, хатыныңа шушы таяк белән сук, – дигәннәр.

Бу кайтып киткән. Хатыны йорт алдында йөри икән. Моны күреп калган да:

– Әле син кайттыңмыни? – дип, сугарга кизәнгән, ләкин вәзир:

– Ат бул! – дип, алданрак сугарга өлгергән.

Шулай итеп, хатын бер күк толпарга әйләнгән.

– Мин атланып барган әлеге ат минем хатыным инде ул, – дип, вәзир сүзен тәмамлаган.

Патша уйлап торган да балдакны вәзиргә биргән.

*1970 елда Чакмагыш районы Йомран авылында*
*Фатыйх Әбелфазыл улы Шәмсетдиновтан (1893 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 250. Ана васыяте

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер кеше. Аның бер улы белән бер кызы булган. Бу кеше гел сату итеп көн күргән, ди. Сатуга ул үзенең кызы белән улын да алып йөргән, ди. Бу шулай йөртә торгач, улын да сатуга өйрәткән. Малае да бик яхшы сату итә башлаган.

Менә берзаман карт нык чирләп киткән. Ул үзенең янына балаларын, карчыгын чакырып китергән дә:

– Менә, карчык, миңа үләр вакыт җитте, улыбыз хәзер дөнья көтәрлек булды, сезнең барыгызны да улыбыз кадер-хөрмәт итсен, – дип үлә.

Шуннан болар үзләре генә көн күрә башлаганнар. Малай сату иткән, ә сеңлесе аңа булышкан. Сату эшендә йөргәндә, сеңлесе абыйсының өстен-башын караган. Атларын да таңнан торып эчергән, җиккән. Алар икесе дә әниләрен кадер-хөрмәт иткәннәр.

Менә берзаман боларның әниләре дә чирләгән. Ул үзенең янына балаларын чакырып китергән дә болай дигән:

– Балаларым, бергә яшәгән кебек тату яшәгез. Улым, сеңлеңне какма-сукма, рәнҗетми генә яшә, – дигән.

Шулай ук кызына да абыйсының һәрбер сүзен тыңларга, аңа ярдәм итәргә кушкан. Үзе озак та тормый үлеп киткән.

Болар бик яхшы көн күрәләр. Абыйсы үсеп егет була. Өйләнгәч тә, сеңлесен бик ярата. Сеңлесе дә абыйсын хөрмәт итә. Ләкин абыйсының хатыны боларның бер-берсен шулкадәр хөрмәт итүләрен яратмый. Ул аларның араларын бозарга, берберсеннән аерырга тырыша. Көн саен ул шул уй белән яна. Һәм төрле явызлыклар эшли башлый. Иң башта өй эчендәге әйберләрен ватып-кырып бетерә. Ире кайткач әйтә:

– Менә сеңлең бөтен әйберне ватып-кырып бетерде. «Әтиәнидән калган әйберләр сезнекеләр түгел», – дип әйтә, ди.

Ире моңа каршы әйтә:

– Үзем тапкан мал түгел, әтинеке җәл түгел, дөнья малы табылыр әле, – ди.

Үзе сеңлесенең мондый эшләр эшләмәсен белә. Ире икенче кайтуында хатыны сыерларын, сарыкларын үтереп бетерә. Аннары елап, иренә каршы чыга:

– Сеңлең бөтен мал-туарны үтереп бетерде, инде нишлибез? – ди.

Ире моңа каршы:

– Кайгырма, хатын, баш бетмәсә, мал бетмәс, – ди.

Моңа хатынының тагын да ачуы кабара. Инде дә ышандыра алмагач, ире кайтуга соңгы атларын үтерә, ләкин иренең моңа бер генә дә исе китми. Сеңлесенә бер сүз дә әйтми, элеккечә ярата. Хатыны ачуыннан кая барырга белми.

Менә бервакыт бишектәге баласын үтерә дә, кызны өйдә калдырып, суга китә. Судан кайтуга, ире дә кайткан була. Хатын бишектәге үле баласын күтәреп ала да елый башлый.

– Инде баламны үтергән, – ди.

Бала – бавыр ите. Ире монысында ышана. Ул, балта белән бер түмәр алып, сеңлесе белән урманга китә. Сеңлесе нигә балта алуын сорый.

– Әй сеңлем, син безгә бик күп бәла-каза китердең, мин боларның берсенә дә ышанмаган идем, инде баламны үтергәч ышандым. Бу балта – синең кулларыңны чабып өзәргә, – ди.

Урманга баргач, сеңлесенең кулларын чабып өзә дә кайтып китә. Сеңлесе, елый-елый, урманда йөри. Менә бервакыт кызга бер карт очрый. Карт:

– Кызым, сине кем шушы хәлгә төшерде? – ди. Кыз башыннан үткәннәрнең барысын да сөйләп бирә. Шуннан карт кызны асыл ташлар эченнән агып яткан чишмә янына алып килә дә:

– Кызым, чишмә суы белән кулларыңны юу, – ди.

Кыз терсәкләрен суга тигерсә, исе-акылы китә: кабаттан үсеп чыккан нәфис кулларына карап туя алмый. Шулай итеп куллы була кыз.

Карт:

– Инде, кызым, су эч, – ди.

Кыз, су эчкәч, өч көн, өч төн йоклый. Йокыдан торуына, алдында күзнең явын алырлык киемнәр була.

Кыз, карчыкларча киенеп, хәер сорашучы булып, авылданавылга йөри башлый. Шулай йөри торгач, үзләренең авылына килеп чыга бу. Туп-туры абыйларына китә. Барып керсә, өй эче шау-гөр килеп тора кунаклар белән.

Әбине ачык йөз белән каршы алалар һәм түр башына утыртып куялар. Шуннан әбинең тормышын сораша башлыйлар. Әби боларга:

– Балакайлар, күргәнен сөйлимме, белгәнен сөйлимме? – ди.

Болар барысы да:

– Күргәнен, әби, күргәнен! – диләр.

Әби башыннан үткәннәрен сөйли башлый.

Абыйсы белән җиңгәсе кызны танымыйлар, ә әби хас алар тормышын сөйли. Кунакларның да исе китә. Җиңгәсе ягыннан

да, абыйсы ягыннан да кунаклар бик күп була. Иң соңыннан кыз түзә алмый, елап, абыйсын кочаклап ала да:

– Абыем, менә мин башымнан үткәннең барысын да сөйләдем, явыз җиңгәм мине шушы хәлгә төшерде, син минем кулларымны чабып өздең, ләкин мин сиңа ачуланмыйм, – ди.

Абыйсы хатынының чәченнән тотып ала да:

– Болар барысы да хакмы? – ди.

Хатыны:

– Хак – ди.

Шуннан бу хатынын ат койрыгына бәйли дә чаптырып алып китә.

– Урманга барып җиткәнче, явыз җаның чыкмаса, урманга баргач чыгар, – ди.

Ләкин хатын урманга барып җиткәнче үлә. Абыйсы белән сеңлесе әле булса тату гына гомер итәләр, ди.

*1970 елда Чакмагыш районы Калмаш авылында*
*Мәһүбә Хәсәновадан (1901 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

**251. Ана сөте**

Минем әти яшь чакта, картәтәй бишектә яткан чакта, мин йөгереп йөргән чакта, булган, ди, яшәгән, ди, бик явыз бер карт. Ул ел да кан бәйрәме үткәрә икән. Авылдан 12-13 яшьлек япьяшь егетләрне үзенә чакырып ала икән дә, энә белән төртеп, канын агызып үтерә икән. Шул каннан он белән күмәч салып ашый икән.

Шуннан көннәрдән бер көнне Мәликә апаның Мәлик исемле унике яше дә тулмаган үсмер улын чакырган, ди. Мәликә белән Мәлик мескен ни эшләсеннәр: кочаклашып елашканнар-елашканнар да юлга әзерләнә башлаганнар. Әмма юлда ашарга бер ризыклары да юк икән. Шуннан Мәликә апа алабута онына үзенең күкрәк сөтен сауган да, күмәч пешергән, ди. Шул алабута күмәчен алып, Мәлик юлга чыккан, ди. Бара, ди, бу, бара, ди. Өч көн, өч төн баргач, барып кергән ди.

Исәнлек-саулык сорагач, явыз карт Мәликкә утырырга урындык куйган, ә үзе хәл-әхвәл сораштыра башлаган. Теге

малай бер сүз дә әйтми икән, үзенең юлга дип алган күмәчен тик ашап утыра икән. Шуннан теге карт әйткән, ди:

– Шулкадәр тәмләп ашыйсың, миңа да ашатып кара әле, – дигән, ди.

Картка күмәч шулкадәр ошаган һәм ул егеттән сораган:

– Бу кадәр тәмле итеп моны нәрсәдән пешердегез? – дигән.

Мәлик әйткән:

– Ул күмәч минем әниемнең күкрәк сөтеннән пешерелгән, – дигән.

Шулвакыт карт Мәликне кочаклап ала һәм:

– Их, болай булгач, син минем туганым буласың бит! – ди. – Ә мин үземнең туганыма тимим, – ди.

Һәм егеткә күп күчтәнәчләр биреп, авылга кайтарып җибәрә. Менә шушы көннән башлап, ул кеше үтерми башлый.

*2002 елда Илеш районы Исәмәт авылында*
*Зинфира Мансуровадан БДУ студенты*
*Альмира Хәйретдинова язып алган*

## ТОРМЫШ-КӨНКҮРЕШ ӘКИЯТЛӘРЕ

### 252. Аждаһа кәләше

Борын-борын заманда яшәгән, ди, диңгез артында монахлар. Алар үзләре халыкны таларга бик яратканнар, ди. Байлык җыяр өчен, ел саен авылның иң матур кызын аждаһага бирәбез дип, суга салганнар, ди. Әгәр кызның ата-анасының акчасы монахларга җитсә, алар кызларын коткарып кала алганнар.

Менә бервакыт монахлар авылның иң матур кызын диңгез буена алып килгәннәр һәм суга ташларга хәзерләнгәннәр. Ләкин ташларга өлгерә алмаганнар. Бу диңгезгә бер сәүдәгәр судья үзенең иптәшләре белән йөрергә чыккан. Алар диңгез буендагы шау-шуны ишетеп, монахлар янына килгәннәр. Сәүдәгәр боларга: «Болай кызның үзен генә җибәрү килешеп бетмәс, аждаһага бер монах алдан барып, кыз киләсен хәбәр итсен», –дигән.

Алар үзләре шунда ук бер монахны тотып, суга ташлаганнар. Ул кайтмагач, кая югалганын белергә дип, тагын бер мо-

нахны суга ташлаганнар. Бу хәлне күреп, башка монахларның коты очкан. Алар үзләренең халыкны алдаганлыкларын ачып салганнар һәм, судьяның аягына егылып, гафу үтенгәннәр. Судья боларны кичергән, тик бу эшне башка кабатламаска кушкан. Шулай итеп кыз котылган.

*1970 елда Чакмагыш районы Таш Калмаш авылында*
*Разия Турьяновадан (1899 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 253. Тапкыр таз

Яшәгәннәр, ди, бер авылда бер әби белән бер бабай. Боларның өч уллары булган. Ике ул акыллы булган, ә өченче ул акылга җиңелрәк икән. Бервакыт бабай үлеп киткән. Бу семья бик фәкыйрь булган, ашарларына да, киярләренә дә булмаган. Әби үзенең олы улына әйткән:

– Улым, син берәр авылга барып, берәр байга көтүчелеккә яллан, бәлки тормышыбыз җиңеләеп китәр, – дигән.

Улы, бу киңәшне тотып, чыгып киткән. Бара торгач, бер авылга килеп җиткән. Авылга кергән дә каравыл өе янына килеп баскан. Моны бер бай көтүчелеккә яллаган.

– Ә хезмәт хакы ничек булыр, бай абзый? – дип сораган егет.

– Хезмәт хакың шулай булыр: без бер-беребезгә ачуланмаска тиешбез. Әгәр син миңа ачулансаң, мин синең борыныңны кисеп алам. Әгәр дә мин сиңа ачулана калсам, бөтен байлыгым сиңа була, – дигән икән бай. Егет риза булган.

Иртән торып, ашарга утырганнар. Бай әйткән:

– Син төшкелеккә ашарга алып китмә, күтәреп йөртергә дә авыр булыр. Мин сиңа үзем илтермен, – дигән.

Егет куйларны алып чыгып киткән. Куйлар бик тыңлаусыз икән, аларны бер урынга туплый-туплый егетнең хәле беткән, ашыйсы да килгән, тамагы да кипкән. Бай килмәгән. Егет өйгә ачуланып кайтып кергән. Бай капка төбендә елмаеп басып тора икән.

– Нигә күңелсезләндең әле син? – дип сораган бай.

– Бай абзый, нигә син мине алдадың, нигә ашарга китермәдең, – дигән, ди, егет.

– Әллә ачуланасыңмы, егет?

– Ничек инде ачуланмыйсың, мин көн буена ач йөрдем.

Шулай итеп, бай егетнең борынын кисеп алган һәм бер дару белән ябыштырып, өенә кайтарып җибәргән. Әнисе, улын күргәч, бик аптыраган. Егет, борыным шеште, дип алдаган, дөресен сөйләмәгән.

Шуннан уртанчы туганы киткән, ләкин аның белән дә шулай булган. Бу сихерле җирдер, дип, әнисе курыккан, башкача анда бармагыз, дигән.

Ләкин таз, мин дә барам, дигәч, җибәргәннәр.

Таз бу байга барып ялланган. Барысы да элеккечә булган. Ләкин таз аптырап калмаган, төш вакыты җиткәч, бер куйны суеп ашаган. Калган итен пешереп куйган. Кичтән көтүне алып кайта икән. Үзе әллә кайдан елмаеп, байга кычкырып килә:

– Бай абзый, капкаңны ач, мин кайтам!

Бай, капканы ачып, куйларны санап кертә башлый. Күрә, бер куй юк. Шуннан таздан сорый:

– Кайда бер куй?

Таз:

– Мин аны суеп ашадым. Ите шунда, ашыйсың килсә, син дә барып аша, анда күп әле. Әллә ачуланасыңмы, бай абзый?

Бай:

– Юк, ачуланмыйм. Бер куйдан ни була, – дигән.

Шул көннән башлап таз көн дә бер куйны суя башлаган. Җитмәсә, пешергән итләрне ашатып, бер юлбарысны ияләштергән. Бер көнне юлбарысны көтү белән бергә куып алып кайтып ябып куйган. Бай, иртән торып, абзарны ачып җибәрсә, алдында юлбарыс басып тора, ә бөтен куйлар буып үтерелгән.

Таз:

– Бай абзый, миңа ачуланмыйсыңмы? – дип сораган.

Бай:

– Юк, ачуланмыйм. Бер көтү куй күпмени ул, – дигән.

Бер көнне байны хатыны белән кунакка чакырганнар. Бай, бүтән кеше юклыктан, өендә тазны калдырып китәргә булган.

Таз:

– Бай абзый, мин сезнең өйдә ни эшләрмен соң? – дип сораган.

Байның бик каты ачуы килсә дә, сиздермәскә тырышкан:

– Күршеләр ни эшли, син дә шуны эшләрсең,– дигән.

Күршеләр исә үзләре өмә ясаганнар һәм кунак чакырганнар иде. Алардан күреп, таз да өй түбәләрен сүтеп ташлады, үгез суеп, кунак чакырды. Авылга кайтып керү белән, байның коты очты. Таз өемне яндырган икән, дип уйлады.

Ләкин таз елмаеп, капка төбендә басып тора:

– Бай абзый, мин капканы сүтмәдем, әйдә капкадан кер, – ди.

Шуннан бай бу тазны үтерергә булды. Бик кызу итеп мунча яктырды, мунча ташына су салды. Ләкин таз моны сизеп калды. Мунчага кергәч, ишек төбенә генә утырып, битен чапты, юынды. Шуннан мунчага пар салып, кулларны бутап чыгып китте. Чыкты да:

– И бай абзый, мунча шундый әйбәт, рәхәтләнеп кердем, хәзер үзегез барыгыз инде, – ди.

Шулай итеп, бай мунчада исереп үлә. Таз, үзенең әнисе белән абыйларын да алып килеп, әле булса шунда рәхәт гомер итеп яталар, ди.

*1977 елда Борай районы Абдулла авылында*
*Шәмсекамәр Низаметдин кызы Гайниәхмәтовадан (1907 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 254. Мылтыкчы карт хәйләсе

Бер карт булган. Бу карт, карчыгы үлгәч, яшь бичә алган, ди. Яшь бичә бу картны бер дә яратмаган. Ул картны ничек булса да юк итәргә тырышкан. Бер көнне бер әбидән киңәш сорарга барган, ди. Әби теге яшь бичәгә болай дип киңәш биргән: «Син картыңны тизрәк үлсен дисәң, көн саен майлы ботка ашат, – дигән. – Аның күзләре сукыраеп үләр», – дигән.

Яшь бичә картына көн саен майлы ботка пешереп ашата башлаган. Теге әби бу хәлне бабайга да әйтеп куйган икән. Бабай, яшь хатынының хәйләсен белгәч, юри чирлегә сабышкан.

«Күзләрем күрми башлады, хәлем юк, үләр вакытым җитә бугай», – дип әйткән, ди.

Яшь хатын бу хәлгә бик сөенгән. Үзе янына бер яшь егетне китерә башлаган. Бер көнне бу яшь егет белән ашап-эчеп утыралар икән, теге бабай юри сукырга сабышып мич башында утыра, ди. Карт теге егетне үзе янына чакырып алган да: «Минем хәзер үләр вакытым җитте, күзләрем дә күрми, үлгәнче, мин сиңа менә бу мылтык белән ничек эш итәргә өйрәтим әле», – дигән. Шулай итеп, егетне үзе янына чакырып алган да: «Менә болай тотасың, менә болай тартасың», – дигән һәм егеткә атып җибәргән, ди.

Егет үлгән. Шуннан егетнең үле гәүдәсен бер умарталыкка илтеп куйган. Каравылчы карт, бу кешене умартадан бал урлый дип белеп, тагы атып еккан, ди. Шуннан, кая куярга белми, су буена алып төшкән дә бер көймәгә утыртып җибәргән. Бер охотник үрдәк атарга су буена килгән икән. Бу көймәдәге кешегә: «Кит, үрдәкләрне куркытма!» – дип кычкырган. Шуннан соң әйтеп-әйтеп тә тыңламагач атып җибәргән, ди. Өченче тапкыр атылгач, көймәсе белән су төбенә киткән, ди.

*1977 елда Борай районы Чишмә-Борай авылында*
*Җәмилә Вәлинур кызы Газизовадан (1913 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 255. Зирәк кыз

Борын-борын заманда түгел, борын төбендә бер кантон яшәгән, ди. Ул әйткән:

– Ачыдан-ачы ни бар, татлыдан-татлы нәрсә бар, кем дөресен әйтә, шуңа ярты байлыгымны бирәм, – дип әйткән, ди.

Төрле ачы нәрсәләр китергәннәр, берсе дә ачы булмаган, төрле-төрле әйберләр китергәннәр, берсе дә татлы булмаган.

Бер картның 17 яшьлек кызы булган. Кыз әтисенә:

– Әти ярты байлык ярап калыр. Барып әйт: татлыдан-татлы – бал, ачыдан-ачы – үлем, – дигән.

Карт барып әйткән, кантон әйткән:

– Син моны белерлек түгел, каян белдең? – дип сораган.

Карт әйтергә мәҗбүр булган:

– 17 яшьлек кызым бар, ул әйтте, – дигән.

– Ай-ай, кызың бик башлы икән, – дип, аңа бер чирек ефәк тасма биргән.

– Карт, кызыңа әйт, иртәгәгә миңа күлмәк-чалбар тукып китерсен, – дигән.

Карт елый-елый кайтып киткән.

Әтисе кайгысын сөйләп биргәч, кыз аңа бер бөртек шырпы алып бирә дә:

– Кызымның киндер оясы беткән икән, сиңа киндер урыны ясарга кушты, – дип әйтергә кушкан.

Бабай шырпыны тоткан да, кантон кырына киткән. Кантон кыз кушканны үти алмаган. Шуннан кантон карттан кызын аңа бирүен сораган.

Кыз кантонга кияүгә чыга. Әгәр кыз кантонга эндәшсә, кантонның яраткан әйберен яки ярты байлыгын алып китергә тиеш була.

Бервакыт алар үзләренә мәҗлескә кешеләр чакыралар. Мәҗлес башлана.

Ашагач, кантон сорый:

– Туйдыгызмы?

– Туйдык, – диләр.

Икенчене ашатып беткәч, тагы сорый, шундый ук җавап бирәләр. Өченчене ашатып беткәч, тагы да шундый ук хәл кабатлана. Шуннан кантон боларны гаепли башлый.

Кыз сикереп тора да бер чүлмәк ала. Һәм аңа таш тутырып, уртага кертеп куя.

– Тулымы? – ди кыз.

– Тулы! – дип кычкыралар.

Яңадан ком кертеп сала, селкетә, таш арасына ком сеңеп бетә. Яңадан ком, су кертеп сала. Чүлмәк тулып кына бара. Кыз шунда:

– Һәр нәрсә үз урынына сеңә, барлык ашаган нәрсә дә үз урынына сеңә, – ди.

Кыз кантонга каршы чыккан була бит инде. Кыз кантонны ашата, исертә дә алып чыгып китә. Бара торгач, кантон уяна.

– Син һаман мондамени, чыгып китәргә тиеш идең бит, – ди.

Кыз:

– Юк, чыгып китмәдем. Иң яраткан нәрсәмне, яки ярты байлыгыңны алам, ә иң яраткан нәрсәм – син идең, – ди.

Шуннан кайталар да бик күп еллар матур итеп гомер итәләр.

*1964 елда Балтач районы Иске Яхшый авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

## 256. Әкият яратучы король

Борын-борын заманда булган, ди, бер король. Ул бик тә әкият яраткан, ди. Бердән бер көнне король ат җиткән җиргә ат җибәреп, хат җиткән җиргә хат җибәреп, хәбәр тараткан, имеш:

– Кем дә кем мине әкият сөйләп туйдыра ала, шуңа күп байлык һәм ярты корольлегемны бирәм, – дигән, ди.

Шуннан соң бик күп кешеләр килеп әкият сөйләгән. Ләкин король, тәхетенә утырып, һаман тыңлый икән, ди. Бердән-бер көнне бер егет үзенең көчен сынамакчы булган, ди. Әти-әнисе һич риза түгел, ди, моның.

– Улым, барма син анда. Күпме пәһлеван кешеләр ул король кулыннан үтте инде. Сине дә харап итәр ул, – диешкәннәр.

Шулай да егет көчен сынамак булган, ди. Король янына чыгып киткән бу. Ай барган, ел барган, бер атна дигәндә, барып җиткән, ди, бу теге башкисәр король янына. Рөхсәт сорап, король янына кергән. Шуннан бу егет корольгә әкият сөйли башлаган:

– Борын-борын заманда, борыны китек команда бар чакта, булган, ди, бик саран патша. Бу патшаның байлыгы бик күп булган, ди. Шулай бер көнне ат җиткән җиргә ат җибәреп, хат җиткән җиргә хат җибәреп, патша амбар салырга төзүчеләр чакырткан, ди. Күпмедер вакытта осталар күз күреме җирне биләгән амбар төзеп тә куйганнар. Патша амбарны кош кереп йөрмәслек итеп эшләргә кушкан, ләкин бер мастер бер генә урында чыпчык сыярлык тишек калдырган. Бодайны амбарга тутырганнар. Шуннан соң җир йөзендәге бөтен чыпчыклар җыелып килгәннәр, ди. Җыелып килгәннәр дә берәмләп бодай

ташый башлаганнар. Менә беренче чыпчык беренче бодайны алып чыкты, менә икенче, өченчесе...

Әкиятче корольне өч көн, өч төн тыңлаткан, ди. Король түзмәгән:

– Азагы кайчан? – дип сораган.

– Тукта әле, күз күреме җирне биләгән амбардан берәмләп бодай ташу, майлап бәрәңге ашау түгел ул, – дип җавап кайтарган егет. – Аның азагы кызык әле, – дигән ул.

Яңадан чыпчыклар чиратлап бодай чүпли башлаганнар, ди. Тагын дүрт көн, дүрт төн вакыт узган. Атна тулгач, король:

– Кайчан азагы була? – дип сораган.

– Тукта, анда бодай бик күп бит әле, – дигән егет.

Тагын бер атна вакыт үтеп киткән.

Ә король тәмам җиләгән, ди.

– Җитәр, тукта, кирәкми миңа чыпчыкларың, – дигән, ди.

Шуннан, вәгъдәсендә торып, ярты корольлеген һәм бик күп байлыкны егеткә биргән, ди. Шул көннән башлап бу егет әтиәнисе белән бик әйбәт яши башлаган, ди. Күп тә үтми, бик матур ярлы кызына өйләнеп, җиде көн, җиде төн туй иткәннәр, ди.

Туйларында мин дә булдым, кашыклап бал эчтем, чүмечләп аш ашадым, сыйлары бик мул булды, халык канәгать калды. Шуның белән әкият тә бетте.

*1964 елда Балтач районы Иске Яхшый авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

### 257. Кәҗә, фәкыйрь һәм мәзин

Бер авылда бик фәкыйрь генә бер кеше яши. Читәннән үргән балчык өйдә ирле-хатынлы гына торалар икән. Өйләре мәчет артына салынган икән.

Боларның бердәнбер кәҗәләре була. Кәҗә мәчет артына кереп ашап йөри. Мәзин көн дә ястү намазына килә, башында – яшел чапан. Кәҗә моңа үрелеп карап куя. Ә бер көнне мәзин артыннан менә. Мәзин: «Нигә минем арттан мендең?!» – ди дә, мөгезеннән тотып, манара артына ыргыта. Кәҗә мескен үлә.

Иртән кәҗәнең хуҗалары торалар, ә кәҗә урынында юк. Хатын моны эзләргә китә. Шуннан ирле-хатынлы икәүләп эзлиләр. Ниһаять, моны табалар. Башка кеше эше булмас, дип, мәзингә бик хәтәр яныйлар. Мәзин дә, куркып, намазын ихрабта гына укый башлый. Ә бер көнне манарага менә. Фәкыйрь моны күзәтеп кенә тора да, артыннан менеп, муеныннан тота да манара артына төшереп җибәрә.

Ә абыстай мәзин кайтмагач борчыла башлый. Таң аткач, кешеләрдән, күрше-күләннәрдән сорый. Күргән-белгән фәлән кеше юк. Бөтен җирдән: су буйларыннан, ындыр артларыннан эзлиләр, табалмыйлар. Бик озак йөри торгач, мәчет артыннан табалар. Күзләре акайган, буылган, үлгән. Халык: «Изге бәндә иде, Аллаһ юлында үлгән», – диләр. «Манарага азан әйтергә менгәндә, тамак кырмыйрак менгәндер», – диләр. Мәзинне алып кайтып күмәләр, ә халык телендә, мәзинне мөселман пәрие алмаштырган, дип сөйлиләр. Ә фәкыйрь мәзиннән үч алганы өчен шатланып йөри.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*укытучы-пенсионер Зыяда Латыйповадан*
*БДУ студентлары язып алган*

### 258. Таз әкияте

Борын-борын заманда бер картның өч малае була. Ул бай карт була. Озак та үтми әҗәл чиренә ята. Ул өч малаен чакырып ала да:

– Мин үлгәч, акчаны, бөтен мал-мөлкәтне тигез итеп бүлегез. Тазны да рәнҗетмәгез, – ди.

Бабай үлә. Үлгәч, тәрбияләп күмәләр. Мал-мөлкәтне, бабай әйткәнчә түгел, ике туган үзләренә генә бүләләр дә, Тазга бер үгез генә бирәләр. Таз үгезен ашата-эчертә дә мич башына менеп ята. Ике туган атасыннан калган мал белән спекулять итәләр. Ул байыйлар, ул кием боларда.

Таз әйтә:

– Бәй, мин дә үгезне сатам да байыйм, – ди.

Бердән-бер көнне үгезне җитәкли дә, базарга китә. Бер урман аша үтәргә туры килә. Аклан очрый. Акланда ялгыз каен үсә. Каен бик шаулый. Таз шунда барып утыра.

– Минем үгезне аласы киләдер, – ди.

Каенга:

– 50 сум бирерсең, – ди Таз.

Каен һаман шаулый.

– Ярый, иртәгә бирәсеңдер, – ди дә, үгезен каенга бәйләп, кайтып китә.

Туганнар кемгә, күпмегә бирүен сорый.

– Нигә сезгә кирәк? Каенга, – ди Таз.

– Акчасын бирдеме, күрсәт әле, – дип сорыйлар тегеләр.

– Сезгә нигә кирәк, акчасын иртәгә бирә, – дип җаваплый Таз.

Тора бу иртә белән, атасыннан калган балтаны ала да урманга бара. Әгәр каен акча бирмәсә, кисәргә уйлый. Өч тапкыр каеннан акча сорый да, кисә башлый үзе биеклек җирдән. Кисеп бетерүе була, кискән җирдән алтын ага башлый.

– Ә, үзәгеңә үткәч, бирдеңме алтыныңны! – ди Таз.

Ат белән киләләр урманга. Бик иртә була бу. Барып җитәләр, алтынны пулыхка төйиләр, өстенә утын өяләр дә, үзләре җәяү кайтарга чыгалар. Каршыларына бер мәзин очрый. Ат артыннан килә икән ул. Кая баруларын сораша. Агалары: «Утынга бардык», – диләр. Ә Таз беркатлы:

– Үгезне саткан иде, алтын алып кайтабыз, – ди.

Мәзиннең алтынны бик күрәсе килә, шул вакытта бер уч алтынны алып кесәсенә салып та куя. Ә Таз, ачуланып, балта белән моның нечкә җилкәсенә чаба. Мәзин үлә. Моны арбага салып алып кайталар да, кеше күрмәс борын, базга ыргыталар. Алтынны тиз-тиз җыештыралар тавышсыз-тынсыз гына.

Иртән бөтен халык шаулый: ат алырга киткән җиреннән мәзин юк. Ялан калмый, япан калмый, мәчет тирәсеннән эзлиләр. Шуннан авылның актив сымаклары өйдән-өйгә кереп тентү ясый башлыйлар. Бу вакытта Таз капка төбендә утыра. Таз боларны күргәч:

– Мәзинегез безнең базда бит, – ди.

Агалары башта кертми торалар тикшерүчеләрне, азак шулай да кертәләр. Тазны базга төшерәләр. Таз астан кычкыра:

– Мәзинегезнең сакалы бар идеме?
– Бар.
– Күзе, аягы-бармы?
– Бар.
– Мөгезе бармы?
– Бәй, мәзиннең мөгезе буламыни? – дип, халык аптырый.
Ә туганнары:
– Бәй, нигә Таз сүзенә карадыгыз соң?! – диләр.

Шулай итеп, агалары мәзин белән эшне төнлә үк бетереп куйган булалар. Шуннан инде Таз да, агалары да бик әйбәт кенә яшәп китәләр.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*укытучы-пенсионер Зыяда Латыйповадан*
*БДУ студентлары язып алган*

## 259. Кырык карак әкияте

Бер авылда урта хәлле генә бер бай яши. Боларның бик үткер, бик матур, бик тере Корбанбикә исемле бердәнбер кызлары була. Бу кыз бик уңган, бөтен эшкә өлгерә.

Бер заман моның әтиләре шәһәргә кунакка китәләр. Боларга кырык километр чамасы ераклыкта кара урман була. Шунда кырык бер карак яши. Бу каракларның кырыгының хатыны була, берсенеке булмый. Ул каракларның башлыгы икән.

– Син дә өйлән инде, – диләр моңа.

Башлык:

– Миңа кырык хатыныгыздан да чибәр, үткен, зирәк кыз кирәк, – ди.

Хәзер болар гади кием киенеп, кайсы сораучы, кайсы тегүче булып, якын-тирә авылларга таралалар. Икесе Корбанбикә яшәгән авылга килә, көмеш коючы булып. Корбанбикәләрнең өйләренә дә керәләр. Корбанбикә һуш китәрлек чибәр кыз була. Шуннан караклар кайталар, җыелалар, күргәннәрен сөйлиләр. Иң матуры Корбанбикә булып чыга. Шуннан киңәшләшәләр болар:

– Я, кызны ничек алабыз: кодалапмы, көчләпме, урлапмы? – диләр.

– Нигә, бай малае булып барабыз да кодалыйбыз, – диләр болар.

Әйбәт итеп киенеп, яңадан баралар болар. Ни өчен килгәннәрен кызның әти-әнисенә сөйләп бирәләр. Әтисе:

– Әле билгеле түгел, бер нәрсә дә әйтәлмибез әлегә, чөнки кунакка китәбез хәзер, – ди.

Дүрт көннән соң әтиләре кунакка китәләр. Караклар уйлашалар:

– Тукта әле, әтиләре кунакка китте, без барыйк та урлыйк аны, – диләр.

Икенде-ахшам вакытында караклар абзарга качалар. Корбанбикә малларны карый, салам сала, эшен бетерә дә кызлар җыярга китә. Шулчак караклар өйгә үтеп, базга кереп качалар.

Кызлар җыелалар: кайсы тегә, кайсы бәйли, кайсы җөн эрли. Шуннан бер кызның базга ялгыш энәсе төшеп китә бит. Кыз энәсен эзләргә төшә. Төшсә, анда ике кеше утыра. Бик нык курка. Караклар моңа бер сүз дә әйтмәскә кушалар.

– Берәр нәрсә әйтсәң, кара аны, – дип яныйлар.

Кыз баздан чыга. Корбанбикә чәй әзерләгән арада, әлеге кыз иптәшләренә бу турыда әйтә. Шуннан кызлар төрлесе-төрле хәйлә, сәбәп табып, таралышып бетәләр. Корбанбикә кызларын озатып, ишекләрен элеп керә. Керсә, теге ике карак уже стулда утыралар. Корбанбикә бер дә исе китмичә:

– И, кызлар киткән булды тагы. Китсәгез, миңа яңа иптәшләр килгән менә, – дип сөйләнеп, тегеләр белән барып кул биреп күрешә.

Шунда ук самавыр куеп җибәрә, өстәлгә сый-хөрмәт әзерли. Өстәл артында бу ике кеше нигә килгәннәрен әйтәләр. Корбанбикә аларга сандык әйберләрен күрсәтә башлый.

– Алып китәргә булыр, – ди.

Ашагач, теге каракларның тышка чыгасы килә. Тегеләрнең чыгуы була, кыз ишекне элеп тә куя! Керергә дөбердәтәләр тегеләр, тик Корбанбикә ачмый. Ул аларга:

– Ул хәтле дөбердәтмәгез, күршеләрдән яхшы түгел, барыгыз, тәрәзәдән генә керегез, – ди.

Тегеләр тәрәзә янына баралар да:

– Менеп булмый бит, – диләр.

Шуннан Корбанбикә, балта алып, тәрәзә янына килә дә тегеләргә салфетка төшерә. Салфетка белән тартып ала да, башта берсенең, аннан икенчесенең башын чаба да, тураклап, арыш капчыгына тутыра.

«Нигә озакладылар икән?» – дип, тагын ике карак атта киләләр. Корбанбикә аларга әлеге капчыкларны тоттыра да:

– Алып китә торыгыз, бу – минем әйберләрем, – дип биреп җибәрә.

Кайткач ачып карасалар – теге иптәшләре.

– Син безнең иптәшләребезне бәлешкә турап җибәргәнсең, үзеңне без пилмәнгә турарбыз, – диләр алар.

Кызның әтиләре кайта. Корбанбикә бөтенесен дә сөйләп бирә. Шуннан боларга тагын ике карак килә. Әти-әнисенә нигә килгәннәрен сөйлиләр. Корбанбикә риза булырга куша. Әти-әнисе бик елап озатып калалар.

Кайтканда, караклар аны бик нык куркыталар. Килеп җитәләр. Башлык әйтә:

– Үтергәнче, бер кич булса да куныйм әле, – ди.

Боларны кәҗә keləте белән бер рәттән торган өйгә урнаштыралар да тыштан зур йозак белән бикләп куялар. Төнлә Корбанбикә өйтә:

– Минем тышка чыгасы килә, – ди.

Башлык әйтә:

– Кая чыгасың инде, ишек бикле бит, өйдә генә утыр, – ди.

Корбанбикә әйтә:

– Өйдә кыен бит, оялам, син мине лутчы сөлге белән бәйлә дә анавы өстәге тәрәзәдән төшер, – ди.

Корбанбикә сөлге белән абзар эченә төшкәч, үзен чишә дә кәҗәне сөлгегә бәйләп куя. Башлык эчтән сөлгене тарта, кәҗә мекердәп куя. Башлык:

– Ну, бирән, ашагансың да икән! – дип эчтән сүгенә.

Бераз торганнан соң, тартып мендерә, караса – кәҗә. Башлык шакката:

– Корбанбикә кәҗә булган! – ди ул.

Ныклабрак караса, эшнең нидә икәнлеген аңлап ала: бу үзләренең кәҗәсе, ләбаса!

Ә Корбанбикә кача. Иртән караклар эзләргә чыгалар. Иң элек ул базарда бер тире сатучының тиреләре арасына качып кала. Аннан бер чүлмәкчедә яшеренә. Караклар аны табалмыйлар. Корбанбикә, шулай итеп, өенә кайтып җитә. Туры өйгә керми, каракларның өйдә булуы бар, дип, печәнлеккә кереп яшеренә. Аннан, әтисе абзарга килгәндә, аның каршысына чыга. Әтисе хәйран кала инде. Шуннан Корбанбикә башыннан үткәннәрнең бөтенесен дә сөйли. Аннан бөтен авыл халкы коралланып, җыелып баралар да, каракларны үтереп бетерәләр, мал-мөлкәтләрен үзләренә алалар.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*укытучы-пенсионер Зыяда Латыйповадан*
*БДУ студентлары язып алган*

## 260. Өч туган

Яшәгән, ди, өч туган. Бер заман болар баю нияте белән женшень казып сатмакчы булганнар. Боларның юллары уңган. Йөз мең кешегә җитәрлек женьшень тамыры казып алганнар. Шуннан, ике туган сүз берләшеп, өченчесен үтереп, аның тамырларын үзләренә алганнар. Соңыннан исән калган ике туган ничек булса да бер-берсен үтерү юлын эзлиләр икән. Менә алар авылларына да кайтып җиткәннәр.

– Бар, – дигән берсе икенчесенә, – суля[1] алып кил, мин сине монда көтеп торырмын.

Икенчесе суля алып килә, туганына бир. Икенче туганы уйлый:

– Әгәр мин туганымны үтерсәм, суля да, тамыр да миңа кала, – ди икән.

Ул шулай иткән дә. Килү белән туганын атып үтергән дә суляны эчеп тә җибәргән. Һәм шунда ук җиргә тәгәри. Чөнки үтерелгән туган да үзенең туганын үтерү өчен суляны агулаган була. Алар шулай өчесе дә үләләр, ә кыйммәтле женьшень тамыры череп бетә.

---

[1] *Суля* – чын атамасы – *сулема*, көчле агу. Элек дәвалану өчен кулланылган.

Шул заманнан бирле кешеләр тамыр да, акча да эзләми, тик туганнарын гына эзли торган булганнар.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Калмаш авылында Гайшә Газизовадан (1928 елгы) БДУ студентлары язып алган*

**261. Тугрылык һәм хыянәт**

Бер кеше суга баткан чакта, моны берәү коткара.

– Син мине үлемнән коткардың, инде мин сиңа ни яхшылык итим? – ди теге кеше.

– Мин синнән берни дә сорамыйм, тик иртәгә күл буена иң якын, иң тугрылыклы кешеңне алып кил. Мин дә шунда булырмын, – ди.

Шуннан бу юл буйлап уйланып кайта һәм хатынынннан да якын, аңардан да тугрылыклы кешене табалмый.

Икенче көнне алар хатыны белән күл буена киләләр. Килсәләр, теге кеше юк. Шуннан моны бик озак көтәләр, ләкин коткаручы кеше һаман юк. Бу ирнең йокысы килә башлый һәм ул: «Теге кеше килсә, мине уятырсың», – дип, йокыга китә.

Хәтсез вакытлар үткәч, көймәгә утырган берәү күренә. Аның көймәсе тулы алтын, көмеш була. Хатын бу кешене күреп, ирен уятырга уйлый, тик шулвакыт көймәдәге кеше:

– Уятма! – дип кычкыра. Яр буена килеп туктагач, хатын янына килә.

– Әгәр риза булсаң, әйдә, минем белән киттек, ә ул калсын шунда, – ди. – Киткәнче, шушы балта белән аның башын чап, – ди.

Хатын моның алтыннарына бик кызыга бит инде. Уйлап-нитеп тормый, иренең башына чабарга дип, балтаны күтәрә. Шулвакыт теге кеше моның ирен уята.

– Шушымы синең иң якын, иң тугрылыклы кешең? – дип сорый ул. – Әгәр хатының урынына этеңне алып килгән булсаң, ул синең яныңа беркемне дә җибәрмәгән булыр иде, – ди.

*1970 елда Чакмагыш районы Йомран авылында Фатыйх Әбелфазыл улы Шәмсетдиновтан (1893 елгы) БДУ студентлары язып алган*

## 262. Ике сатучы

Ике сатучы яшәгән, ди. Алар бик дус булганнар. Бер көнне сатучыларның берсе базарга китәргә җыена. Ләкин тимерләрен урлап китүдән куркып уйга кала. Башкаларга ышана алмый инде бу сатучы, дустына илтеп куя. Аннан бу базарга китә. Дусты моның тимерен сатып җибәрә дә хәйлә кора. Сатучы базардан кайта, сорый тимерен. Дусты болай дип җавап бирә:

– Әй, дускай, мин күрмәгәндә генә, синең тимереңне тычканнар кимереп бетергәннәр, нишлисең инде, хәерле каза булсын. Ышанмасаң, әйдә, барып кара.

Сатучы әйтә:

– Юк, барып тормыйм инде, сиңа да ышанмагач, иң якын дустым бит.

Шулай ди дә, сатучы үз юлы белән китә. Юлда дустының баласын очрата һәм үзе белән алып китә. Баланың атасы бик кайгыра һәм дустына киңәш сорап килә.

Дусты әйтә:

– Мин синең балаңны күрдем, бик җәлләдем дә, тик соң иде шул. Аны зур бер кош күтәреп алып китте. Хәерле каза булсын инде, нишлисең бит.

Бу сүзләргә дустының ачуы  килгән һәм әйткән:

– Баланы кош күтәреп киткәнен кайчан күргәнең бар, нигә тузга язмаган сүз сөйлисең? – дигән.

Моңа каршы сатучы:

– Әйт әле, дускаем, синең кайда тимерне тычканнарның ашаганын күргәнең бар? – дип сораган.

Ни эшләсен инде дусты, туры сүзгә җавап юк. Гаебен сөйләп биргән һәм, тимер өчен акча түләп, гафу үтенгән.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Коты авылында*
*Рәйсә Миһрановадан (1911 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 263. Тапкыр кыз

Борын-борын заманнарда бер патша булган, ди. Бу патшаның хатыны ач күзле булган, ди. Халык өстеннән шулкадәр

издеваться иткәннәр, инде ул гына җитмәгән, көннәрдән бер көнне ул: «Адәм сөягеннән сарай салдырыйк», – дия башлаган. Патша әйткән:

– Каян җыябыз? Ничек салабыз аны?

Моңа патша каршы килмәгән. Хатыны:

– Сәбәп табып хезмәтчеләрне үтерик, – ди.

Шуннан вәзирләрен-ниләрен җыя да киңәш итәләр. Үзләренең мәмләкәтендәге халыкны җыялар да болай диләр:

– Дөньяда нәрсә каты, нәрсә татлы, нәрсә ерак китә? – диләр.

Шуңарга җавап бирәлмәсәләр, халыкны асып үтерергә булалар, ә сөягеннән сарай салдырырга уйлыйлар. Халыкларга уйлау өчен, өч көн бирәләр. Беренче көнне җыялар да:

– Дөньяда нәрсә каты? Нәрсә татлы? Нәрсә ерак китә? – диләр. – Әгәр шуны белмәсәгез асабыз, – диләр.

Шуннан берсе дә табалмый. Кайсы әйтә:

– Таш каты.

– Нәрсә татлы?

– Бал татлы, җимеш татлы, – диләр.

Дөньяда булган татлы нәрсәләрне әйтеп бетерәләр инде.

– Дөрес түгел, – диләр. – Нәрсә тавышы ерак китә? – диләр.

Кайсы әйтә:

– Машина, кош, поезд, җәнлек тавышы ерак китә, – диләр.

– Дөрес түгел,  – диләр тагын.

Шуннан өч көн генә вакыт куялар. Өч көндә шуларга җавап бирергә, бирә алмасалар – асалар. Әгәр араларынннан берсе җавап бирсә дә котылалар. Ләкин берсенекен дә дөрескә чыгармыйлар. Инде халык елаша башлый, аптырый, җавап табалмагач. Шуларның арасында сиксән яшьлек бабай була.  Хатыны булмый, унҗиде яшьлек кызы белән генә торган була. Кызы сорый:

– Әткәй, нигә җылыйсың?

Балигь булмаган балалардан сорамаганнар чөнки, ә картлардан гына сораганнар.

– Әй кызым, шулай-шулай бит әле. «Дөньяда нәрсә каты, нәрсә татлы, нәрсә ерак китә?» – дип сорыйлар патша хозурында. Без шуларга җавап таба алмыйбыз, – ди. – Нәстә генә әйтсәк

тә, дөрес түгел, дияләр, – ди. – Менә ике көн бардык инде, җавап бирә алмасак, иртәгә асалар, тунап-киптереп, сөяктән сарай салдыралар, – ди.

– Әй, эткәй, нигә кайгырасың, нигә елыйсың, аңарга җавап табып була бит, – ди кызы. «Нәрсә каты?» – дип сорасалар: «Ат тоягы каты», – дип әйт, – ди. «Ул ничек каты?» – дип сорасалар: «Атның аягы тузмый, ничә еллар буе йөрсә дә, атның аягындагы тимер туза, атның тоягы тузмый», – дип әйт, – ди.

Бара бу. Сорауларга җавап бирә. Патша белән вәзирләре аптырыйлар.

– Нәрсә йөгерек? – дип сорыйлар.

– Күңел, мин күңелем белән бөтен дөньяны әйләнеп чыгам, – ди.

– Нәрсә татлы?

– Йокы, – ди бабай. – Мин ләззәтле ашамлыкларны ашамасам да тора алам, ә йокысыз тора алмыйм, – ди.

– Дөрес, – дип, боларны коткаралар, ә бабайны алып калалар, чөнки берсе әйтә:

– Ул аларны белмәс иде, аңа кызы әйткән, – ди.

– Бабай, кызың бармы? – дип сорыйлар.

– Бар, ул әйтте, – ди бабай.

Хәзер инде патша әйтә:

– Бабай, кызың булгач, күп белгәч, мә сиңа унбиш күкәй. Алып кайт, бер көн эчендә чыгарсын да, утыртсын да, жарить итәргә чебешләр китер, – дип әйтә.

Бабай елый-елый алып кайтып киткән, ди. Ә кызы тагын сорый:

– Тагы нәрсә булды?

– Әй, кызым, сиңа патша унбиш күкәй җибәрде, – ди. – Шул күкәйләрдән чебеш чыгарып, үстереп, патшага иртәгә илтергә кирәк, – ди.

Кыз:

– Әй, эткәй, елама, давай, пешереп ашыйк әле аны, – ди.

Иртән торгач та, пешереп ашата, кулъяулыгына бер кашык тары салып җибәрә. Бабай патшага бара.

Патша:

– Чебешләр китерденңме? – ди.

Бабай әйтә:

– Чыгып өлгерде, ашатырга ярма юк, – ди. – Менә, сиңа кызым тары җибәрде, шуны чәчеп, үстереп бир, иртәгә чебешләргә ярма кирәк, – ди.

Шуннан патша җитен җибәрә бер уч.

– Шушы җитенне бүген эрләсен дә, суксын да, күлмәк тегеп җибәрсен!

Бабай кайтып китә дә, кызына әйтә, ә кызы бер орчык кадәре генә агач җибәрә патшага.

Патша:

– Күлмәк китерденңме? – ди.

Бабай:

– Өлгермәде, – ди. – Өлгерер иде дә, кызның инструментлары юк, – ди. – Менә сиңа агач, шушы агачтан иртәгә инструментлар әзерлә, – ди.

Патша бабайга бер үгез биреп җибәрә.

– Кызың бозаулатсын, мин икенче атнага баруга, – ди.

Бабай үгезне көчкә алып кайтып китә.

– Әй, кызым, патша үгез җибәрде, – ди. – «Киләсе атнага үзем барам, мин баруга бозаулатсын», – дип әйтте, – ди.

Ә кызы:

– И, эткәй, бер дә кайгырма, безгә бер еллык ит булды, – ди.

Икенче көнне, күрше-тирәне чакырып, үгезне суеп элеп куйды, ди. Шуннан кызы юына, җыена да, патша килер көнне мич яга, бәлеш сала. Патшаның килер сәгате җитте, ди. Шуннан, патша күренгәч, тройка белән:

– Әткәй, син мунчага бар, – ди, үзе тары төяргә чыга.

Патша килеп җитә, кыз янына төшә. Кыз тары төя.

– Нихәл, туташ? – ди.

Кыз:

– Исән, бик әйбәт, – ди.

Патша:

– Бу тары ничә төюдә әзер була?

Кыз:

– Атың ничә басуда килеп җитте, шулкадәр, – ди.

Патша:

– Бу киледә ничә бөртек тары бар? – ди.

Кыз:

– Башыңда ничә бөртек чәчең бар, шулкадәр, – ди.

Патша:

– Әткәң өйдәме? – ди.

Кыз:

– Әткәй өйдә юк, мунчада, – ди.

– Нәрсә эшли?

Кыз:

– Бәбәйли, – ди.

Патша:

– Нигә, ирләр бәбәйлимени? – ди.

Кыз:

– Нигә үгез бозаулыймыни? – ди.

Патша әйтә:

– Кыз, син бик күп беләсең, мин сине үземә хатынлыкка алам, – ди. – Киләсеңме?

Кыз:

– Киләм, киләм, – ди, – патша кадәр патшага булгач киләм.

Патша:

– Син только күп беләсең. Миннән башка хөкем итмәссең, әгәр миннән башка хөкем итсәң аерам, – ди.

Кыз:

– Ярар, син мине аергач, синнән җаным теләгән бер нәрсәне алам, – ди.

Патша, ризалашып, кызны алып кайта. Атасын да алып кайта, ашыйлар-эчәләр дә патша кызны алып кала. Күпмедер торгач, патша бер атналык юлга чыгып китә.

Яланда ике кеше кунган була, атларын тугарып. Иртән торсалар, берсенең биясе колынлаган да (боларның берсенең аты – бия, икенчесенеке алаша булган), алаша янына барып яткан. Менә болар сугыша башлыйлар.

Берсе әйтә:

– Минем бия колынлаган!

Икенчесе:

– Минем алаша колынлаган, – ди.

Шуннан китәләр хөкем чыгарырга патша янына, ә патша өйдә булмый, кызга хөкем чыгарырга туры килә. Кыз сорый:

– Нигә килдегез?

– Хөкемгә килдек, – диләр.

Кыз:

– Патша өйдә юк, – ди. – Ни өчен хөкемгә килдегез?

Берсе әйтә:

– Минем биям колынлаган иде, ул үзенең алашасы дип әйтә, – ди. Икенчесе:

– Минем алашам колынлаган, колын минем алашам янында ята иде, – ди.

Кыз:

– Әй, сантыйлар, алаша колынлыймыни? – дип, колынны биягә ияртеп чыгарып җибәрә.

Болар чыгып кына баралар иде, патша кайтып керде, ди.

– Нәрсә эшләп йөрисез монда?

Шуннан тегеләр хөкемгә килүләрен әйтәләр. Һәм: «Хатының хөкем итте инде», – диләр дә кайтып китәләр. Патша хатынын җәберләргә тотына:

– Мин сине аерам, – ди.

Хатыны:

– Ашыйк та китәрмен, – ди.

Шуннан патшаны исертә дә вәзирләренә ат җигәргә куша. Ат җиккәч, патшаны атына чыгарып сала да алып кайтып китә. Юлда патша айный һәм сорый:

– Нигә мине алып кайтасың?

Хатын:

– Синнән киткәндә, җаным теләгән нәрсәне алырга кушкан идең, – ди.

Патша:

– Синнән аерылып булмый икән, әйдә кайтабыз, – ди.

Һәм алар үлгәнче тигез гомер итәләр.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Ихсан авылында*
*Мәдинә Сөләймановадан (1895 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 264. Пәйгамбәр акылы

Сөләйман пәйгамбәр булган, ул дөньядагы бөтен нәрсәнең телен белгән. Шуннан бу бер пәйгамбәргә әйтә:

– Иртәгә көн аяз булыр, сәхрәләргә чыгып, көн буе йөр. Кайткач, нәрсә күрдең, барсын да миңа сөйләрсең, – дигән.

Икенче көнне чыгып киткән бу пәйгамбәр. Күп йөри торгач, алтын тас тапкан. Бу тасны бераз күтәреп йөртә дә соңыннан күмеп куя, «күтәреп йөртергә авыр булыр, килеп алырмын», – дип. Бераз киткәч, артына борылып карый. Караса, теге тас җир өстендә утыра, күмгән җиреннән чыгып. Тагы күмә килеп. Өч тапкыр килеп күмә. «Миңа язмагандыр, язса килеп алырмын әле», – ди дә китә. Бер фил очрый. Филне тычкан сөйрәп йөртә, гаҗәпләнеп карап тора да берни дә әйтә алмый китә, ди, тагы.

Йөри-йөри, бик матур кыз очрый, ди. Бу кыз уйнап-көлеп кенә тора, ди. Бик мәхәббәтле булган, йөгерә дә туктый, йөгерә дә туктый. Шуннан бу кыз белән сөйләшмәкче булды, ди. Кыз артыннан йөгерә-йөгерә арып бетте, ди, бу. Көн буе йөргәч, кайтты, ди.

Сөләйман каршы чыгып:

– Ниләр күрдең? – ди.

– Йөрдем-йөрдем дә бер алтын тас таптым, – ди теге.

– Кая илттең аны,– ди Сөләйман.

Тегесе:

– Бераз күтәреп йөрттем дә җиргә күмдем, – ди. – Килә дә чыга, килә дә чыга, өч тапкыр күмдем, – ди теге.

– Нәрсә мәгълүмат алдың?

– Бер мәгълүмат та алмадым, миңа язмагандыр, дидем дә киттем, – ди.

– Мәгълүмат шул: заман ахырына таба җир астындагы бөтен байлык өскә чыгар, – ди Сөләйман.

– Фил очраттым, филне тычкан сөйри иде, – ди.

– Аннан нинди мәгълүмат алдың?

– Бер мәгълүмат та алмадым, карап тордым да алга киттем.

– Мәгълүмат шул: «Заман ахырына таба ирләрне хатын-кызлар сөйрәп йөртер, – ди, – иң галәмәте шул, – ди.

– Бер кыз очраттым, аны көн буе кудым-кудым да җитә алмадым, үзе тоттырырга гына тора, үзе алдата, – ди.

Сөләйман пәйгамбәр әйтә:

– Аны кумаган кеше юк, ул – дөнья, шулай тоттырмый, – ди. – Дөньяны кумаган кеше юк, дөнья кудырта, – ди.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Ихсан авылында*
*Мәдинә Сөләймановадан (1895 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 265. Поп ничек көлкегә калган?

Бер авылда ярлы гына бер итекче белән аның бик матур хатыны яшәгәннәр. Болар бик тату гына гомер иткәннәр. Шушы ук авылда бер азгын поп та яшәгән. Ул, туры килгәндә, һәрвакыт хатын-кызлар белән шаярырга ярата икән.

Итекче хатыны попларга көн саен суга керә икән. Поп аңа һәрвакыт баштан-аяк карап, тамак кырып кала икән. Мондый хәл көн дә кабатлана башлагач, итекче хатыны иренә хәлне сөйләп бирә. Итекче:

– Ул сиңа тамак кырганда, син дә җавап итеп тамак кыр, – дигән.

Шуннан болар поп хатынын да чакырып, попны бик яхшы өйрәтергә булып, план коралар. Икенче көнне итекче хатыны попларга суга керә. Попның өйдә табынып утырган чагы була. Ул хатынны күреп алгач, тизрәк табынуын төгәлли дә, үз хатыны күрмәгәндә, ишек алдына чыгып сыза. Кулына себерке алып себергәндәй итеп йөри башлый һәм хатынга:

– Ыһым, ыһым киленкәй, Аллаһ ярдәм бирсен, – ди.

– Ыһым, ыһым, поп абзый, сәламәт бул, – дигән була итекче хатыны. Попның эченә җылы йөгерә. «Ходай күңелләребезне берләштергән икән», – ди.

Базар көнне итекче, аркасына капчык асып, базарга китә. Хатыны озата чыга, ә поп боларның сүзләрен тыңлап тора. Ә итекче поп ишетерлек итеп хатынына:

– Кара аны, яхшы гына тор, мин иртәгә шушы вакытларда кайтып җитәрмен, – ди.

– Эш пешә, – дип шатлана поп.

Кичкә таба поп арт ишектән итекче хатыны янына юл тота. Хатын өйдә була, өй эшләрен бетереп, чигү чигеп утырган була.

– Әйдүк, атакай, – дип каршы ала ул попны.

Чәй куеп җибәрә, поп ачык чырай, такта чәй булгач, түргә үк менеп утыра. Болар әйбәт кенә утырганда, ишек шакыйлар.

– Ай, атакаем, харап булдык бит, – ди хатын, – ирем кайткан, ахры, син мич башына менеп тор, җае килгәч, үзем чыгарып җибәрермен, – ди.

Үзе барып ишекне ача.

– Юлдан кире әйләнеп кайттым әле, сине дә ялгыз калдырасым килмәде, – ди ире.

– Вот дошман, мешать итеп йөри, – ди поп.

– Бездә кунак та бар әле, бер хәер сорашып йөрүче бабай, әнә мич башында йоклап ята, уянгач, бергәләп чәй эчеп җибәрәрбез, – ди хатын. Үзе мич янына килеп:

– Бабай, бабай, төш монда, – ди.

Поп нишләсен, әкрен генә мич башыннан төшә. Итекче һәм хатыны, попны күреп, чак көлеп җибәрмиләр. Мич башында попның бите-кулы, өс киеме кап-кара була. Поп морҗалардан төшкән ак тавыкка ошап кала.

Итекче:

– Бабай, бик күп җирләрдә йөргәнсең бугай, сакал-мыегың да җиткән, сиңа игелегем тисен, бер савап булыр, – дип, попның ай-ваена карамыйча, сакал-мыегын кырып ташлый. Поп танымаслык булып үзгәрә.

Шул вакытта поп хатыны килеп керә. Попның коты ботына җитә һәм тиз генә яңадан мич башына менеп китә. Поп хатыны:

– Энем, тиз генә атакайның аяк киемен төзәтеп бирмәссең микән? Үзе әллә кая китеп югалды: әллә чиркәүдә, әллә кайда йөри. Көттем-көттем дә, аптырап, үзем килдем. Иртәгә күрше авылга кунакка бара идек, – ди.

– Кая әле карыйк, – ди итекче.

– Әй, энем, я өйдә булмассың, дип, әле алып килмәгән идем. Сине поп, базарга китте, дип, сөйләп торган иде. Әллә килеп, син генә алып китәсеңме? Шунда ишек катында гына иде.

Итекче хатыны чыгып киткәч, болар өйдә икесе генә калалар. Поп хатыны юри:

– И энем, карт поп белән торып, аның карт сөякләрен кочаклап гомерем узды инде, менә синдәй ирең булсын иде ул, – дип, итекчене кочаклый.

Итекче дә:

– И апакай, сиңа минем дә күптән күзем төшеп йөри иде, – дип, ул да кочаклап ала.

Ә поп мич башында сүгенеп утыра. Мыгырданган тавыш ишетеп, итекче:

– Син нәрсә, бабакай, саташып уянып догаңны укыйсыңмы? – ди.

– Эһем, эһем, эчем авырта, – дип, поп тиз генә тышка чыгып йөгерә. Юлда үзләреннән кайтып килгән итекче хатынын чак кына бәреп екмый.

Поп җан-фәрманга чабып, өенә кайтып керә, тиз генә өсбашын алмаштырып юына һәм, исән-имин калуына шатланып бетә алмыйча, Ходайга дога кылырга утыра.

Бераздан хатыны да кайтып керә. Ул юри попны танымаска салышып:

– Әллә карак кергән инде йортка! – дип кычкырып җибәрә.

Поп:

– Чү, карчык, чү. Бу мин бит, картың, – ди.

Хатыны елап җибәргән була.

– И картыкаем, кайларда булдың соң син, ниләр эшләдең? – ди.

Ә поп исә:

– Сине кайда кочакладылар, мине дә шунда кырыктылар, – ди.

Шуннан соң поп акылга утыра.

*1970 елда Чакмагыш районы Рәҗәп авылында*
*Өмелхәят Ибраһимовадан (1903 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 266. Без еламый кем еласын?

Бер карчык була. Алар үсеп җиткән бер кызы белән икәүләп кенә яшиләр. Бер көнне кыз көянтә-чиләкләре белән елгага суга төшә. Яр буена утыра, уйлана да елый башлый.

– Мине суның арьягына кияүгә бирсәләр, миннән бала туса, ул «картинәйләргә барыйк», дип еласа, су аша чыкканда, суга батып үлсә, мин еламый кем еласын, – дип такмаклый бу.

Кызын әнисе эзләп төшә. Әнисе дә елый башлый. Кочаклашып елыйлар. Бер адәм килеп чыга.

– Нигә елыйсыз? – дип сорый.

– Мине суның аръягына кияүгә бирсәләр, миннән бала туса, ул «картинәйләргә барыйк», дип еласа, су аша чыккан да суга төшеп үлсә, – без еламый кем еласын, – дип, тагын да ныграк елый башлыйлар.

Теге кеше:

– Сездән дә юләррәк кеше булмас микән? – дип, эзләп китә.

Бер күл буена барып чыга. Бер абый шунда бау ишә. Ике хатын суга төшеп киләләр.

– Нигә бау ишәсең? – дип сорыйлар тегеңәрдән.

– Күлне күккә асам, – дип җавап бирә теге.

Хатыннар елый башлый.

– Болардан да юләррәге юктыр инде – дип, үз юлына китә теге кеше.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*укытучы-пенсионер Зыяда Латыйповадан*
*БДУ студентлары язып алган*

## БӘЕТЛӘР

САК-СОК БӘЕТЛӘРЕ

### 267. Беренче бәет

Балалар, шаярмагыз,
Анага карышмагыз.
Йөрегез адәм булып,
Сыйфатны алышмагыз.

Без дә, без дә уйнар идек,
Суларга чумар идек.
Күп вакыт өйгә кайтмый,
Бакчада кунар идек.

Без икәүләп кайтмаганда,
Эзләп тә тапмаганда,
Ачулана иде әнкәй
Күңеле тапмаганда.

Шаянлык начар икән,
Бозыклык басар икән.
Ата-ана каргашлары
Бик мәгкуль ясар икән.

Көн дә эзли безне әнкәй
Уенга чыккан җирдин.
Каргашып эзли бердин,
Тиргәшеп эзли бездин.

Әтекәй иртә торды,
Өендә кошлар күрде.
«Болар нинди кошлар?» – диеп,
Хәйранга калып торды.

Әнекәй белде ахырын
Балалар кош булганын.
Әтекәйгә сөйләп бирде
Рәнҗеп дога кылганын.

Йөрибез өйдә очып,
Кош булып канат кагып,
Сахраларга очар идек –
Булмый бит ишек ачып.

Әнекәебез үкенәдер
Баласыз калганына.
Яшь белән каннар түгәдер
Тиешсез каргавына.

Балалар дәртен күргән,
Адашып читтә йөргән
Адәмнәргә гыйбрәт бу хәл –
Укысын күзе күргән.

*1964 елда Балтач районы Сәйтәк авылында*
*Талига Хаҗиевадан (1888 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 268. Икенче бәет

Икәү сугыштык кимерчәк өчен,
Әнкәй каргады бер дә юк өчен.

Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без,
Бу дөньялардан гыйбрәт кылдык без.

Әткәбез калды безнең мәчеттә,
Без тилмерәбез икебез читтә.

Бардым урманга, җиләкләр пешкәч,
Әнкәй җыглыйдыр исенә төшкәч.

Төшкәндер безгә әнкәй каргышы,
Үземез туганчы тәкъдир язмышы.

Су буйларында дингез камышы,
Кара урманда Сак-Сок тавышы.

Бардым урманга, җыйдым карлыган,
Без ятимнәрне әнкәй каргаган.

Чыктым басуга, урак урырга,
Ходай язгандыр шулай булырга.

Яңгыр явадыр, әнкәй, башыңа,
Җыглап килдек без әнкәй каршына.

Каргады безне газиз әнкәбез,
Фани дөньяны күрми китәбез.

Әнкәй токмачны үзеңә күп иттең,
Әткәй кайтканчы, безне юк иттең.

Әткәй тиргәде: «Өйдә торсын!» – дип,
Әнкәй каргады: «Сак-Сок булсын!» – дип.

Әнкәй җыглыйдыр: «Ник каргадым?» – дип,
Сак-Сок йөридер: «Харап булдык», – дип.

Бардык урманга, кистек пар каен,
Сагына әнкәем безне көн саен.

Кистем пар нарат яңи избага,
Ике күземнән канлы яшь ага .

Җокыга киткәч, бер төш күрдем мин,
Җалан-кырларда җалгыз йөрдем мин.

Имезгән сөтеңә, әнкәй, түзәсең,
Кыямәт көндә бәхил буласың.

Су буйларында бала үрдәкләр,
Искә төшкәндә, өзелә үзәкләр.

Алты яшьләрдә бергә йөрдек без,
Җиде яшьләрдә Сак-Сок булдык без.

Кыйбла ягыннан җилләр исәдер,
Безнең өметне әнкәй кисәдер.

Ишек алдыңда җиктем кар(а) атлар,
Әнкәй каргагач, яралды канатлар.

Булай булдык без каргыш төшкәнгә,
Җыглама, әнкәй, Ходай кушканга.

Бик күп җыгласаң, китапка кара,
Безне уйласаң, Сак-Сокка кара.

Китап укырсың, гыйбрәт алырсың,
Кошлар очканда карап калырсың.

Сиңа, әнкәем, бер сүз әйтмәем,
Бәхиллек бирче, өйгә кайтаек.

Бер җыл тулганчы кайтабыз, дидек без,
Бер жыл тулгачтан өмет өздек без.

Әнкәй каргады, әткәй, белдеңме?
Турыңдин уздым, әнкәй, күрдеңме?

Җыйган җиләгем калды яртысы,
Ике баламның калмады берсе.

Калган күлмәгем, бер дә кимәдем,
Очып киткәндә: «Сау бул!» – димәдем.

Мамык эшләпә җилгә очырдым –
Ике балаңны каргап очырдың.

Бала үрдәкләр сулар буенда,
Сак-Сок булыр, дип, кемнәр уенда?

*Бәетнең югарыда китерелгән тулы вариантын*
*1977 елда Борай районы Яңа Тазлар авылында*
*Мәтыйга Хәбибрахман кызы Шәяхмәтовадан (1898 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Аерым өзекләр БДУ студентлары тарафыннан Яңа Тазлар авылында*
*Бибиха Мусинадан (1911 елгы), Бустанай авылында*
*Гөлҗамал Әхмәлетдин кызы Әхмәлетдиновадан (1914 елгы),*
*Абдулла авылында Хөсникамал Низаметдиновадан (1910 елгы)*
*язып алынган*

## ХӘРБИ-ТАРИХИ БӘЕТЛӘР

### 269. Миңнулла бәете

Наполеон әйтә икән,
Минем теләгем, диеп.
Башка җирнең җир-сулары –
Илгә бүләгем, диеп.

Әй, Наполеон, мәкерле җан,
Явыз икән теләгең.
Кан койдыру, яшь түктерү,
Шулмы илгә теләвең?

Французны кызыктырган,
Россиянең маллары.
Шул малларны талар өчен
Басып керде яулары.

Шул яуларны туздырырга,
Китте безнең Миңнулла.
Иле өчен көрәшләрдә
Ул газиз башын сала.

Туган ил өчен көрәшсәң,
Батырлык үзе туа.
Күп батырлыклар күрсәтте
Безнең авыл Миңнулла.

Миңнулланың балалары
Әтиләрен көттеләр.
Газиз әткәбез кайтыр, дип,
Ихлас өмет иттеләр.

Әй, балалар, көтмәгез сез,
Әткәгез бит юк инде.
Олы көрәш юлларында
Ул вафат булды инде.

Явыз патшалар булмаса,
Сугыш та булмас иде.
Иң кадерле газиз башлар,
Һәлак та булмас иде.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Калмаш авылында*
*Фәрдәнә Әхмәтшинадан (1914 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 270. Герман сугышы бәете

Менә инде күр аларны,
Нинди явыз һәм зәһәр.
Булдыра алмас усаллыкны
Шайтаның да бу кадәр.

Нимесләрнең кораллары,
Бар да яңа системда.
Алар тубы шундый зәһәр:
Атканда җир селкенә.

Мылтыклары яңа форма,
Бик ерактан алдыра.
Пулеметлары ядрәле,
Яңгыр кебек яудыра.

Безнең гаскәр, аларны күргәч,
Ата, ди, башларына.
Явызлар да буш куймыйлар,
Ата да башладылар.

Нимесләрнең солдатлары
Аю кебек тазалар.
Шулай да безнең гаскәрне
Җиңә алмый качалар.

Нимесләр Варшау буена
Йөзләп, меңләп баралар.
Бер-ике көн сугышкачтын,
Бик аз булып калалар.

Нимесләрнең атлары күп –
Бар(ы)сын парлап җиккәннәр.
Безнекеләр кызу бәргәч,
Кире борылып чиккәннәр.

Алар анда безнең җиргә
Яхшы гына керделәр.
Безнең гаскәрләр аларның
Кирәкләрен бирделәр.

Солдатлары үлгәнгә дә,
Карамыйча керәләр.
Машина белән чокыр казып,
Үлеләрне күмәләр.

Чокыр казыр өчен, алар
Ясаганнар машина.
Шушы машиналар белән
Җитәләр адәм башына.

Германиянең гаскәре
Меңләп-меңләп үләдер.
Мең үлекне машиналар
Бер сәгатьтә күмәдер.

Үлеп кенә котылмаслар,
Туры килер түләргә.
Арт сабагын укыттык без
Алар кебек юләргә.

Шулай итеп, нимесләр дә
Ул урыннан чиккәннәр.
Бакчалардан бәрәңгене
Алып, төяп киткәннәр.

Бу Германия патшасы,
Әллә инде котырды.
Дәрәҗәсен белмәенчә,
Россиягә тотынды.

Австрия уйламыйча
Җәфа алды үзенә.
Чынлап торып ышанган, ди,
Шул юләрнең сүзенә.

Күп вакытлар котыла алмас
Бу сугышның чиреннән.
Өстәвенә колак какты
Ни кадерле җиреннән.

Безнең Россия никадәр
Җирне үзенә караткан.
Батырлыгын, көчен, данын,
Җир йөзенә тараткан.

Күп тә үтми аларның
Гаскәрләре туздылар.
Пулемет һәм тупларны
Руслар таптап уздылар.

Нимесләрнең кораллары
Бик ерактан алалар.
Галисия җирләрендә
Тездән каннар агалар.

Солдат йөри кырларда,
Ачы җилле буранда.
Солдатка бик кыен була,
Авыр мәҗрүк булганда.

Бу хәлләрне күрсәгез,
Агар иде яшегез.
Өстебездән туплар оча,
Калырмы икән башыбыз?

Варшау каласы янында
Күтәрелде зур тавыш.
Галисия кырларында
Ун көн булды зур сугыш.

Шулай итеп ул якларда
Бик күп алга киттек без.
Дошман гаскәрләрен таптап,
Карпат тавын үттек без.

Ачы суык бураннарда
Итекләрем шакылдый.
Көне-төне колагымда
Туп тавышы шаркылдый.

Яргалады аягымны
Галисия ташлыклары.
«Озакламый җиңәрбез», – дип,
Куандыра башлыклары.

Гөр-гөр итеп торадыр
Туп тавышы колакта.
Офисерлар кычкыргач
Карыйбыз без флагка.

Без барабыз мылтыкларны
Иңебезгә күтәреп.
Вафат булсак кылыгызчы
Догалар, кул күтәреп.

*1970 елда Чакмагыш районы Тозлыкуш авылында*
*Савия Фәтхетдиновадан*
*БДУ студентлары язып алган*

### 271. Аерылу бәете

Безне сугышка чакырып,
Хәбәр килде патшадан.
Шул ук көнне чыгып киттек,
Торып калмый башкадан.

Без сугышка китәбез,
Туган илне сакларга,
Күз күрмәгән урыннарга,
Еракка, чит якларга.

Ике күздән яшь килде
Туган илдән киткәндә.
Атаң-анаң, балаң, хатын:
«Сау бул», – диеп әйткәндә.

Безгә каршы сугыш ачкан
Немецларның патшасы.
Сугышырга җитмәс аның
Гаскәр белән акчасы.

Чуен белән ялгангандыр
Бара торган юлыбыз.
Исән кайтсак – күрешербез,
Үлсәк – бәхил булыгыз.

Без китәбез бу илдән,
Аерылып нечкә билдән.
Бездән сәлам көтәрсез
Ашкынып искән җилдән.

Сугышларга керербез,
Арыслandай йөрербез.
Ходай тәкъдиргә ни язса,
Шуны без дә күрербез.

Көн болытлы, төн караңгы,
Кич булмагач, ай да юк.
Аерылырга язган икән,
Җылашудан файда юк.

*2002 елда Илеш районы Исәмәт авылында*
*Зинфира Мансуровадан БДУ студенты*
*Альмира Хәйретдинова язып алган*

## 272. Сугыш бәете

Аяныч хәлем, янадыр бәгърем, һич юк өметем, котгаргыл үзең.
Төштем гөгүбәткә, нихәл итмәккә, тоткылык каты, хәл юк китмәккә.

Ерак илләрем, ялгызмын үзем, күрмидер күзем, раббым, бир түзем.
Гыйззәтле атам, шәфкатьле анам, мин кайчан кайтам – белмисең үзең.

Исәнбез монда, ятлар кулында, Ватан юлында корбан бул, җаным.
Чит-ят җирләрдә, дошман илләрдә, тамар туфракка соң тамчы каным.

Ялгыз бу башым, юк шул юлдашым. Туган илләрем, ямьле кырларым,
Яшел урманнар, йөргән җирләрем, күрмимен сезне, ябык юлларым.

Кайда иптәшем, якын сердәшем, сезләрне сагынып түгелә күз яшем.
Көннәрем төндәй, кояшсыз үтә,ниләр күрәчәк бу газиз башым?

*1977 елда Борай районы Яңа Тазлар авылында*
*Саимә Гыйльфановадан (1911 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 273. Әфган сугышы бәете

Әфганстан – йөрәк ярасы,
Әрнүләрнең юктыр чамасы.
Ят җирләрдә һәлак булдык бит без –
Татар, башкорт, урыс баласы.

Туган илебезгә исән кайтсак,
Җирне үбәр идек һәммәбез.
Чит җирләрдә чыкты җаннарыбыз,
Табутларда кайтты гәүдәбез.

Безне көтә газиз ата-ана,
Тәпи баскан изге җиребез.
Ни хәл итик, безне озатты бит
Еракларга туган илебез.

Ил кушканны без үтәргә хаклы,
Безгә башка чара калмаган.
Кыска гомер, ят җирләрдә үлү –
Әмер шулай булган Алладан.

Ятим калды безнең сөйгән ярлар,
Алтын балдакларны кимәдек.
Үзебезнең ул һәм кызларыбызны
Кочакларга алып сөймәдек.

Иген басулары безне көтте,
Безне көтте уку йортлары.
Әткәй, әнкәй, туган-тумачалар
Сүндермәде көтеп утларны.

Тик югалткан кеше баласын
Татый кайгыларның ачысын.
Маңгайларда шушы язмыш булгач,
Күрәчәктән кая качасың.

Илкәебез, әткәй-әнкәйләрне
Без назлаган кебек назлачы.
И, Ходаем, яп-яшь егетләрне
Бу дөньядан иртә алмачы.

Илдә туа, яуда үлә диләр,
Ир-егетләр яуда үлмәсен.
Безнең язмыш ачы. Килер буын
Без күргәнне берүк күрмәсен.

*2002 елда Илеш районы Дөмәй авылында*
*Җәннәт Шакировадан БДУ студенты*
*Альмира Хәйретдинова язып алган*

## 274. Чечен сугышы бәете

*Бу бәет Чечня җирендәге канлы бәрелешләрдә башын салган авылдашыбыз Фирдәвис Галихан улы Бәләгытдиновның истәлегенә багышланган.*

Кышкы салкын көннәрдә,
Ике меңенче елларда,
Гомеремне кистеләр,
Утызынчы гыйнварда.

Усал снайпер кулларында,
Автомат «тел»гә килде,
Ул атудан яраландым,
Тәннәрем телгәләнде.

Чечен иленә киткән чакта,
Үләсемне белмәдем.
Әҗәл җитеп, үлеп киттем –
Туганнарны күрмәдем.

Кичен җырлап йөри идем,
Көнтүгеш авылында,
Гомеремне кистеләр шул
Грозный давылында.

Уйнап үскән авылым,
Печән чапкан җирләрем,
Үзем үлдем, күкрәп калды
Туган-үскән илләрем.

Әнкәй, ашың пешеп җиткәч,
Балаларың җыелыр.
Алар булып, мин булмагач,
Кайнар яшең коелыр.

Зиратларда сайрап торган
Мин яраткан кош булыр.
Чәй эчәргә утырырсыз,
Минем урыным буш булыр.

Машиналар кызу бара,
Төягәннәр ташкүмер.
Егерме сигез яшькә җиткәч,
Өрәм булды яшь гомер.

Сөйгән кызым, урамнарда
Сулап йөр син саф һава,
Төрле чакларым булгандыр,
Бәхиллә, кыен булса да.

Май бәйрәме, Сабантуйга
Кайтырмын, дигән идем, –
Челпәрмә килделәр шул
Уй-хыялларым минем.

Грозныйны яулаганда,
Бик каты яраландым,
Хәрби госпитальләрдә
Соң сулышымны алдым.

Табутым кайтты авылга
Кырык җиде көннән генә.
Ходай ярдәм бирә күрсен
Мине үстергән әнигә.

Альберт энем, синең белән
Бергә китәргә йөрдем,
Ярый әле, син бармадың,
Калуыңны хуп күрдең.

Сабан туе көннәрендә
Җыелыр халык бәйрәмгә.
Дуслар, мине искә алың,
Җыелышкан мәлләрдә.

Шамил, Рөстәм, Илүсә,
Онытмагыз мине дә –
Ак бәхетләр теләп калам,
Сабакташларым, сезгә.

Ах, дусларым, түзегез,
Түкмәгез яшегезне,
Инде мәңге күрә алмассыз,
Якын иптәшегезне.

Альберт, Салават, әткәй, әнкәй,
Йөзләремне күрегез,
Мин үлгәнгә борчылмагыз,
Матур тормыш корыгыз.

Уралып-уралып ага шул,
Мата елга сулары.
Гомерлеккә калды миннән
Көнтүгеш басулары.

Миннән калган киемнәрне
Туганнарым кисеннәр,
«Илдәге тынычлык өчен
Корбан булды», – дисеннәр.

Көнтүгешнең урамнары
Ике яктан канаулы,
Сугыш афәтен чыгарганның
Көне булсын санаулы.

* * *

Кыр казлары йөзеп йөри,
Төнбоеклы күлләрдә.
Көнтүгешне кайгы басты
Фирдәвис үлгән көннәрдә.

Клубларда, бөтен җирдә,
Калды эшләрең синең.
Алтын куллы авылдашым,
Оҗмахта урының синең.

Кояш ныграк балкый иде,
Син урам йөргән чакта.
Мәңге оныта алмабыз,
Без сине югалтсак та.

Зәкия апа, Галихан абый,
Кайгыгыз күтәргесез,
Ярагызны кузгатканга
Гафу итә күрегез.

*2019 елда Балтач районы Көнтүгеш авылында*
*китапханә мөдире Асия Мостафинадан*
*«Балтач таңнары» гәзите хезмәткәре*
*Аида Хәйретдинова язып алган*

## СОЦИАЛЬ-ИҖТИМАГЫЙ БӘЕТЛӘР

### 275. Манара бәете

*(Авылдагы мәчет манарасын кисү уңае белән язылган)*

И, манара, синең аең ераклардан ялтырый,
Син, манара, ауган чакта бөтен дөнья калтырый.

«Манараны кисәләр», – дип, бөтен халык җыелды,
Җир йөзенә фирештәләр саф-саф булып тезелде.

Манара әйтә: «Кисәләр бит, авам инде, тотыгыз!
Өметләрем – һәр барчагыз, әй, догалар укыгыз.

Манарада ай да урак: «Авам!» – диеп дулкынлый,
Һаваларда ай да кояш, йолдызлар – бар да елый.

Манараның тирәзәсе бар да җиргә коелды,
Фирештәләр, канат җәеп, саф-саф булып җыелды.

Борма-борма баскычларны алып-алып куйдылар,
Җир йөзенә фирештәләр саф-саф булып кундылар.

Һавада болыт булмаса, җилләр дә исмәс иде
Ходайдан әмер булмаса, алар да тимәс иде.

Манараны кисү белән, авылның яме бетте,
«И Аллаһы рәҗуан», – дип, манара авып төште.

И манара, син булмагач, авылларда ямь бетте,
Саклап кала алмаганга, манара рәнҗеп китте.

Мәчет әйтә: «Актык сулуым: артык ашыгып сүтмәгез,
Минем кырдан узган чакта дога кылмый үтмәгез.

Манараны да, мәчетне дә сагынасызмы, мөэминнәр?
Азан да юк, намаз да юк, зәгыйфьләнде бит диннәр.

И манара, синең аең каршы иде кыйблага,
Ничә еллар зекер тәсбих әйткән идек Аллага.

И, манара, исемеңне бигрәк матур кушканнар,
Бәлки, телгә килгән булсаң, куркыр иде дошманнар.

И, манара, син үзең дә кем кискәнен белмәдең,
Бер Ходайдан әмер булып ничек телгә килмәдең?

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Шәмсинур Гыйззәтуллинадан (1906 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 276. Мирсәет бәете

Мин җырлыймын, сез тыңлагыз,
Бу – «Мирсәет бәете».
«Мирсәет үтерелгән», – дигән сүз
Илләр буенча китте.

Башкаема суккан чакта,
Тетрәп китте кулларым,
Дошман кулыннан үткәнне
Белмәде туганнарым.

Казарманың буйларына
Мылтыгымны сөядем.
Туган-үскән авылыма
Кайтты канлы сөягем.

Аяз көнне яшен сукты
Әгерюенең юлларын.
Мине үтергән кулакның
Сындырыгыз кулларын.

Аклы ситса күлмәгемнең
Бизәкләре беткәндер.
«Кызылармееци улым кайтыр», –
Диеп, әнием көткәндер.

Казармада торган чакта,
Тәмле ашлар ашадым,
Гөлчәчәктәй яшьлегемне
Кулак мәлгунь ашады.

Сезгә бүләкләрем булыр
Чемоданым эчендә.
Ике ел җыйган гыйлемлек
Бар да китте эчемдә.

Дүшәмбе көн сәгать биштә
Үттем авыл башыннан.
Артка борылып караган идем,
Каннар акты башымнан.

Ташкентлардан чыккан чакта
Ашамадым ашымны,
Шушы авылны чыккан чакта
Ашадылар башымны.

Йокларга ята идем мин
Аклы күлмәкләр белән.
Газиз җанымны алдылар
Имән күсәкләр белән.

Миннән калган киемнәрне
Иптәшләрем кисеннәр:
«Совет власте өчен ул
Корбан булды», – дисеннәр.

*1970 елда Чакмагыш районы Калмаш авылында*
*Мәһүбә Хәсәновадан (1901 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 277. Сәхәб бәете

Без әйтәбез, сез тыңлагыз –
Сабый бала бәете.
Язгы сулар аккан чакта
Чыга Сәхәб мәете.

Сүс чыбыркы каты шартлый
Безнең Сәхәб кулында.
Елый-елый кече яшьтән
Көтү көтте болында.

Ул ачлыктан котылуны
Мәктәпләрдән эзләде.
Мәүлет хәлфә суккан чакта,
Түзәлми хәлсезләнде.

Таң аткач та, алтыга
Сәхәб мәктәпкә килде.
Каеш камчыга чыдамый,
Гәүдәсе кара көйде.

Сабый бала аркасыннан
Ташынып каннар акты.
«Кыйнама!» – дип әйтә алмый,
Ахырда телсез калды.

Елан төсле бөгелә-сыгыла
Мәүлет хәлфә камчысы.
Сәхәб кыйналган идәннән
Кипми каннар тамчысы.

Нури апаның Сәхәбе
Елый урам чатында.
Яшьли мескен харап булды
Мәүлет хәлфә катында.

Нури апа кич утыра
Сукыр лампасы белән.
Нурлы йөзләре саргайды
Сәхәб кайгысы белән.

*1970 елда Чакмагыш районы Таш-Калмаш авылында*
*Гыйльминур Бадамшинадан (1885 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 278. Ачлык чире бәете

*1944 елны, сугыш вакытында, халык бик ачыкты һәм, көз көне җыелмый калган арыш башагын ашап, бик күп кеше агуланды, үлде. Бик күп өйләр йозакка бикләнде.*

Кырык дүртенче елны
Бик күп кырылды халык.
Бу әкият, ялган түгел
Барысы да чынбарлык.

Агуланган кешеләрне
Күрсәң – исең китмәле.
Дүрт-биш көн эчендә бик күп,
Бик күп өйләр бикләнде.

Алтмыш өйле бер авылда
Кырыклап кеше үлде.
Көн саен дүрт-биш мәетне
Исән кешеләр күмде.

Агуланып үлгәннәрне
Хәзер кемнәр исәпләр?
Әнә шундый авырлыкта
Үтте безнең яшь чаклар.

Иртән чирли баласы –
Тамаклардан кан килә.
Ә кичен чирли анасы –
Танаудан да кан килә.

Без дә ятим ул вакытта –
Ни эшләргә белмибез.
Хәзерге яшь кешеләрнең
Төшенә дә кермибез.

Өйдә бер кеше чирләсә,
Өйдә беркем калмады.
Үлем канатларын җәеп,
Безне кайгы ялмады.

Кан чиреннән үлеп бетте
Әбисе дә, бабасы.
Ул вакытның һич төзәлмәс
Йөрәкләрдә ярасы.

Безнең Базы суы әче,
Үрчетеп булмый балык.
Сугышта кеше кырылды,
Авылда үлде халык.

Сугышлардан бик тиз килми
Әтиләрдән хатлар да.
Менә шулай авыр булды
Без бәләкәй чакларда.

Ул чирдән беркем котылмый,
Беркем котылмый качып.
Мәетләргә кәфен дә юк,
Тормыйлар өстен ачып.

Танавыннан каны ага,
Чыдап булмый исенә –
Чирле кеше үрсәләнә
Керер янган мичеңә.

Гөлләремә су сибегез,
Гөлләрне корытмагыз.
Сулар агар, еллар үтәр,
Сез безне онытмагыз!

Йөгерәбез, су буенда
Аякны кисә камыш.
Кешеләр үлә сугышта,
Авылда – ачы язмыш.

Үлгән кешенең яныннан
Һичкенә дә китмәйбез.
Үзебез дә үлмәс өчен,
Чәчкән борчак чүпләйбез.

Үлгәннәр кабере яныннан
Үтәбез башны иеп, –
Исән чакта җир сөрделәр,
Сауган сыерны җигеп.

«Сыерыңны җик!» – дип куша
Яшенә дә картына.
Тырма тартып, без йөрибез
Әниләрнең артыннан.

Сабан сөреп, тырма тартып,
Без яшәргә тырыштык.
И Ходаем, илгә-көнгә
Бирсәң иде тынычлык.

*2002 елда Илеш районы Кадер авылында*
*Фәнүзә Гыйльвановадан БДУ студенты*
*Альмира Хәйретдинова язып алган*

## 279. Төрмә бәете

Минем гомеремнең сулары
Боргалана, комлана.
Менә шундый хәлләр булды
Түтәй белән торганда.

Ачлык вакыт – бер заманны
Киттек арыш башына.
Ярты кило башак җитте
Минем газиз башыма.

Ярты кило башагымны
Үлчәп алып калдылар.
Бүрек кадәр йозак белән
Мине бикләп салдылар.

Кемнәр уйлап йөргән инде
Мөгаллимә хәйләсен?
Мин бер ятим инде хәзер –
Мине кемнәр җәлләсен?

Ул төрмәнең тәрәзәсе
Бигерәк тә тар икән .
Унөч яшьтә төрмәләрдә
Күрәчәгем бер икән.

Комендантлар килеп керсә,
Без торабыз шикләнеп.
Иптәшләрем уйнап йөри,
Ә мин ятам бикләнеп.

Комендантлар килеп керсә,
Без утырган бүлмәгә –
Минем анда күргәннәрне
Сөйләмим беркемгә дә.

Мөгаллимә дигән карчык
Килеп чыкты каршыма
Ярты кило башак өчен
Җитте минем башыма.

Унөч яшьтә әсир булдым,
Әллә дөнья тар микән?
Мин анда да интекмәдем,
Аллакаем бар икән.

Мин анда да миһербанлы
Кешеләр барын белдем.
Ипи ашап, рәхәтләнеп,
Йөгереп уйнап йөрдем.

Ипи ашаган баланың
Тамаккае тук икән.
Исемә төшсә өзгәләнеп,
Кайтыр җирем юк икән.

Шулай итеп көннәр үтте –
Вакыт җитте кайтырга.
Никадәрле еласам да,
Беркем юк юатырга.

Беркемгә дә күрсәтмәсен,
Төрмәләрнең бүлмәсен.
Мин күргән ул нужаларны
Бер кеше дә күрмәсен!

*2002 елда Илеш районы Кадер авылында*
*Фәнүзә Гыйльвановадан БДУ студенты*
*Альмира Хәйретдинова язып алган*

## ХАТЫН-КЫЗНЫҢ МИХНӘТЛЕ ЯЗМЫШЫ ТУРЫНДАГЫ БӘЕТЛӘР

### 280. Гайшә бәете

Үсеп җиттем мин буйга –
Әнкәй килгән бер уйга.
Озакламый туй булды,
Өйгә кодалар тулды.

Шулай итеп, яшь башым,
Килен дә булып китте.
Кемгә төшәр күз яшем,
Берничә ел торгачтан?

Ирем яшь кәләш алды,
Миңа көн дә калмады.
Башым кайгыга калды,
Ирем, тыңлачы әле:

– Зөләйхаң да артык түгел,
Кардин ап-ак тоттым мин.
Син никадәр җәфа кылсаң,
Һәммәсен дә йоттым мин.

Матурлыгым, зифалыгым –
Бары да инде җиремдә.
Ни кушсаң да эшли идем,
Калдырмадым берен дә.

Балаларым яхшы кара,
Ертык-тишек булмасын.
Ятим булып моңаймасын,
Күңелләре тулмасын.

Ир булсагыз, урыныгызда
Игътибарлы булыгыз.
Хатын-кызны хурламагыз,
Алар түгел колыгыз.

Хатын-кызның күңеле нечкә,
Тиз кырыла, өзелә.
Хатын-кызны яхшы тотсаң,
Шунда дөнья төзелә.

Балаларым-чагаларым,
Калдыгыз бит ятим сез.
Әнкәгезне сагынганда,
Белмим инде, нишләрсез.

Балаларым-чагаларым,
Калдырамын сезләрне.
Туганнарга бер сөйләрсез,
Искә алып безләрне.

Дөнья мине мәҗбүр итте
Теләп үлем алырга,
Кунак булып барып килдем
Әниләрем янына.

Дөнья мине дошман күрде,
Җафа салды башыма.
Алып китте, җиткермәде
Егерме биш яшемә.

«Үлем яхшырактыр, – дидем, –
Яшәүдән эт көнендә».
Үзем илтеп, башым салдым
Кабан күле төбенә.

*1970 елда Чакмагыш районы Үрнәк авылында*
*Гайшә Миңнегалиевадан (1904 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 281. Комсомолка кыз бәете

Кайдадыр шунда, татар авылында,
Очрадым менә бер туйга.
Туй уйнаганда, кыз җылаганда,
Аптырап калдым бер уйга.

Кызның җылавын шуннан беләмен:
Көчләп бирәләр бер карт байга.
«Бирмәгез мине, бирсәң дә бармыйм,
Барам яшь комсомол малайга!»

«Кызым, барырсың, барып кабарсың,
Теләгән кадәр мәһәр алырсың.
Яхшы атларда, ефәк капларда
Кунак булып безгә кайтырсы».

Ишек ачылды, халык чәчелде,
Һәм мулла керде никах укырга,
Мулланы күргәч, йөрәк яньчелде,
Асылындым әнкәй муенына.

Ишекне ачып: «Кайтабыз, – дидем, –
Җигегез, – дидем, – туры атымны».
Атларны җиктек, без качып киттек,
Байны калдырып мулла янында.

Бай әйткән, диләр: «Шушы оятсыз
Пычратты, – диеп, – изге атымны.
Шулдыр мәлгуньнәр, яшь комсомоллар
Урлады, – диеп, – минем хатынны».

*1970 елда Чакмагыш районы Үрнәк авылында*
*Кәримә Фәйзуллинадан (1920 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 282. Фәрүзә кыз бәете

Урамда җырымны, әй, җырлыйлар,
Дусларым колак салып тыңлыйлар.
Дусларым колак салып, әй, тыңлыйлар,
Фәрүзәне җәлләп җылыйлар.

Нигә тудым дөньяга кыз булып,
Ник акмадым дәрьяга боз булып?

Шыбрай гына шыбрай яңгыр яуса иде,
Җир йөзләрен яңгыр алса иде.
Бирде генә эткәем сөймәс ярга,
Бер Ходаем ярдәмен салса иде.

Мәһәр итеп алган туры атны
Бәйләдең, этием, багана төбенә.
Бирмәдең, этием, үз тиңемә,
Бирдең картка, адәм кименә.

Әтием башымны бәйләдең
Сөйгән егетемә жәлләдең.

Иртә беләп торып тышка чыксам,
Җилләр исә урам буена.
Бирдең, этием, сөймәс ярга,
Сөйгәнемне чакырыйк туема.

Нигә тудым дөньяга кыз булып,
Ник акмадым дәрьяга боз булып?

Урам буйларыннан ярыш узды,
Әле дә үкенәм: чыгып бакмадым.
Бу да дөньяларда мин янамын,
Нигә суга, утырып, акмадым?

Бәйләдең, этием, башымны,
Кая итәргә канлы күз яшемне?

Биек тау башына менә-менә,
Аякларым талды арудан.
Адәм актыгына биреп, мине
Аердылар сөйгән ярымнан.

Урам уртасында, ай, баткаклык,
Батамын да шунда, калкамын.
Янымдагы сөйсә, күңелем булмый,
Чарасыз җан гына ятамын.

Нигә тудым дөньяга кыз булып,
Ник акмадым дәрьяга боз булып?

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Калмаш авылында*
*Рәхимә Ибраһимовадан (1890 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## ШӘХСИ ФАҖИГАЛӘР ТУРЫНДАГЫ БӘЕТЛӘР

### 283. Хәлимә әби бәете

Баламнан күргән хурлыктан
«Бисмиллаһ» дип башладым –
Алтмыш сигез яшькә җиткәч,
Җыру яза башладым.

Анасына кем кул суза –
Бу бигрәк гыйбрәт.
Үзәгемә үткәннән соң,
Мин чыгардым мөнәҗәт.

Ачуланып типкәләдең –
Кара күмер тәннәрем.
Үзеңә дә кайтыр, балам,
Миңа күрсәткәннәрең.

Исән чакларымда йөрдем
Кеше типкеләрендә.
Балакаем риза түгел
Имезгән сөтләремә.

Мин чирләгәч, алып кайтып,
Тавыкханәгә яптың.
Ничә еллар шул «ханә»дә
Берүзем, ялгыз яттым.

Чыгам, дип, ишеккә барсам,
Түшемә тибә идең,
Эткә биргәндәй икмәкне
Ваткалап бирә идең.

Хәл белергә кеше килсә,
Аңа мине хурладың.
Ике балаңны үстердем –
Кадеремне белмәдең.

«Мәңге үләсең юк!» – диеп
Кычкырдың бит, балам, син.
– Ник акырасың, син? – диеп,
Башларымны ярдың син.

Балакаем, минем белән
Вәхшиләрчә уйнадың.
Анам минем кулларымда
Мәңге торыр, дип уйладың.

Мине зинданннарга салдың
Картайган көннәремдә.
Йөрерсең әле син дә шулай
Картайган көннәреңдә.

Картлык күңелсез киләсен
Алдан сизмәде күңел.
Баламнан күргән хурлыклар
Язып бетәрлек түгел.

Авыз ачып сөйләшергә
Ирек бирмәдең, балам.
Синең кулларыңа калгач
Хокуксыз булды анаң.

Куаладың, типкәләдең –
Һаман сине эзләдем.
Актык минутларымда да
Балам, сине эзләдем.

Имезгән күкрәк сөтемне
Ахирәттә түләрсең.
Балам, каргышым төшкәчтен,
Кемгә үкенеп сөйләрсең?

Тиздән мәңгелек йортына
Китәр газиз әңкәең.
«Әнкәй, ничек ятасың? – дип,
Сорамадың хәлкәем.

Киленкәем, сиңа кала
Миңа ясаган тар бүлмә.
Миңа күрсәткән хурлыкны
Син дә күрмичә үлмә!

Исән чакларымда минем
Булмады кадерләрем.
Мин үлгәч тә, каберләрем
Булмасын рәшәткәле.

*2002 елда Илеш районы Исәмәт авылында*
*Луция Сәлаховадан БДУ студенты*
*Альмира Хәйретдинова язып алган*

## 284. Яхъя бәете

Әнкәй мине тапкачтын да
Ак биләүгә биләгән.
Ак биләүгә биләгән:
«Гомерең булсын», – димәгән.

Бик бәләкәй чакларымда
Ятим калдым әткәйдән.
Әткәй үлгәч, күп тә тормый
Вафат булды әнкәй дә.

Шулай итеп ятим калдым
Яшь чагымда әткәйдән.
Әнкәй үлгәч, үстем инде
Бер ятим әбекәйдә.

Әбекәй белән икәү генә
Тора идек бер өйдә.
Бу өйләрдә яшәгәндә
Уйламадым берни дә.

Кырык җиденең июнь аенда
Көннәр җылы һәм аяз.
Төннәре дә шул ук инде:
Дымлы, җылы һәм аяз.

Шундый көннәрнең берсендә
Уйладым мин барырга,
Сәкәм дигән зур авылның
Данлыклы базарына.

«Базарларга барам», – дигәч,
Әбекәй әйтә: «Барма», – дип.
Их, әбекәй, шул чагында
Эчләрең сиздемени?

Сызылып таңнар аткан чакта
Чыгып киттем берүзем.
Базарларга барам, диеп,
Ашыгып барам үзем.

Авыллардан чыккан чакта,
Бер кеше дә тапмадым.
Инде хәзер ялгыз башым
Юлдан бара башладым.

Сызылып таңнар аткан чакта,
Кара урман күренә.
Күңелләрем сизгән кебек,
Авыр бару үземә.

Авылга да ерак түгел,
Кара урман күренә.
Урман авызына кергәч,
Күпере дә беленә.

Бара торгач барып җитәм
Шушы күпер янына.
Сандугачлар сайрашалар
Минем тирә-ягымда.

Күпердән дә чыгып киттем,
Таудан менә башладым.
Эчкәйләрем сизгән кебек
Уйлар уйлый башладым.

Инде хәзер таудан менәм,
Карыйм тирә-ягыма:
Бернәрсә дә күренми шул
Инде минем янымда.

Тауга менеп җиткәчтен дә
Сала юлы тар кебек.
Хәзер инде бу тирәдә
Шикле кеше бар кебек.

Таудан-тауга менү белән
Кызу бара башладым,
Бөтен тәнем калтыранып,
Әллә нишли башладым.

Сала юлыннан барганда,
Карадым мин сул якка.
Ни күзләрем белән күрим,
Бер кеше бар шул якта!

Күрү белән шушы кеше
Миңа килә башлады.
Аякларым калтырана,
Атлый алмый башладым.

Сызылып таңнар аткан чакта
Атлый бу миңа таба.
Алып китте йөзе кара
Мине урманга таба.

Бу кеше килеп тоткачтын
Нишләргә дә белмимен.
Тирә-ягыма каранам:
Үземә ярдәм эзлимен.

Урман эченә кергәч тә
Карыйм агач башына.
Инде хәзер шушы кеше
Җитәр минем башыма.

Кинжаллары ялтырый,
Бөтен тәнем калтырый.
Бер урысча, бер татарча
Бу миннән нидер сорый.

Бу урманның эчләрендә
Кискәннәр каен башын.
Бу кешенең кулында
Бетәдер минем башым.

Кинжал белән кизәнә,
Минем тәнем чиркана.
Ничек кулы барды микән –
Китереп тыкты җилкәмә.

Кинжал салкынын сизгәч тә
Башым түбән иелде
Өстемдәге күлмәкләрем
Кара канга күмелде.

Башыма казаган чакта,
Тотып алдым кинжалын.
Кинжалларын тоткан чакта,
Өзелде бармакларым.

Тауны менеп җиткәчтен дә
Карыйм авылга таба.
Башкаема кинжал тыккач,
Кан тамырларым ага.

Җилкәләрем сызлап аугач,
Җан бирәлми тилмердем.
Янымдагы үләннәрне
Канга буяп бетердем.

Шулай итеп, Яхъяны
Юлга чыккач тотканнар.
Ярты пот ашлыгы өчен
Башына кинжал тыкканнар.

Матур урман буйларыннан
Киләләр гармунчылыр.
Җаннарымны биргән чакта
Булмады ярдәмчеләр.

Базардан кайткан кешеләр
Урманнарга кергәннәр.
Яхъяның канлы гәүдәсен
Алар шунда күргәннәр.

Яхъяның, мескенкәйнең
Күзкәйләре йомылган.
Башкаеның биш җиренә
Кинжал белән тыгылган.

Бу урманның уртасында
Шомырт чәчкә атадыр.
Яхъя, мескен, бөкерәеп,
Кан эчендә ятадыр.

Җилкәсеннән дә суйганнар,
Кулкайларын кискәннәр.
Шулай итеп, Яхъяны
Суеп, үтереп киткәннәр.

Яхъя мескен, үләлмичә,
Башын өстерәп йөргән.
Янындагы үләннәрне
Канга буяп бетергән.

Атасыннан, инәсеннән
Ятим калды бу бала.
Шулай итеп, җәзаланып
Үтерелде бу бала.

Тугыз йөз егерме сигездә
Туган иде бу бала.
Кырык сигезенче елда
Дөньялардан югала.

Кояшкай күтәрелгәндә,
Бу мескенне суйганнар.
Ярты пот ашлыгын ашап,
Ун ел буе торганнар.

Кара урман уртасында
Яхъяны суйганнар.
Каберенә ташлар куеп,
Исемен язып куйганнар.

Яхъя мәрхүм әйбәт иде,
Бик күп эшләр эшләде.
Шулай булулары аның
Төшенә дә кермәде.

Дөньяларда шундый эшләр
Булгалаган ул чакта.
Яхъяны үтергәннәр
Базарга барган чакта.

Бу бәетне укыганда,
Барыгыз да тыңлагыз.
Ялгызыгыз юлга чыгып,
Яхъя кебек булмагыз!

Кара урман эчләренә
Берьялгыз сез кермәгез!
Төнлә ялгыз юлга чыгып
Әрәм була күрмәгез!

*2001 елда Бакалы районы Иске Корыч авылында*
*Сәкинә Сәлимовадан (1921 елгы) БДУ студенты*
*Светлана Гарифуллина язып алган*

## 285. Фәтхерахман бәете

Әй, туганнар, языйм әле,
Үземнең күргәннәрне.
Машина астына калып,
Интегеп үлгәннәрне.

Тарих мең дә тугыз йөздә
Илле бишенче сәнәдә.
Берничә кеше вафат булды
Сәфәр ае эчендә.

Сәйтәк сулары тирәндер,
Тирән җире билдәндер.
Җомга көнне Хәмәт безне
Эшкә алырга килгәндер.

Текәннәргә барган чакта,
Машинага утырдым.
Барган чакта эчем пошты:
«Ник барам?» – дип үкендем.

Тарих бер мең тугыз йөз дә
Илле бишенче сәнәдә
Башларыбызны ашадылар
Җәйнең ямьле көнендә.

Иртән киткән вакытымда
Үләсемне белмәдем.
Әҗәл җитми үлеп киттем,
Туганнарым күрмәдем.

Иртән торып, без ашадик
Актик көнге ашларны.
25 метрлы матчалык
Басты безнең башларны.

Машина белән бүрәнәгә
Тора башым кысылып.
Мөмкин түгел һич алырлык,
Бүрәнәләр тора коелып.

Бүрәнә башыма төшкәч
Акты минем каннарым.
Кансуярның юлларында
Чыкты минем җаннарым.

Их, дусларым, сез кайтырсыз,
Кыр казыдай тезелеп,
Йома көн сәгать җидедә
Җаным чыкты өзелеп.

Йокларга ята идем бит,
Аклы күлмәгем киеп.
Газиз җанкаем чыкты бит,
Башка бүрәнә тиеп.

Больницага барган чакта,
Машинада сикердем.
Хәмәт абый аркасында
Кара гүрләргә кердем.

Семьям белән торган чакта,
Тәмле ашлар ашадым.
Гөлчәчәктәй гомеремне
Хәмәт абый ашады.

Әткәй-әнкәй, бәхил булың, –
Мәңгелеккә ташладым.
Хәмәт абый аркасында
Бетте минем башларым.

Машиналар кызу бара –
Төягәннәр ташкүмер.
Утызынчы яшькә чыккач
Әрәм була яшь гомер.

Машинага төягәндә,
Тыр(ы)шып-тыр(ы)шып төядем.
Туган-үскән авылыма
Кайта канлы сөягем.

Өйдә чакта гармунымда
Туйганчы уйнамадым,
Үзем төягән бүрәнә
Изәр, дип уйламадым.

Әнкәй, ашың пешеп җиткәч,
Балаларың җыелыр.
Алар булып, мин булмагач,
Канлы яшең коелыр.

Әнкәй, мине сагынырсың
Агач яфрак ярганда.
Ярсын-ярсын еларсың инде
Канлы йөзем күргәндә.

Миннән калган киемнәрне
Балаларым кисеннәр.
«Кеше өчен, колхоз өчен
Корбан булды», – дисеннәр.

Быел җәйне җыйган идем
Агыйдел камышларын.
Миңа охшатып тыңлагыз
Машина тавышларын.

Сабан туе көннәрендә
Җыела яшьләр акланда.
Дусларым, искә алыгыз
Эшкә барган чакларда.

Авыл халкы карап кала
Тимерлектән кайтканда.
Фәтхерахман вафат булды
Кич, кояшлар батканда.

Кыр казлары йөзеп йөри,
Йөзеп йөри күлләрдә.
Бөтен җирне кайгы басты
Безнең үлгән көннәрдә.

Тимерлекләр ямьле иде,
Фәтхерахман булганда.
Чүкеч, кайчы, кыскыч иде
Фәтхерахман кулында.

Тимерлеккә барган чакта,
Судан чыктым мин атлап.
Безне күмде авыл халкы
Бик зурлап та, бик мактап.

Сәйтәк суы бигрәк тирән:
Колач җәеп йөзәрсез.
Бу бәетне укысагыз,
Еламый ничек түзәрсез.

*1964 елда Балтач районы Штәнде авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

## 286. Суга баткан Гайшә бәете

Чәршәмбе көн кер юарга,
Ник җибәрдең, әнкәем.
Барма, Гайшә, дигән булсаң,
Бармас идем, әнкәем.

Кулымдагы көмеш йөзек,
Көнгә каршы эридер.
Тал чыбыктай зифа буем,
Су төбендә эридер.

Өстемдәге камзулымны
Элеп куйдым казыкка.
Зифа буем үскән икән,
Балыкларга азыкка.

Баткан чакта итәкләрем,
Батадыр да калкадыр.
Муенымдагы тәңкәләрем
Су төбендә ятадыр.

Аучы мылтык атадыр,
Төтене җиргә ятадыр.
Матур Гайшә баткан дигәч,
Туе елап кайтадыр.

Чәршәмбе көн мунча яктык,
Битем-күзем юарга.
Чәршәмбе көн кер чайкадым,
Газиз башым җуярга.

Приказчик егет килеп җитеп,
Баткан җирне күзлидер.
Курыкмыйча, суга кереп,
Чумып-чумып эзлидер.

Батыр егет эзли торгач,
Бик тә талды хәленнән.
Җан сөйгәнен эзли-эзли
Аерылды җаныннан.

Үкенечле үлем булды,
Буйга үсеп җиткәндә.
Икесе дә вафат булды,
Туй була дип көткәндә.

Батыр булган егетебез,
Җәлләмәгән малын да.
Биргән вәг(а)дәсе өчен
Кызганмаган җанын да.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Йомран авылында*
*Салиха Гайсинадан (1899 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### САТИРИК БӘЕТЛӘР

## 287. Самогончы Хафиз бәете

Самогон койдым бу айда
Арпа кушып бодайга.
Сакла дошман күзеннән дип,
Ник инәлдем Ходайга?

Җәен иген икмәдем,
Кышын урман кисмәдем.
Кырда кошел каравыллап,
Кудым колхоз икмәген.

«Галимулла кем?» – дисәгез:
Талдан сыбызгы ясый.
Галимулла дружин гына
Газиз башымны ашый.

Кодагыйның су чиләген
Самогонга көйләдем.
Кара мунчаларга кереп
Каптырырлар димәдем.

Галимулла кунак икән,
Ат эчерә лаканнан.
Төнге сәгать уникедә
Килеп тотты якамнан.

Аклы күлмәк алдырдым,
Хакын бирми калдырдым.
Эшне зурга җибәрмим дип,
Юкка телем талдырдым.

Үстем илдә тын гына,
Дуска иш булып кына.
Ил алдында хурга калдым
Самогон куып кына.

*1964 елда Балтач районы Иске Яхшый авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

## 288. Хәсән мулла бәете

*Хәсән үзе, мулла булуына карамастан, хатын алган да аерган, алган да аерган. Мөгаллимә аның беренче хатыны була. Аны аерып, икенче хатын алгач, Мөгаллимәнең Хәсәнгә ачуы чыга. Шуннан Мөгаллимә Хәсәннең икенче хатынын аерта да, яңадан үзе бара. Шундый хәл берничә мәртәбә кабатлана. Бу хәл Чакмагыш авылында була. Авыл малайлары, Хәсән мулла белән Мөгаллимәдән көлеп, шушы бәетне чыгарганнар.*

Хәсән мулла – ябалак,
Күк атыңны дагалат.
Мөгаллимәңне аермасаң,
Чыкмас иде яманат.

Эшлияләр һәм камытлар,
Бар да Хәсән атында.
Абыз әби ни әйтә икән
Бу эшләрең хакында.

Хәсән мулланың атлары
Улак аша тибешә.
Атнага бер хатын аеру,
Разе шул эш килешә.

Хәсән мулла кая бара?
Тарлауларга тырмага.
Мөгаллимәнең исе киткән
Хәсән белән тормага.

Ачы микән, төче микән
Мөгаллимә камыры?
Бер кайта да, бер килә ул,
Шулай кызык, ахыры.

Хәсән мулла бик зирәк,
Ул зирәклек ник кирәк?
Мөгаллимә үткер булгач,
Әсмәбикә ник кирәк?

*1970 елда Чакмагыш районы Таш Калмаш авылында*
*Нәкыя Имамган кызы Ситдыйковадан (1899 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 289. Канау буе бәете

Канау буеннан кайта,
Сәкегә менеп ята.
Хатыны чәй кайната,
Чәй эчергә тидия.

«Беләсең, – ди, – тик ятуны», –
Ачулана хатыны.
Ачулана хатыны:
– Беләсең, – ди, – тик ятуны,
Чыгып ләчтит сатуны,
Кайгың да юк тидия.

Карамыйсың бер эш тә,
Бурычың күп Гайнүшкә.
Баттың инде бурычка,
Чыгалмассың тидия.

– Ырылдама, карт тәре,
Тагын сиңа ни кирәк?
Кайнат чәең тизрәк,
Чәй эчәргә тидия.

Син белгәнне мин беләм,
Мин синнән артык күрәм.
Дөньялыкта мин бөлгән –
Тәкъдир шулай тидия.

Юклык белән мал табып,
Юклыкны тәкъдиргә ябып,
Киткәннәр юлдан чабып,
Сукмак белән тидия.

*1970 елда Чакмагыш районы Тозлыкуш авылында укытучы-пенсионер Мәсәлим Гәрәевтан (1905 елгы) БДУ студентлары язып алган*

# МӨНӘҖӘТЛӘР

## ҮЛЕМ ТУРЫНДА

### 290. Беренче мөнәҗәт

Әйдәгез бергә, ятмыйк кабердә,
Чыгыйк, кузгалыйк якта дөньяга.

Якты көннәрдә, салкын төннәрдә
Яктыра бара үлем хәлләре.

Күңелем төшмәде, куллар бармады,
Исәпләр-уйлар миндин калмады.

Якты дөньяда калсын исемем,
Исәпләсәгез, китәр исегез.

Якты дөньяны күреп туймадым,
Бу киң дөньяда бер мин булмадым.

Арыш басуда сайрый бер тургай,
Ризыклар беткәч тәкъдирләр шулай.

Йокым килмәде озын төннәрдә,
Ризык җыймадым үләр көннәрдә.

Яткан жирләрем бик әйбәт иде,
Сырхавым каты, эчләрем көйде

Тыннарым кыса, җаннарым чыга,
Нурлар чәчелсен каберем өстенә.

Яшьли үлгәннәр, гүргә кергәннәр.
Бик авыр хәл бит безгә, туганнар.

Җирләр дымлана, үләннәр кибә.
Кулларым сузсам, туфракка тия.

Китап алыгыз, укып карагыз,
Әрвахка карап гыйбрәт алыгыз.

Дөньяда тордым бик күп вакытлар,
Балчыклар безгә йомшак ястыклар.

Иптәшем калган йоклаган кебек,
Уянып китсәм кара төн кебек.

Кулларым сузам, күңелем бозам,
Куеп киткәннәр, ничекләр түзәм?

Әйдәгез бергә, ятмыйк кабердә,
Һич тә кайтмаслык мәңгелек җирдә.

Үлгән кешенең килми хәбәре,
Һич белеп булмый яхшы-яманын.

Әй туганнарым, бәхил булыгыз,
Искә төшереп, дога кылыгыз.

Мин дә бәхилмен, туганнар, сезгә –
Кыямәт көнсез күрешү юк безгә.

Бигрәк уфтанам иптәшем юкка,
Куеп киткәннәр мәңгелек йортка.

*1977 елда Борай районы Кодаш авылында*
*Зөләйха Хәсәнҗан кызы Аллаяровадан (1906 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 291. Икенче мөнәҗәт

Сиңа вакытлар җитәр,
Бәгырьләреңне кисәр,
Әҗәл якаңнан тотар –
Һич тә аңламай калырсың.

Синең тәнең агарыр,
Сөякләрең таралыр,
Күңелләрең каралыр –
Һич тә аңламай калырсың

Газраил сорар жаныңны,
Мөшкел итәр хәлеңне,
Алмас дөнья малыңны –
Һич тә аңламай калырсың.

Газраил җан алганда,
Җанга көчлек килгәндә,
Бугазларың кипкәндә, –
Һич тә аңламай калырсың.

Бина кылган сорыйлар,
Мәхрүм булып калырдар,
Калур җөмлә малларың –
Һич тә аңламаймусың.

Куәтең җитмәдеме,
Көне-төне йөрдеңме,
Моны аңламадыңмы? –
Һич тә аңламаймусың.

Чәчең агармадымы,
Йөзең саргаймадымы,
Яшең түгелмәдеме? –
Һич тә аңламаймусың.

Үлгәннәрне күрдеңме,
«Үләм» , – диеп йөрдеңме,
Һич гыйбрәт алмадыңмы? –
Һич тә аңламаймусың.

«Үлде», – диеп юарлар
Як-ягыңдин тотарлар,
Дәхи Коръән укырлар –
Һич тә аңламаймусың.

Тәннәреңне юарлар,
Башыңдин су коярлар,
Акбуз кәфенгә чорнарлар –
Һич тә аңламаймусың.

Дусларым, иптәшләрем,
Багламагыз башымны,
Күрим кардәшләремне,
Улымны һәм кызымны –
Һич тә аңламаймусың.

Өйдән алып чыгарлар,
Өйне ялгыз куярлар,
Балаларың еларлар –
Һич тә аңламаймусың.

Башсыз атка мендерер,
Җиңсез күлмәк кидерер,
Мәңгелек йортка илтерләр –
Һич тә аңламаймусың.

Ләхет үзәрә куярлар
Һәм дә сөаль сорарлар,
Кырык адым җир киткәч –
Һич тә аңламаймусың.

Шушы язган сузләрне
Укып аңлатырсыгыз,
Тәүбә итеп, гамәл кылып,
Калбеңне пакьләргә тырыш.

Тәубә итсәң, гамәл кылсаң,
Җаның җиңел бирерсең,
Гөнаһларыңдин пакьланып,
Җәннәтләргә керерсең.

*1977 елда Борай районы Кодаш авылында*
*Зөләйха Хәсәнҗан кызы Аллаяровадан (1906 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 292. Өченче мөнәҗәт

Әйдәгез бергә, ятмаек гүрдә, чыгып кузгалыйк якты дөньяга.
Якты дөньяда калды исемебез, исәпләсәгез, китәр исегез.

Күңелем үсмәде, кулым бармады, хәсрәтләрем күп, миннән калмады.
Якты дөньяны күреп туймадым, ник бу дөньяда мәңге булмадым?

Җәйләргә төшсәм, йөрердәй булам, хуш исләренә терелердәй булам.
Түбән басуда сайрый бер тургай, бер Ходай кушкач, тәкъдирләр шулай.
Тәнем бик зәгыйфь – каты юмагыз, кире кайталмам – ашыктырмагыз.

Һичкем кермәгән, ишек куймаган, кызыл буяуга кемнәр буяган?
Бу ялгыз өйгә кемнәр китергән, тәрәзәсе юк – кемнәр бетергән?

Кояшлар төшә, яңгырлар ява, үләннәр үсә минем өстемә.
Яшь вакытларда гамәл кылмадым, юлдаш кыл, Ходай, нурлы иманым.
Уйлап караем чыгып китәргә, чыгып булмыйдыр – ни хәл итәргә?

Ерак илләрдән күрә килгәннәр, дога кылыгыз, якын туганнар.
Үлем хәлләре бигрәк сусата, әгәр чыдасаң, рәхмәтләр арта.

Йорттан чыкканда, һич ашыкмагыз, бик еламагыз, зинһар, чыдагыз.
Каберләремне иркен казыгыз, ак ташлар куеп, исемем языгыз.

Чатырлар корып, кошлар кундырып, агач утыртып нурландырыгыз.
Яфраклар ярып, кошлар сайрасын, рухым шатланыр, догалар барса.

Үләннәр үсә кабер өетенә, нурлар чәчәләр каберем эченә.
Яшьләй үлүе, гүргә керүе бик авыр хәл шул, туганнар, безгә.

Туганнар, зинһар, килеп карагыз, безләрне күреп, гыйбрәт алыгыз.
Дөньяда тордым бераз вакытлар, туфраклар безгә мамык ястыклар.

Куеп киткәннәр кара тун кебек, уянып китсәм, кара төн кебек.
Якты дөньяда, салкын гүрләрдә, бигрәк сусата үлем хәлләре.

Йокы күрмәдем озын төннәрдә, ризык җыймадым үләр көннәрдә.
Яткан урыным да бик рәхәт иде, сыкравым каты, эчләрем көйде,
Тамагым кипте, тыннарым бетте, ялгыз китәргә вакытлар җитте.

Ачып карарга күзем таладыр, барча туганнар миннән каладыр.
Җанның чыгыры кичләрдә булса, төннәр саклагыз авыр булса да.

Зифа буйларым үлчәп алыгыз, каберемне минем иркен казыгыз.
Зифа буйларым, нурлы йөзләрем, якты дөньяда актык көннәрем.

Кабыкка салып, пакьлап юыгыз, зәгыйфь тәнемә кәфен салыгыз.
Күзем йомылган, нурым коелган, берни сөйләми: телем тотылган.

*1977 елда Борай районы Яңа Тазлар авылында*
*Саимә Гыйльфановадан (1911 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 293. Дүртенче мөнәҗәт

Әҗәл сырхавы каты, туганнар,
Шул вакытларда чыгадыр җаннар.
Хәлләрем бетте, әҗәлем җитте,
Тәнемдә итләр дә бөтенләй кипте.

Җаннарым чыга, борыгыз кыйблага,
Тере тәнемнән кайнар тир ага.
Җаннарым чыккач, йомыгыз күземне,
Ясинсыз куймагыз, зинһар, үземне.

Тәсбихлы кулым куйыйм күкрәккә,
Үлгәч догалар кирәк бигрәк тә.
Ак кәфеннәргә чорнап алдылар,
Җиназаларга чыгарып салдылар.

Тар ләхетләргә илтеп куйдылар,
Якты дөньялар бездән калдылар.
Бар кардәшләрем озата килделәр,
«Азак(кы) туйлары, кайтмас», – диделәр.

Җавап алганда тетриләр илләр,
Ике фәрештә: «Курыкма», – диләр.
Караңгы гүрдә чери тәннәрем,
Рәхәтлекләрдә чыкты җаннарым.

Кәүсәр чишмәдин сулар эчәбез,
Атнакичләрдә дога кылабыз.
Якты дөньяда кала исмебез,
Исәпләсәгез китәр исегез.

Озын төннәрдә, салкын гүрләрдә
Яткыра безне үлем хәлләре.
Йокым килмәде озын төннәрдә,
Ризык җыймадым азак көннәрдә.

Яткан урыным йомшакта иде,
Сырхавым каты, эчләрем көйде.
Тәнемне алып, юып салдылар,
Юып бетергәч, кәфен салдылар.

Хушбуйландырыгыз зифа буйларым,
Якты дөньяда актык туйларым.
Йөзем юылган, нурым коелган,
Бер дә сөйләшми, телем тыелган.

Тәнем бик зәгыйфь, каты юмагыз,
Бик җыламагыз, зинһар, чыдагыз.
Пакь җиргә куеп, җиназа укыгыз,
Яхшылыгымны истә тотыгыз.

Кабергә куйгач, ташлап китмәгез,
Миңа багышлап Коръән укыгыз.
Агачлар утыртып, шатландырыгыз.

Яфраклар ярсын,  кошлар сайрасын,
Догалар барсын, рухым шатлансын.
Үләннәр үссен каберем өстенә,
Нурлар чәчелсен каберем өстенә.

Кояш кыздыра, үләннәр көя,
Кулымны сузсам, туфракка тия.
Дөньяда тордым хәтсез вакытлар,
Балчыктан безгә йомшак ястыклар.

Инде йортларым еракта минем,
Куеп киткәннәр, ни хәлләр итим?
Иптәшсез калдым, йоклаган кебек,
Уянып китсәм, кара төн кебек.

Кулларым сузсам, күземне ачсам,
Искиткеч хәлләр, ничекләр түзим?

Уйлар уйланам чыгып китәргә,
Чыгып булмый бит, ни хәл итәргә?

Барыбыз бергә караңгы гүрдә,
Бер дә кайтмаска, мәңгелек җирдә.
Тәрәзәсе юк, ишек куймаган,
Кызыл буяуга кемнәр буяган.

Монда ятабыз, бер дә кайтмыйбыз,
Кыямәт көнне көтеп ятабыз.
Бер көннәр җитәр, кыямәт булыр,
Безнең урыннар оҗмахта булыр.

Күкрәгем тибә, тыннарым бетә,
Ясин чыгарга вакытлар җитә.
Ачып карарга күзләрем тала,
Барча яктылык дөньяда кала.

Кояш чыкканда, нур тула йөзгә,
Кыямәт көнсез кавышу юк безгә.
Тирән күмсәләр, кайталмам инде,
Түшәкләремә яталмам инде.

*1970 елда Чакмагыш районы Үрнәк авылында*
*Мәһинур Заһидуллинадан (1911 елгы; ике ел – искечә, унике ай яңача укыган)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 294. Бишенче мөнәҗәт

Минем бер яшьлегем китсә,
Йөземнең нурлары китсә,
Яшәрмәс ул, чәчәк  атмас,
Рәхим кылсын үзе, Аллаһ.

Кара чәчем бу агарса,
Йөземнең кызылы китсә,
Күземнең күрмеше китсә,
Табылмас бу фани дөнья.

Колагымның аңы китсә,
Авызымда тешем бетсә,
Тәнемнең куәте китсә,
Табылмас ул фани дөнья.

Бу дөньядан китәр булсак,
Каберләргә керер булсак,
Калыр дөньяда барысы,
Кыйбла күрең гамәлеңне.

Үлемнәр бик каты хәл ул,
Безнең башка килер бер көн.
Катышмас андин һич беркем
Рәхим кылсын үзе, Аллаһ.

Атаң, анаң кала, дими,
Улың, кызың кала, дими,
Хәләл җефетең кала, дими –
Үлем – аеручы хәл ул.

Туганнарың кала, дими.
Җыйган малың кала, дими,
Дус-ишләрең кала, дими –
Үлем – аеручы хәл ул.

Газиз җаныңдин аерыр,
Кызыл йөзеңне сүндерер,
Тәнеңне боз кебек кыйлыр –
Боны аңласын һәр адәм.

Тәнеңдин кан агызсаң да,
Ни кадәрле ышансаң да,
Котылмассың үлемнән һич
Башыңны тышка орсаң да.

Газиз күргән ата-анаңнан,
Дәхи сөекле балаларыңнан,
Якын күргән туганнарыңнан
Аеручы – үлемдер ул.

Карамас ул җәмалыңа,
Карамас ул Кәмалыңа,
Нихәтле баласын куйган –
Бу үлем шундый хәлләр ул.

Гамәл кылгын, и кардәшләр,
Гамәл булыр сиңа юлдаш.
Галәмизләр булыр бихуш –
Үлем шундый хәлләр ул.

Ки бер көнне үләчәкбез,
Гарисатка барачакбыз,
Гамәлләрне күрәчәкбез –
Фикер кылып йөрик, кардәш.

Хода боерыгын тотмый.
Гамәлсез һич гафел ятма.
Кыямәт көн китererләр,
Китабыңны сул яктан.

Гамәл кыйлгын ки һәркемгә.
Карамагыл фасыйк иргә.
Ихлас белән гамәл кылгыл:
Гамәлең китмәсен җилгә.

*2001 елда Бакалы районы Иске Корыч авылында*
*Зөлфия Зариповадан (1925 елгы)*
*БДУ студенты Светлана Гарифуллина язып алган*

### 295. Рамазан ае

Ай-һай, рамазан, үтәсең инде,
Бигрәк ямансу итәсең инде.
Кергән көннәрдә шатлыклар иде,
Чыккан көннәрдә ямансу иде.

Көннәрең ямьле, кичләрең матур,
Үтеп киткәчтен, сагынырбыз инде.
Ай-һай, рамазан, без гафел һаман,
Риза була күр без бичарадан.

Кадер кичләрең бик ямьле иде,
Үтеп китәсең, хуш, сау бул инде.
Тоткан уразабыз кабул булсачы,
Алдагы елны тагын күрсәкче.

Елларың озын, унике айдыр,
Үтеп киткәнче, кемнәр югалмый.
Без шуны телик, барыбыз бергә,
Киләсе елны тагын күрергә.

Телибез синнән раббем шуларны,
Имин үтүен килер елларның.
Бардыр оҗмахың, бардыр тәмугың.
Безгә ач, раббем, рәхмәт накугын.

*1970 елда Чакмагыш районы Үрнәк авылында*
*Маһинур Заһидуллинадан (1911 елгы. Ике ел – искечә,*
*унике ай яңача укыган) БДУ студентлары язып алган*

**296. Уза гомеребез зарланып...**

Укыйк Коръән, әйтик салават,
Рәселулланың үзенә.
Кыямәт көне булганда,
Карарбыз аның йөзенә.

Рәселүлланың пораклары,
Көмештәй тояклары.
Ихлас белән гамәл кылыйк,
Без – бу дөнья кунаклары.

Уза гомеребез зарланып,
Фани дөньяга алданып.
Телим дидар, телим җәннәт,
Илаһи, сиңа җалбарып.

Илаһи, сорыймын синнән,
Гафу кылгыл гөнаһымны,
Ахры зәмдә насыйп әйлә,
Шәрәфәтле иманымдин.

Ходаем, бән сәфәр чыксам,
Юлыктырма җаманнарга.
Газиз җанымны алсаң да,
Иманымны оныттырма.

*1970 елда Чакмагыш районы Тозлыкуш авылында*
*Разия Камалиевадан (1905 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

**297. Әллә яшьли генә җәтим калганга мин...**

Сандугач сандугачка җим бирәдер,
Хәрендәш хәрендәшкә, дим, бирәдер.
Яшьләй генә ятим калды ялгыз башым,
Минем ничек торганымны кем беләдер?

Эчкәйләрем, йөрәккәем дөрләп яна,
Минем узган рәхәт тормышларым кая?
Хәзерге гомерләрем үтә зая,
Әллә кайгы күлләренә төшкәнгә мин.

Сахраларга чыксам, ямьнәр табалмаем,
Йокыларга ятсам, йокы алалмаем.
Ризык җыйсам, ләззәтләрен табалмаем,
Әллә кайгы күлләренә төшкәнгә мин.

Яланнарга чыксам ялгыз башым,
Сандугачлар булалар юлдашым.
Шул чакларда алар сайрый, мин җылыймын –
Чишмә кебек ага минем кайнар яшем.

Күзләремә кайнар яшьләр тулу белән,
Көн яктыларын да туя күрә алмыйм.
Дөньяларда рәхәт тормыш сөрә алмыйм,
Әллә яшьли генә җәтим калганга мин.

Җәтимлектән авыр хәлләр юк дөньяда,
Җәтимнәрнең һәрвакыт та күңеле боек.
Сүзләсә, бичараның сүзе сынык,
Әллә яшьли генә җәтим калганга мин.

Җәтим балалар җыласа, җир-күк җылый,
Бу ятимнәр нигә җылый икән болай?
Җыласа да, батучы юк аларны шул,
Хак тәгалә маңгаена язган шулай.

Тигезлекнең ләззәтләрен шуннан беләм:
Сабыйлары үсә ата-ана белән.
Җәтимнәр үсәләр җәфа белән,
Әллә яшьләй генә җәтим калганга мин.

Җәтим балалар һәрвакыт та ялгыз яши,
Һич булмыйдыр аларның дус-ишләре.
Аталылар берсе дә аларга тиң түгел,
Берсенең дә ятимнәргә исе китми.

*1970 елда Чакмагыш районы Тозлыкуш авылында*
*Разия Камалиевадан (1905 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

**298. Аналар утыра түрдә**

Тугыз ай күтәреп йөрдем,
Хәләл сөтләремне бирдем.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран:
Баламнан катылык күрдем.

Анага бала бик татлы,
Тугач та тәннәрен пакьли,
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран:
Ана күңелен бала таплый.

Аналар утыра түрдә,
Вакытсыз кермиләр гүргә.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран:
Ананы сөймиләр бер дә.

Балакаем, нурлы йөзем,
Күреп туймый ике күзем.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран:
Бары ялган минем сүзем.

Баладагы гаепләрне
Авыр булса да, ана каплый,
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран:
Ана гаебен бала таба.

Ашарга да вакыт җитте,
Карын ач, аш вакыты үткән,
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран:
Баламның шәфкате беткән.

Үзен уйлый-уйлый зиһенем,
Беразга таралып китә.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран:
Шулай гомерләрем үтә.

Бала бит ул – йөрәк мае,
Эчкәемдә кайгы кайный.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран:
Балалар белмиләр аны.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Ихсан авылында*
*Мәдинә Сөләймановадан*
*БДУ студентлары язып алган*

# ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ

## ЛИРИК ҖЫРЛАР

### 299. Зиннәт җыры

Ай-вай, Гөлмәрфуга, бөдрә чәч.
«Минем җаным килде», – диеп,
Йөгереп чыгып, ишек ач.

Сандугачым, сайрама әле,
Сайрап эчемне өзәсең, аппагым.
Ай-вай, Гөлмәрфуга, читегең,
Сән әйтмәсәң дә беләмен
Чит илләрнең читенен.

Эчем өзелгәндә сайрап
Әҗәлсез үтерәсең, аппагым.
Ай-вай, Гөлмәрфуга, шәлләрең,
Тышка чыксаң, күп йөрисең
Сәне бигрәк җәлләрем.

Бәнем кашың биг(е)рәк кара,
Сәнеке дә карамы, аппагым?
Ай-вай, Гөлмәрфуга, калфагың,
Калфагыңны кыңгыр салып,
Кайда бардың аппагым?

Сәнеке дә бәнең кебек
Эчкәйләрең янамы, аппагым?
Ай-вай, Гөлмәрфуга, күлмәгең,
Кичә көндез кайда йөрдең,
Нурлы йөзең күрмәдем?

*1964 елда Балтач районы Тушкыр авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

### 300. Мәдинәкәй җыры

Шәм-шәриф дигән, ай, шәһәрдә,
Мәдинәкәй сылуым, нечкә бил,
Кич ахшамсыз капкалар ябылмас.
Үткән дә гомер, калган хәтер,
Мәдинәкәй сылуым, нечкә бил,
Сатып алам, дисәң дә, табылмас.

Икедәй генә егет юлга чыккан,
Мәдинәкәй сылуым, нечкә бил,
Сагну малкайларын бүләргә.
Егеттәй генә кеше, ай, шул була
Мәдинәкәй сылуым, нечкә бил,
Риза-бәхил була үләргә.

*1964 елда Балтач районы Сәйтәк авылында*
*Талига Хаҗиевадан (1888 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 301. Асраулар җыры

Ятимлек бигрәк начар,
Фәкыйрьдән һәркем качар.
Ятим дә, фәкыйрь булса,
Ризык хак җиргә чәчәр.

Әнекәем, мине ник таптың?
Кайгы күрсәтергәме?
Чит илләрдә, чит җирләрдә
Бәхет эзләтергәме?

Ай-вай, замана,
Кечерәк кенә кыз бала.
Шул кечерәк кыз баланы
Җәнем-тәнем кызгана.

*1964 елда Балтач районы Штәнде авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән)*

## 302. Төрмә җыры

Ничә еллар бу бинада
Утыра ялгыз башым,
Бер савыт су, телем икмәк
Иде минем бар ашым.

Бакчаларда сандугачлар
Сайрай микән әле дә?
Әллә алар да төшкәнме
Мескен тоткын хәленә?

Хәтфә кебек яшел булып
Тора микән җир йөзе?
Әллә алны да яндырып
Беткәнме дошман сүзе?

Чыга торган идем ауга,
Башыма таҗлар киеп,
Инде салкын төрмәләрдә
Утырам башым иеп.

Йөз мең алтын торыр иде
Минем атланган атым.
Тәхетемдер инде хәзер
Шушы утырган ташым.

Ак Иделгә казлар төшкән –
Баласы алты гына.
Күңелләрем сезнең белән –
Җаннарым ярты гына.

*1964 елда Балтач районы Иске Яхшый авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

## 303. Әллүки

«Әллә-бәлли», – диярмен,
Хикәяләр сөйләрмен.
Сиңа теләкләр теләрмен,
Бәхетле бул, диярмен.

Кичтән йокың кала да,
Елап үтә көндезен.
Гыйззәтем син, кадерлем син,
Минем йөрәк бәгърем син.

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу.
Мәдрәсәдә белем алгач,
Мулла булып китәр бу.

Рәшәтнәмә алыр бу,
Зәңгәр йортлар салыр бу,
Мин үлгәчтен, догачы
Булып кына калыр бу.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Коты авылында*
*Бибинур Гайсинадан (1894 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 304. Тау җыры

Тау биекме, син менәмсең,
Мен, менәлсәң, таугa мен.
Тауга менеп, күр дөньяны,
Күр бу дөньяның ямен.

Күр син анда киң яланнар,
Күр авыллар, күр сулар,
Күлләр, урманнар, болыннар,
Бер таралсын кайгылар.

Төш түбәнгә, йөр син анда,
Күр чәчәкләр, чишмәләр.
Күр игеннәр, күр җимешләр,
Кайгыларыңны җибәр.

*1970 елда Чакмагыш районы Тозлыкуш авылында*
*Ракыя Гаделгәрәй кызы Исламовадан (1910 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 305. Алдырмастай киек, ай, алдырмас...

Алдырмастай киек, ай, алдырмас,
Алларында кыя тау булса.
Кайгырмасын егет, кайгырмасын,
Газиз башкайлары сау булса.

Арка җиркәйләрдә ат уйный.
Уйсу җиркәйләрдә төлке уйный.
Аталардан бала ятим калса,
Көн итүләрен көн дә уйлый.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Коты авылында*
*Хаҗигали Дәүләтшиннан*
*БДУ студентлары язып алган*

### 306. Сагыну җыры

Иртән генә торып тышка чыксам,
Таң җилләре исә яланнан.
Күз яшьләрен түгеп мин көтсәм дә,
Хәбәр килми газиз баламнан.

Кая гына барыйм, кемгә сөйлим
Йөрәгемнең әрнеп җанганын.
Ишетергә миңа язды микән
Балакаемның исән кайтканын.

Йомылып кына чапкан аткаеңны
Тезгененнән тотма, буш җибәр.
Аңтыса да, дошман куып җитмәс,
Буш җибәргән атны – кош, диләр.

Кара атка менеп, камчы элеп,
Кайда йөри минем алтыным.
Үлгән генә микән, исән генә микән?
Газиз балам, минем алтыным.

Кызганамын сине, куркамын да,
Ай, алтыным, китеп, юк булдың.
Нинди генә явыз, нинди генә дошман
Белән көрәшкәндә юк булдың.

Һәрбер кыемнарын тигез кисеп,
Төн утырып күлмәк тегәмен.
Сугышларга киткән бәбкәемә
Шушы булсын минем бүләгем.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Коты авылында*
*Галимә Ситдыйковадан*
*БДУ студентлары язып алган*

### 307. Егет җыры

Җырласаң, егет, моңлы җырла,
Йокыдагы кызлар уянсын.
Моңлы бардыр, моңсыз бардыр,
Моңлыларның күңеле юансын.

Сахраларга чыксам ялгыз башым,
Кызыл йолдыз булсын юлдашым,
Кызыл йолдыз булса, ай, юлдашым,
Мең дошманга торыр бер башым.

Быел ла гына печән мин чапмадым,
Бөрлегәннәр өзеп капмадым,
Бу дөньяларны ла өч әйләндем,
Синнән күркәмнәрне тапмадым.

Җилбердәй җилбер җилләр исә,
Җитен тамырын ла җил кисә.
Егетләр дә үсә, кызлар да үсә,
Егет бәгырьләрен кыз кисә.

Ишек алларымда түгәрәк күл,
Тирә-ягы аның кызыл гөл,
«Мин матурмын», – диеп, син мактанма,
Өзелеп сөйгәннәрнең кадерен бел.

Тау буйларында, ай, күк чәчәк,
Ничек кенә үскән, көн тими?
Кашларың да кара, буең зифа,
Ничек кенә үстең, күз тими?

Каз канатлары кат-кат булыр,
Ир канатлары ат булыр.
Хатларыма каршы хатлар язсаң,
Сөюләрең синең хак булыр.

Су буйлары, дуслар, тугай-тугай,
Тугай саен сайрый бер тургай.
Иртәсен дә сайрый, кич тә сайрый,
«Бу моңаеп үлсен», – ди бугай.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Коты авылында*
*Кәримә Фәйзуллинадан (1920 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 308. Яшьлек җыры

Сандугачлар сайрый һаваларда,
Бөтен дөнья тулган нур белән.
Тик мин генә уйда, шундый моңда,
Бөтен эчем тулган моң белән.

«Нинди тавыш?» – диеп, бер карасам,
Килеп кунган икән сандугач.
Ул сандугач килеп миңа әйтте:
«Ни уйлыйсың, дускай, күзең ач».

Яшь сандугач, ул да моңлы сайрый,
Ике моңлы бергә кушылдык.
Аның белән бергә без икебез,
Сөйләштек тә хәзер дус булдык.

Яшь сандугач көйли, нидер сөйли,
Аңлый алмыйм аның сүзләрен.
Бәлки, күргәндер дә ул сандугач,
Син дускайның йөргән җирләрен.

Ул сүзләрен сөйләп, саубуллашып
Очып китте минем янымнан.
Ул да китте, хәзер мин ялгызым,
Беркем дә юк минем янымда.

Матур булып язлар килер инде,
Чәчәк атар инде алмагач.
Язның килүендә ни файда бар,
Үз янымда дустым булмагач.

Яшел яфрак ярыр ак каеннар,
Күбәләкләр очар болында.
Синең исмең, синең алмагачың
Яңрар яшьлек сагыну җырында.

Матур булып йомшак язлар килгәч,
Юлга чыгып, сине карармын,
Кырды җыйган матур чәчәкләрне
Синең күкрәгеңә кадармын.

Сандугачлар талга басып сайрар,
Яз көннәре җылы, яшелгә.
Язлар килер, язлар тагын китәр,
Безнең дуслык калыр мәңгегә.

Бөдрә чәчләреңне җайлап тара,
Зәңгәр шәлең бөркән аппагым.
Язгы матур көннәр килү белән
Чыгып кара бозның акканын.

Күзләреңә карап елмаерлар
Кояшкайның җылы нурлары.
Шатлык белән шаулап-уйнап агар
Елгаларның ярсу сулары.

Әгәр минем салкынлыкны сизсәң
Исеңә төшер аккан бозларны.
Онытма син, матур чәчәк аткан
Язы булган салкын кышларны.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Коты авылында*
*Хәсәнә Нурлыгаяновадан*
*БДУ студентлары язып алган*

РЕКРУТ ҺӘМ СОЛДАТ ҖЫРЛАРЫ (НАЗЛАР)

## 309. Солдатка киткәндә

Күрдем инде солдатларны –
Өчәр-өчәр баралар.
Туган илне саклар өчен,
Солдат итеп алалар.

Кара бөдрә чәчләремне
Майлыймын да тарыймын.
Армияга баруымны
Зур бәхеткә саныймын.

Солдат итеп алсалар да
Будырмам билләремне.
Кара чәчем агарса да
Онытмам илләремне.

Солдат мескен ашаганы –
Базда яткан кәбестә.
Солдат күргәннәрен безгә
Күрсәтмәсен фәрештә.

Содатларга аш бирәләр
Калай табаклар белән.
«Смирно!» – дип кычкыралар
Калын тамаклар белән.

Солдат итеп алсалар,
Корал ал билләреңә.
Корал алсаң билләреңә,
Кайтырсың илләреңә.

*2002 елда Илеш районы Кадер авылында*
*Фәнүзә Гыйльвановадан*
*БДУ студенты Альмира Хәйретдинова язып алган*

## 310. Солдат җыры

Җомга көнне сәхәрдин
Хәбәрдин килде авылга.
Ул хәбәрне китергәндә
Чыдап булмый давылга.

Безнең илләр Истамбул,
Шул илләргә ята юл.
Туганнарым, эткәм-әнкәм,
Күрә алмасам исән бул.

Без барабыз Борайга,
Борайлардин Чурайга.
Чурайлардин чыгып киткәч
Тапшырабыз Ходайга.

Балаларым: «Әткәем!» – дип,
Асылыналар муенга.
Әткәй-әнкәй: «Бәбкәем!» – дип,
Акча тыга куенга.

Кайсы солдат уракта,
Кайсы солдат еракта,
Кайсы мескен елап карый
Файда юк ла елап та.

Быел төшкән яшь киленнәр
Озата барды калага;
Күз дә ачып карап булмый
Елап калган анага.

Иртә намаз чакларында
Әкрен генә җил җылай,
Карт солдатлар чыгып киткәч,
Җирләр түгел, ил җылай.

Солдат итеп җибәрделәр
Белмим кайсы калага.
Ничава киткән балага
Авыр калган ата-анага.

Солдат поход чыгып китте
Утырып ил атына.
Малы – зәкат, җаны – корбан
Падишаһлар хакына.

Аршин-аршин ак клеенка
Тәрәзәдәге пәрдәгә.
Ураза кая, намаз кая
Сугыштагы бәндәгә.

*1964 елда Балтач районы Иске Яхшый авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

## 311. Табын җырлары

Әле яшьбез, картаербыз,
Сыйпарбыз сакалларны.
Ике яшькә бәхет теләп
Күтәрик бокалларны.

Чыгамын да карап керәм
Һавадагы аемны.
Үзем эчми сиңа бирәм
Үземә тигән паемны.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре – Мөслимә.
Гөлләр булса, куяр идем
Биек өстәл өстенә.

Мәрьям чибәр, Мәрьям чибәр,
Мәрьям кулъяулык чигәр.
Салып биргәч эчеп җибәр,
Артыннан җырлап җибәр.

Дусларымның колагында
Алтын алкалары бар.
Дусларымның бите кояш,
Ай гына калкасы бар.

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява
Кое чылбырларына.
Сез, дусларым, охшагансыз
Сахра былбылларына.

Стаканым бигрәк тирән,
Тирәсенә гөл кирәк.
Шул гөлләргә сезне тиңләп,
Дусларыма җырлап бирәм.

Стаканың путалы,
Уң кулыңа тот әле.
Уң кулларыңа тот әле,
Гөлт-гөлт итеп йот әле.

Имән агач – каты агач,
Каен агач, чырагач.
Салып биргәч, эчеп җибәр,
Тәм кергәндер җырлагач.

Өстәлләрдә ике шешә,
Берсе киндер бәясе.
Берсе күңелләрне ача,
Берсе йөрәкне баса.

Биек тауның башларында
Каен бура бурыйлар.
Абзыкаем, мыегыңны
Калфак чугына урыйлар.

Биек тауның башларыннан
Тәгәреп төшә мичкә.
Әй, дусларым, җырлашаек,
Калмасын үкенечкә.

Агыйделгә казлар төшкән,
Агып китмәсләр микән?
Мин дә җырлап карыйм әле,
Гаеп итмәсләр микән?

Җирән атым җигешле,
Җигешләре килешле.
Җырга каршы җыр җырлана,
Дуслар, сезгә тиешле.

Минем чәчем беркет-кара,
Чапкан атны өркетә.
Алдымдагы стаканым
Хозяйкадан җыр көтә.

Дилбегә белән йөгәнне
Бер чөйләргә эләләр.
Үзеңә тигән пайларны
Җан дустыңа бирәләр.

Стаканымның төпләре
Көмеш белән тутырган.
Җырламас идем, уф кынам,
Якын күргән дус кынам.

Бишәтемдә биш пугывка,
Алтынчысы – каптырма.
Азаккы җырларны җырлыйм,
Башка җырлар таптырма.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре ич Фоман.
Башка җырлар җырлыйсым юк,
Мәҗ(е)лес булсын тәмам.

Чылдар-чылдар итәдер
Ат өстендә ыңгырчак.
Хуҗага житте ятар чак,
Безгә җитте кайтыр чак.

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Бишәүләп килдек сезгә.
Алтау, җиде, сигез, тугыз,
Унаулап килең безгә.

Ат булмаса, булмас инде,
Җәяү барыйк тәпиләп.
Сый булмаса, хөрмәт булыр,
Чәй эчәрбез эпиләп.

*1964 елда Балтач районы Сәйтәк авылында*
*Талига Хаҗиевадан (1888 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

## 312. Кыска җырлар

Алъяпкычың өчкә төр,
Өчкә төрмә, бишкә төр.
Кунмыйм, куркам, ятлар белән,
Иркәм сизсә, нишләтер?!

Йөрәкләре ярсу була
Чабып килгән атларның.
Кадерләрен белдек микән
Бергә булган чакларның?

Аклы ситса күлмәгемнең
Җиңнәре төймәләнгән.
Кояш синең йөзләреңә
Нурларын сибәләгән.

Безнең урам, озын урам,
Борылып үскән бер каен.
Мин дә ялгыз, син дә ялгыз,
Нишләек соң, дускаем?!

Тәрәзәмнең төпләрендә
Ике савыт гөлкәем.
Җилгә очкан җефәк кебек,
Үтмәсен гомеркәем.

Самоварны тиз кайната
Чынагач күмерләре.
Басудагы зәңгәр чәчкә –
Кыз бала гомерләре.

Безнең Иш таулары биек
Менәм ак күлмәк киеп.
Йокыларымнан уянам,
«Уф, йөрәккәем», – диеп.

Түбәтәеңнең түбәсе,
Җитмеш ике миркәсе.
Без үзебез чибәр түгел,
Чибәрләрнең иркәсе.

Алма бакчасына керсәм,
Алы бар, кызылы юк.
Кирәкми кеше ярлары,
Барыбер кызыгы юк.

Яркәйләргә барган чакта,
Карурманнарны үтәм.
Сине көтәм, сабыр итәм,
Кирәкми миңа бүтән.

Айлар итәсем килә,
Гөлләр итәсем килә,
Шомырт чәчкәләрен өзеп,
Бүләк итәсем килә.

Атымның дугасы алтын,
Сынса да алдырмыймын.
Башым кара гүргә керми,
Ятларга калдырмыймын.

Алтын алка колакта,
Күләгәсе beləктә.
Мәхәббәт гөлләре булып
Чәчкә атасың йөрәктә.

*2002 елда Илеш районы Сеңрән авылында*
*Зәйтүнә Солтановадан (1912 елгы)*
*Альмира Хәйретдинова язып алган*

Суга барсам, карап торам:
«Ну, да, агасың», – диеп,
Алма да әйтә, өзелеп төшкәч:
«Калды агачым», – диеп.

Ике аккош очып килә,
Берсе төште суларга.
Берсе төште дә югалды,
Без ошадык шуларга.

Чәчем сибелә, чәчем сибелә,
Сибелеп беттең инде.
Нурланып торган йөземә
Сарылар сиптең инде.

Исәпләсәм, исем китә:
Мин нишләп болай булдым?
Алма бакчасыннан очып,
Кайгы талына кундым.

Үзем дә аптырап торам
Болай булуларыма.
Бер хәсрәтем ике була
Иртән торуларыма.

Беләкләрем талыр инде,
Сәгатьләр бәйләсәм дә.
Мин аны табалмам инде,
СССРны әйләнсәм дә.

Сандугачның сайравына
Мин сорадым бер җавап.
«Нигә аерым яшисез», – дип,
Сайрады миңа карап.

Син боекмы, мин боекмы?
Билгеле инде, мин боек.
Мин боега, дип боекмаң,
Мин аерылганга боек.

Сатучылар алма ашый,
Алманың ни туклыгы?
Бәхетлеләр рәхәт яши,
Их, бәхетнең юклыгы.

Кисәсе иде, ягасы иде
Карурман әрдәнәсен.
Аерылу бар, кушылу бар,
Кемнәрдән гарьләнәсең?

Кистем каен, кисмәң каен,
Каен кисүе кыен.
Калдым ялгыз. Калмаң ялгыз,
Ялгыз яшәве кыен.

Биек тауның башларында
Әрме атларымени?
Әле минем йөрәгемнең
Әрнер чакларымени?

Аклы ситса күлмәгемнең
Энҗе тишекләре юк.
Гүргә кергәч, күрешеп булмый,
Гүрнең ишекләре юк.

И, Ходаем, ник яраттың?
Дөнья күрсәтергәме?
Ят илләрдә, ят җирләрдә
Нужа күрсәтергәме?

Башымдагы яулыгымның
Чигелгән эшләпәсе.
Мәгълүм түгел чәчкәемнең
Кемнәргә бәйләнәсе.

Кыз бала кыза башласа,
Яулыгын суга ташлый.
Кыз баланың сабырсызы
Үз башын үзе ашый.

Ир бала – ил былбылы,
Кыз бала – гөл былбылы.
Ил – былбылсыз, былбыл гөлсез
Яши алмый, билгеле.

Бергә чакта бергәлекнең
Кадерен белмәдек, бугай.
Бергә чакта кем уйласын,
Айрылырбыз, дип, болай.

Биек тауда ак тегермән
Ак бодай гына тарта.
Кая безгә кайгысыз көн?
Минуты саен арта.

Яңгыр явып, бизәк ясый
Күбәләк канатына.
Без түгел, күбәләкнең дә
Гөле бар яратырга.

Ике аккош, бер тутый кош,
Өчәүләп серләшәләр.
Алар үзләре янына
Серләшергә дәшәләр.

Кашларым кара булды,
Башларым моңлы булды.
Шулкадәрле башларыма
Моң бирмәсәң ни булды?

Ян, йөрәгем, ян, йөрәгем,
Ян, йөрәгем, түзәрмен.
Ян, йөрәгем, ныг(ы)рак ян,
Түзәлмәсәм, үләрмен.

Биек тауның башларында
Уралып үскән сырлан.
Кайчан кайгыларым бетә,
Шунда туктармын җырдан.

Биек тауның башларында
Үскән икән чын бодай.
Җырын җырлап юансын, дип,
Бәхет бирмәгән Ходай.

Биек тауның башларында
Утырып тордым ташка.
Күңелләрем сезнең белән,
Җаннарым гына башка.

Мендем тау башларына,
Утырдым ташларына.
Тормыш җиле авыр исә
Калса үз башларыңа.

Биек тауның башларында
Санадыңмы усакны?
Аерым тору күңелләме,
Әллә бергә торсакмы?

Ал бизәкләр була икән
Пуховой шәлләрдә дә.
Бер-беребезне он(ы)талмыйбыз
Аерылган җирләрдә дә.

Ач тәрәзәң, җил керсен,
Гөл яфрагы селкенсен.
Елама, иркәм, түкмә яшең,
Без күрәсен кем күрсен?

Биек тауда бигрәк ямьле
Җәен сәяхәт итәргә.
Безне тормыш мәҗбүр итте
Сезне ташлап китәргә.

Биек тауга чаршау кордым,
Җил тимәгән җирләрдә.
Минем дә торасым килми
Сез булмаган җирләрдә.

Биек тауның башларында
Каеннар да, муеллар.
Кайгыларымны белгәнгә,
Моңлы сайрый былбыллар.

Ал юам елгаларда,
Гөл юам елгаларда.
Кайгы-хәсрәт күрмичә
Яшә иде дөньяларда.

Агыйделнең камышларын
Кем төшеп урган икән?
Аерыласы минутларым
Алдымда торган икән.

Бәйлим, сүтәм, бәйлим, сүтәм
Бәйләгән шәлләремне,
Бәйләгән атлар кебекмен,
Белмисез хәлләремне.

Гармун тавышы ишетсәм
Килә еласыларым.
Төшләремә дә кермәде
Болай буласыларым.

Аккош микән, былбыл микән,
Комда калган эзләре.
Аның да минеке кебек
Өзелә микән эчләре.

Күрдегезме комбайнның
Кайда урак урганын?
Күбәләктәй җаннарымның
Белмим кайда торганын.

Карурманда кош кычкыра
Моңлы тавышы белән.
Мин дә аңа кушыламын
Сагыну сагышы белән.

*2019 елда Балтач районы Көнтүгеш авылында*
*Рәйсә Гыйльметдиновадан «Балтач таңнары» гәзите хезмәткәре*
*Аида Хәйретдинова язып алган*

Калфагым бар, шәлем бар,
Шәл алырлык хәлем бар.
Бу дөньяда ни кайгы бар:
Алма кебек ярым бар.

Уфадан кайткан атларга
Салкын су эчермәгез.
Уф, йөрәккәйләрем яна,
Исемә төшермәгез.

Аклы ситса күлмәгемнең
Якасы уелмаган.
Гомер булса күрешербез,
Кабергә куелмаган.

Кыр казлары китеп бара
Ике билбегә булып.
Бер күреп сөйләшсәң иде,
Икең бер өйдә булып.

Сандугачым, бәләкәйсең –
Гөл төпләренә күмел.
Бәлки, уйламас та идем –
Сабый чакларым түгел.

Сандугачым, бәләкәйсең –
Зураерсың, кагынгач.
Төннәр төннәргә тоташа,
Иркәм, сине сагынгач.

Сандугачлар су эчәләр
Үләндәге чыкларны.
Уйлама, җаным, юкларны,
Уйлыйк бергә чакларны.

Аклы ситса күлмәгемә
Энҗеләр юк тезергә.
Өзелеп сагындым, дускаем,
Мөмкин түгел түзергә.

Басмаларга басам, диеп,
Бастым су эчләренә.
Гомергә дә сүрелмәслек
Төштем ут эчләренә.

Басмаларга бастым, диеп,
Бастым су уртасына.
Мәхәббәткәең кадалды
Йөрәгем уртасына.

Җир җиләге песте, диеп,
Ятып ашамам инде.
Илдә матурлар күп, диеп,
Сине ташламам инде.

Агыйделдә ак пароход,
Буямыйлар ак булгач.
Сагынсам да, күреп булмый,
Арабыз ерак булгач.

Бишмәтләр тектерәсең,
Калмадымы якалык?
Син сөйгәнне мин дә сөям,
Кайсыбызда хаталык?

Текән тауның итәгендә
Кунып, печән эшләем.
Мин китәмен, син каласың,
Ялгыз башым нишләем?

Текән белән Карамалы –
Бар да тимер арбалы.
Синең белән гулять итеп
Бер тиен акча калмады.

Тау астында чишмә ага
Керне агарта торган.
Ике булмый берәү була
Йөзне саргайта торган.

Аклы яулык, күкле яулык –
Яраткан яулыкларым.
Яратмасам, сөймәс идем,
Яратам, җаныкаем.

Җиләк пеште бу айда
Су буенда тугайда.
Мәхәббәт утында янам –
Кушылмагач, ни файда?

Иртән торып тышка чыксам,
Кар яуган көрәгемә.
Мәхәббәтең уклар булып
Кадалды йөрәгемә.

Ак дулкыннар, ак дулкыннар,
Оча ап-ак күбекләр.
Егет белән бер кыз тора,
Таһир-Зөһрә кебекләр.

Алъяпкычың алсу-алсу,
Алсу түгел көрән ич.
Борыласың да карыйсың,
Алларыңда барам ич.

Аклы ситса күлмәгемнең
Балитәкәйләре тар.
Кирәкми кеше ярлары,
Кеше яры – салкын кар.

Җеп эрләдем, җеп эрләдем –
Җебем нечкә, буш була.
Үбәемме, сөямме,
Күңелең ничек хуш була?

Өйдә булса, керер иде,
Өйдә түгелдер инде.
Аның хәзер күңелләре
Миндә түгелдер инде.

Тала беләгем, тала беләгем,
Тулалар иңләгәндә.
Тала беләгем, яна йөрәгем,
Җаныем килмәгәнгә.

*1964 елда Балтач районы Комъязы авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

### 313. Такмаклар

Безнең лавка, матур лавка.
Сатучысы – Миңгата.
Авторитеты төшкән бит,
Безнең урамда ята.

Аклы ситса күлмәгеңне
Кидеңдәмени әле?
Кәләпүш баш, тимер танау
Синеңдәмени әле?

Ике сыер, бер корова
Су эчәләр бәкедән.
Сине уйлап ята идем,
Егылып төштем сәкедән.

Зимагур баеп кайткан,
Капка төбенә яткан.
Баш астына кирпеч салып ,
Чикмән ябынып яткан.

Зимагурга хат язганнар:
«Утын бетте, кайт», – диеп
Хатка каршы хат җибәргән:
«Өй почмагын як», – диеп.

Шырпы кабы, шырпы кабы,
Шырпы кабы бушаган.
Иске Корыч егетләре
Шүрәлегә ошаган.

Өч тиенлек ботинкасын
Көн дә майлаган була.
Чәкүшкәдәй буе белән
Кызлар сайлаган була.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре – Габделбай.
Духи бирәм, дип алдадың,
Кулъяулыкны бир, давай!

Тамчы тама, тамчы тама
Бүрәнә башы чери.
Әйт, акыллым, кәнфит бирәм:
Апаң кем белән йөри?

Ак бүрек, кара бүрек
Кидең ни, кимәдең ни?
Сөйгән ярың читтә булгач,
Сөйдең ни, сөймәдең ни?

Минем иркәм армиядә:
«Атлар эчерәм, – дигән. –
Пока гуляй, заман шулай,
Кайткач, кичерәм», – дигән.

Ак пиманы ник бастырдың,
Ап-ак карда кимәгәч?
Бу йөрәкне ник яндырдың,
Аз гына да сөймәгәч?

Таң! Таң ата. Чулпан калка.
Чулпан таңны ярата.
Әйт, акыллым, кәнфит бирәм:
Апаң кемне ярата ?

Алма пешкән, өзелеп төшкән,
Күгәрчен башын тишкән.
Көн дә кызлар сайлый торгач,
Сачләренә чал төшкән.

Ике тавык, бер курица
Конькида катаются.
Минем йөргән егетләрем
Сезгә ни касаются.

Безнең өйдән клубка кадәр
Тимер юл булса иде.
Аллаһ боерыгы белән
Сөйгәнем килсә иде.

Ботинкасы, ботинкасы,
Ботинкасы сызыклы.
Кеше ярын тартып алып,
Сөюләре кызыклы.

Ак пирчәткәләр кигәнсең,
Ничек кулың тирләми?
Бу кадәрле чибәр булып
Кайда үстең чирләми?

Ботинкасы, ботинкасы,
Ботинкасы лаковый.
Безгә килгән егетләргә
Имән күсәк готовый.

Ботинкасы, ботинкасы,
Ботинкасы ялт итә.
Ышанмыймын сүзләренә,
Сүзләре – политика.

Кара урман артларыннан
Очып килә бер чыпчык.
«Люблю тебя, не забуду», –
Дигән була чукынчык.

Яшел кием ямьсез булса,
Солдатлар кимәс иде.
Аерылу җиңел булса,
Ул безгә тимәс иде.

Басудагы саламнарның
Төбе чери башлаган.
Сәлимә апа сизә микән:
Кызы йөри башлаган.

Минем иркәм – Гөлчабан,
Әйтим авыр булса да.
Агрономга укып кайтты,
Хәзер мөдир мунчада.

Сары-сары, сап-сары,
Сары пычак саплары.
Беребез анда, беребез монда,
Сагындыра башлады.

Һавада очкан кошларның
Канат очлары алтын.
Алтын-көмештән кадерле
Синең җибәргән хатың.

Картлар көтә автобусны
Тауларга менәр өчен.
Егетләр көтә кызларны
Суырып үбәр өчен.

Кипке киям, кипке киям,
Киямен яшеленнән.
Мин дә берне сөям әле
Аларның нәселеннән.

*2001 елда Бакалы районы Иске Корыч авылында*
*Земфира Кашаповадан (1951 елгы) БДУ студенты*
*Светлана Гарифуллина язып алган*

# АФОРИСТИК ИҖАТ

## 314. Мәкальләр

Тирә-ягың яу булсын,
Өй эчең сау булсын.
Көн күрмәгән көн күрсә,
Көндез чыра яндыра.
Дошманнан сакланып була
Дустан Аллаһ сакласын.

*1977 елда Борай районы Абдулла авылында*
*Гыйлемхан таһир улы Таһировтан (1907 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Үлмәс борын үлгәнем –
Дустан яла күргәнем.

Боланның – мөгезе,
Галимнең – сүзе,
Филнең – теше,
Останың эше кыйммәт.

Әйтсәң колакка,
Таратырсың еракка.

Белгәнеңне белдермәсәң,
Белгәнлегең корысын.

Һәр ялтыраган алтын түгел.
Бер галим йөз наданны җиңәр.

Өйрәтмичә белмәссең,
Йөремичә күрмәссең.

Йөргән таш шомарыр,
Яткан таш мүкләнер.

Эчеңдәге серләреңне
Сөйли күрмә дусыңа:
Дусыңның да дусы булыр,
Ул да сөйләр дусына.

Авызың ни әйтсә,
Колагың щуны ишетсен.

Тере сөяк кайда да сыя.
Кешегә үлчәп, күлмәк кисмиләр.
Бүредән курыккан урманга бармас.
Дүрт аяклы ат та абына.
Эшләгән узар, эшләмәгән тузар.
Утсыз төтен булмый.
Жил исми, яфрак селкенми.
Карагайга карап, тал үсәр.
Эттән эт тумый, кош тумас.

Кыйммәтле нәрсәләрдән – акыл,
Гакылсызның бөтен ягы такыр.

Кеше өчен асыл иман-сабыр,
Сабырсызлык башка бәла салыр.

Адәмне сүз боза,
Дөньяны җил боза.

*1977 елда Борай районы Иске Тазлар сигезьеллык мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты түгәрәге әгъзалары җыйган материаллардан БДУ студентлары күчереп алган*

Плансыз эш – тозсыз аш.

Батырлык – матурлык.

Ялкаулык – бәхет дошманы.

Җиреннән аерылган үлгәнче елар.

Бабай күрке мал белән, егет күрке дан белән.

Юньле сакланыр, юньсез мактаныр.

Киң булсаң, ким булмассың.
Күркәм холык – изге юлдаш.
Ерак җыйсаң, якын алырсың.
Сигезне асраганчы, симезне асра.
Акыл айнымас, алтын черемәс.
Ашаган белми, тураган белә.
Ачтан камыр бастырма, туктан казлар астырма.
Дошманның көлгәненә ышанма.
Әрле әрләнгәнче, әрсез ашап туя.
Карт чыпчыкны кибәк белән алдап булмый.
Сакалың белән мактанма, кәҗәдә дә сакал бар.

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Йомран авылында*
*Фәгыйлә Хәлиуллинадан (1901 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Якын күрше ерак туганнан якынрак.
Ике бөркет талашса, бер каргага җим төшәр.
Татлы сүздә дөреслек аз.
Сыйларга сыең булмаса, сыйларга телең булсын.
Киңәшле эш тау ярыр.
Җитмеш җиргә кул сузма.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Венера Фатыйховадан БДУ студентлары язып алган*

Тик тормаган тук торган.
Уты сүнсә дә, кисәве кала.
Суның кадере кое кипкәч беленер.
Диңгезне аршин белән үлчәмиләр.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Суфия Тимашевадан БДУ студентлары язып алган*

Су башыннан болгана.
Кар китсә дә, боз кала.

Урман чытыр белән ямьле.

Суына күрә балыгы.

Еланның башы ашаса, койрыгы тук.

Елан үзе үлсә дә, агуы калыр.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Фатыйма Еникеевадан БДУ студентлары язып алган*

Яхшы ат богаусыз йөрмәс,

Алама атка тышау да тимәс.

Этнең азгыны йортта котырыр.

Җиккән атың җилдәй булсын.

Аты бар батыр, аты юк ятар.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Тәзкия Зиннәт кызы Хазиевадан (1925 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Малың булса, көтүче табыла.

Арыш кибәге алдан оча, бодай кибәге төпкә төшә.

Сирәк тырма төпле була.

Игенченең икмәге күп, бакчачының ашы күп.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Гатилә Дәүләтгәрәевадан (1914 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Азыклы ат арымас.

Ашыккан җитмәс, боерган җитәр.

Акыл айнымас, акыл черемәс.

Асылынсаң, асыл агачка асылын.

Акыл яшьтә түгел, башта.

Бер тарыдан ботка булмый.

Бер курыккан эт өч көн өрер.

Бии белмәгәнгә урын тыгыз.

Биргәнгә биш тә күп, алганга алты да аз.

Барлык өйрәтә, юклык йөдәтә.

Барлык яраштыра, юклык талаштыра.

Көчләп яндырган чыра янмас.

Кайткан малда бәрәкәт бар.

Хак сүз башта ачы була, соңыннан яхшы була.

Яхшылыкка яхшылык белән кайтар.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Ихсан авылында*
*Нәби Акмулов, Арыслан Кәримов, Шәйбәк Акмуловлардан*
*БДУ студентлары язып алган*

### 315. Әйтемнәр

Бүрәнә аша бүре күрә.

Күгәрчен сөте генә юк.

Итекченең итеге булмый.

Салпы якка салам кыстыру.

Юкәгә чөй кагу.

Авызы белән кош тота.

Яманнан ярты кашык аш кала.

Керердән алда чыгарыңны уйла.

Йөрмә әле вакыт уздырып, чабата туздырып.

Тавык та чүпләп бетерә алмаслык.

Сүзгә кесәгә керми.

Җаны теләгән,елан итен ашаган.

Эт белән дә эзләп таба алмассың.

Бу кеше елан аягы кискән.

*1977 елда Борай районы Иске Тазлар сигезьеллык мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты түгәрәге әгъзалары җыйган*
*материаллардан БДУ студентлары күчереп алган*

Уңса – Алладан, уңмаса – бәндәдән.

Әбе килсә, җәбе килми, җәбе килсә, әбе килми.

Тисә – тияккә, тимәсә – ботакка.

Ялкау өмә әйтер, тәмлетамак өмәгә барыр.

Бер кул белән ике карбыз тота алмассың.

Балага эш куш, аның артыннан үзең йөгер.

Эшсез кеше башсыз кала.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Венера Фатыйховадан БДУ студентлары язып алган*

Ике исәп – бер исәп, бер исәп – юк исәп.
Айга карап ай булма.
Тауга менгәч, сусавыңнан ни файда.
Таш ташны эретер.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Суфия Тимашевадан БДУ студентлары язып алган*

Былтыр үлгән ябалак быел башын күтәрер.

Утырган каз урынын белә.

Аптыраткан үрдәк артка чумар.

Аю асра, зыян итмәс.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Фатыйма Еникеевадан БДУ студентлары язып алган*

Бер курыккан куян кырык көн төсеннән чыкмас.

Аю гомергә кул юмас.

Аксак эткә коры кашык, сукыр эткә ул да юк.

Эткә печән салма.

Сукыр тычкан юлга чыкса, тез тиңентен кар.

Этнең йонын уңайга сыйпа.

Этнең җизнәсе күп булыр.

Бәхетле дуңгызның борынында бер ашарлык тизәк йөри.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Хәтми Фәрит улы Хайруллиннан (1909 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Ишәкише беләән.

Җаным тыныч, ярмам – арыш.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Калмаш авылында*
*Гатилә Дәүләтгәрәевадан (1914 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Алманың кызыл булуы беләнмени, эче кортлы булгач.

Аты кешенеке, камыты күршенеке.

Балдан да бала татлы.

Күңел картаймас.

Әмәл хәйләгә мохтаҗ.

Карт чыпчыкны кибәк белән алдап булмый.

Кеше өендә Илья, үз өендә свинья.

Түзгән түл җыяр.

Шикле шикләнер, чикмәнен бөркәнер.

Этнең кодасы булма.

Тотылмаган вор, патшадан зур.

Ит корсак астын бөрми.

Яр ярлыкамый, үзе үтерми.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Ихсан авылында*
*Нәби Акмулов, Арыслан Кәримов, Шәйбәк Акмуловлардан*
*БДУ студентлары язып алган*

## 316.Табышмаклар

Алты егет юлга чыккан,
Алтысы да пәһлеван.
Җиде суктым, җиде типтем,
Уң битеннән чыкты кан.

***(Чабагач белән ашлык сугу)***

Башта актан киенде,
Кара кигәч, сөенде.
Яшел күлмәген киеп,
Миңа су кирәк, диеп,
Сарыларга сабышты.

***(Басуда иген өлгерү)***

Үзе безнең өстә, аяклары күктә.

***(Түбә тактасы)***

Дүрт татар бидрә төбенә атар.

***(Сыер саву)***

*1977 елда Борай районы Кузбай авылында*
*Мансур Хәбир улы Хәбировтан БДУ студентлары язып алган*

Дөбер-дөбер дүртәү,
Әтәч агай икәү,
Хаҗи агай ялгыз –
Ул нәрсә?
***(Сыер)***

Башы – тарак,
Койрыгы – урак,
Аны белмәгән – дурак.
***(Әтәч)***

Мич тулы пирәмәч,
Уртасында – бер калач.
***(Күктәге йолдызлар белән ай)***

Армый-талмый,
Ат артыннан калмый.
***(Арба)***

Үзе бара – эзе юк,
Маңгаенда күзе юк.
***(Көймә)***

Мич тулы пирәмәч,
Уртасында – бер калач.
***(Күктәге йолдызлар белән Ай)***

Әтисе аяк киенгәнче,
Улы Мәскәүгә киткән.
***(Төтен)***

Ап-ак халат кигән,
Башы түшәмгә тигән.
***(Мич)***

Кызыл билбау бәйли дә,
Кыштыр-кыштыр идәндә йөри.
***(Миллек. –*** диал. ***(Себерке))***

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Бибимәулиха Габдулла кызы Халитовадан (1890 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Тимер ындыр эчендә
Сырлы кибән утыра.
***(Бәлеш)***

Өй түбәсендә – вак таш.
***(Йолдызлар)***

Ишекле-түрле йөри дә
Почмакка кереп утыра.
***(Себерке)***

Капка ача да капка артына кача.
***(Җил)***

Меҗе, меҗе, меҗе таш –
Эче – куыш, тышы – таш.
Аны белгән кешегә
Йөз егерме җиде яшь.
***(Самавыр)***

Билли, билли, биллән ат,
Биле нечкә көрән ат.
Тауга менә таймас ат,
Талакласа, үлмәс ат.
***(Кырмыска)***

*1977 елда Борай районы Чишмә-Борай авылында*
*Шәмсинур Миндияр кызы Әхмәтҗановадан (1913 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Метри башлы, мең күзле.
***(Уймак)***

Агачтыр аты, адәм милләте, Ходай кодрәте.
***(Тегермән)***

Ары да чаба карачәй,
Бире дә чаба карачәй.
Тал төбендә тонык суны
Тондырып эчә карачәй.
***(Бөрчә)***

Бәләкәй генә бер мөлде,
Миңа табан карап көлде.
***(Күзге)***

Өч йөз алтмыш алты сыерчык,
Кырык тугыз тубырчык,
Унике аккош, бер торна –
Аны белмичә торма.
***(Көн, атна, ай, ел)***

Яка башында – яшел чук.
***(Үш)***

Морт-морт морткәсе,
Йөз илле баш күркәсе,
Кимерсәң, бар кимеге,
Суырсаң, бар җилеге.
***(Умарта, балавыз)***

Тимер тәкә тау шуа.
***(Гөшле)***

Челтер-челтер итте,
Челтегенә кереп китте.
***(Ачкыч)***

Бәләкәй генә бөкере, бөтен кырны бетерде.
***(Урак)***

Бер бүрек астында дүрт агай.
***(Өстәл)***

Өй әйләнә кыл дилбегә.
***(Мүк)***

Тимер чыпчык, сүс койрык.
***(Инә белән җеп)***

Кырга сыяр, урманга сыя алмас.
***(Тырма)***

Тимерче дә түгел, балта остасы да түгел, үзе – авылда беренче эшче.
***(Ат)***

Кечкенә генә сандыкка бөтен дөнья сыя.
***(Китап)***

Түр башында җылы гармонь, бөтен өйне җылытыр.
***(Җылыткыч батарея)***

Читән аша эт талаша.
***(Җитен эрләү)***

Мич авызында комган, авызын-башын йомган.
***(Песи)***

Кәкре агачта кар тормас.
***(Сыер мөгезе)***

Тат табагач, табагачта бер агач, койрыгы бер колач.
***(Саескан)***

Җәй дә егет, кыш та егет; картайганы юк, гел егет.
***(Чыршы)***

Авызы бар, теле юк,
Сөйләгән сүзенең саны юк.
***(Каләм)***

Дошман күрсә, очар,
Авызыннан утлар чәчәр.
***(Мылтык)***

Баганада яна, күмере юк, көле юк.
***(Шәм)***

Аягы булмаса да, йөрүдән туктамый.
***(Акча)***

Таяк, таяк башында кибет,
Кибет эчендә йөз егет.
***(Көнбагыш)***

Чытыр-чытыр чытырлык,
Чытырлыкта күкәйлек,
Күкәйлектә бүкәйлек.
***(Борчак)***

Ишек төбендә Габдрахман, түрдә түрмән, базда батман.
***(Миндек[1], түшәк, умарта)***

Аю йөгерә бара, йоны коела бара.
***(Тегермән)***

Бәләкәй таудан кар ява.
***(Он иләү)***

Дүрт татар бидрә төбенә атар.
***(Сыер саву)***

Иван агай сузылып яткан,
Балалары тезелеп яткан.
***(Матча һәм түбә такталары)***

Бер тычканда – ике койрык.
***(Чабата)***

Урам аша чыкканда, шакмаклы куъяулыгым төшеп калды.
***(Чабата эзе)***

Ике куллы, ике аяклы, ялгыз гына юл сала.
***(Пычкы)***

Ике башлы, ике куллы, алты аяклы, бер койрыклы,
дүрт колаклы, ике гәүдәле.
***(Кеше белән ат)***

Бәләкәй генә кыз бала, йөрәгенә ут сала.
***(Самавыр)***

Дөбер-дөбер дүртәү, Александр икәү, Федор, мескен, берүзе.
***(Сыер имчәкләре, мөгезе, койрыгы)***

Үзе җансыз, койрыгын борсаң, акыра-акыра чаба.
***(Трактор)***

Бер бөркәнчек эчендә дүрт яшь килен.
***(Өстәл)***

Тәрәзәдән керә, ишектән керми.
***(Кояш)***

[1] Миндек *(диал.)* – мунча себеркесе.

Аттан биек, эттән тәбәнәк.

***(Ияр)***

Бер тәпәндә – ике төрле бал.

***(Йомырка)***

Өй артында дүрт бүре,
Дүртесе дә күк бүре –
Күтәрелде, бәрелде, ярылды.

***(Тәрәзә капкачлары)***

Агач, агач саен табак,
Табак саен кибет,
Кибет саен күлмәкле егет.

***(Көнбагыш)***

Актыр үзе, югары җем-җем итеп тора:
– Бүген таңда килмәсәң, китәм, – диеп утыра.

***(Йолдыз)***

Алтын-алтын яфрак,
Яткан җире – туфрак,
Алтын белән абалаган,
Көмеш белән сабалаган.

***(Кыяр)***

Баш астында баллы кашык.

***(Йокы)***

Бикле келәт эчендә – алтын ком.

***(Мәк)***

Борынга керә, кулга тотылмый.

***(Ис)***

Вак кынадыр үзләре, ялтырыйдыр күзләре.

***(Йолдызлар)***

Ике мөгезе, алты аягы,
Берсенең дә юктыр тоягы.

***(Кысла)***

Иләк-иләк тарым бар, күтәрә алсаң барып ал.

***(Кырмыска оясы)***

Канатсыз, йонсыз нәрсә оча.
***(Җил, давыл)***

Иртә белән чыга, кичен югала, аның урынына иптәше кала.
***(Кояш, Ай)***

Караңгы бүлмә, караңгы бүлмәдә ашъяулык бәйли кыз бала.
***(Бал корты)***

Кар астында кышлаган, бүркен яшел тышлаган.
***(Уҗым)***

Кеше дә түгел, эт тә түгел, ә үзе тешли.
***(Суык)***

Кечкенә генә таш пулат, ишеге дә юк, тәрәзәсе дә юк.
***(Йомырка)***

Кич җиргә төшә, төнне җирдә үткәрә, иртә белән тагын югала.
(***Чык)***

Котыра да үкерә, барлык җирне тутыра.
***(Буран)***

Кулсыз-аяксыз тәрәзә кага, тавышсыз җырлый, өйгә керергә сорый. ***(Җил)***

Күтәреп була, өй аркылы ыргытып булмый.
***(Мамык)***

Мине һаман сорыйлар, көтәләр, ә күренсәм, кага башлыйлар.
***(Яңгыр)***

Мөгри-мөгри мөгрәгән, мөгезен күккә терәгән.
***(Төтен)***

Озын агач башында игәй-мигәй бау ишә.
***(Колмак)***

Чикмәнле бавырсак, аны белә һәр корсак.
***(Бәрәңге)***

Урманда кара, юлда ала-кола, өйгә кайткач, агара.
***(Юкәгач)***

Ямавы бар, җөе юк.
***(Ала сыер)***

Агач та түгел, ботак та түгел, үзе агачта үсә.

***(Кайры)***

Чуар киемле урам малае,
Борчак җыя, кырда куна.

***(Ала сыер)***

Элек үзе судан туды, хәзер үзе су тудыра, ак мамык кебек, үзе алмаз кебек.

***(Пар)***

Үзе үләксә, һәркем ашый... эләксә.

***(Балык)***

Өч озын, өчесе дә бик озын.

***(Юл, су, төтен)***

Ашаганда, тимер ашый; сулыш алса, ут уйната.

***(Пушка)***

Өй артында дарым бар, күтәрә алсаң, барып ал.

***(Туфрак)***

Җир иңгән җирдә – шома пыяла.

***(Су өсте)***

Ак җир – кара тары, кем чәчсә – шул урыр.

***(Язу)***

Кат-кат катлама, акылың булса, ташлама.

***(Китап)***

Бәләкәй куныда аш тәмле.

***(Чикләвек)***

Бер бүректә – кырык ямау.

***(Мунча ташы)***

Икесе басып тора, икесе ятып тора, берсе йөреп тора.

***(Ишек)***

Берсе: «Акны яратам», – ди,
Берсе: «Караны яратам», – ди,
Өченчесе: «Миңа бар да бер», – ди.

***(Чана, арба, ат)***

Сузылып керер, түргә менеп утырыр.
***(Суык)***

Үзе түгәрәк, эче тулы күзәнәк,
Әчкелтем-тәчкелтем, барлык нәрсәдән тәмлерәк.
***(Лимон)***

Мине ашамыйлар, миннән башка туй да ясамыйлар.
***(Тоз)***

Чытыр-чытыр чытырман –
Чытырманга керә алмыйм,
Ак белән бурлаган,
Көмеш белән сырлаган.
***(Китап)***

Бәләкәй генә бер әби тау шуа, тау шуа.
***(Тарак)***

Чуар йомшак күлмәге, тотсаң уңа бизәге,
Тоттырмый китә очып, я кала җиргә посып.
***(Күбәләк)***

Метегән, метегән, ак җеп белән метегән, кара белән метегән.
***(Кул тамырлары)***

Өй түбәсендә аю бии.
***(Төтен)***

Җанлыдан җансыз туа.
***(Йомырка)***

Торса – дөядәй, ятса – куяндай.
***(Чыбылдык)***

Алсаң – күбәя, кушсаң – әзәя.
***(Чокыр)***

Ал тегермән ташы
Гөл тегермән ташы,
Аны белмәгән кешенең
Йөз егермедә яше.
***(Икмәк)***

Чүрәкәй үрдәк чума бара,
Артыннан боз туңа бара.
***(Киндер сугу)***

Бәләкәй генә чүлмәгем, эче тулы чумарым.
***(Чикләвек)***

Ук-ук, ук өстендә чук,
Чук өстендә кибете.
Кибетенең өстендә
Өч йозаклы егете.
***(Мәк)***

Уфадан килгән фил
Уртасында – тасма тел,
Акылың булса, уйлап бел.
***(Үлчәү)***

Биле-биле билән ат,
Биле нәзек көрән ат,
Тауга менсә, таймас ат,
Табыкласа, үлмәс ат.
***(Кырмыска)***

Инәләре сузылган,
Балалары тезелгән.
***(Түбә такталары)***

Кара сыерның кабыргасы тишек. Ул ни?
***(Мичкә)***

Бер мичкәдә кырык кыршау.
***(Ызба)***

Тышы яшел, эче бал,
Эчендә балалары бар.
***(Карбыз)***

Аркылы да торкылы,
Бер бабайның ындыры.
***(Тәрәзә рамы)***

Дөбер-дөбер дүртәү, Александр икәү, Иван берәү. Ул нәрсә?
***(Сыер саву)***

Яшел казның башы таз.

***(Себерке)***

Төпсез чиләктә ит тулы.

***(Йөзек)***

Ызба артында дүрт бүре,
Дүртесе дә күк бүре.

***(Тәрәзә капкачы)***

Олы абзардан – кече абзарга:
«Һәч түбгә, һәч түбгә!»

***(Мич тарту)***

*1970 елда Чакмагыш районы Бәшир авылында Заһира Кирамовадан (1905 елгы) БДУ студентлары язып алган*

Ике кара кызым бар,
Өйдән-өйгә йөрерләр.

***(Күзләр)***

Аты аранда, коерыгы яланда.

***(Юл)***

Аягы әллә ничә булса да, кырдан аркасына ятып кайта.

***(Тырма)***

Мич астында – юеш бозау.

***(Тел)***

Мөгезеннән тоталар, аяк белән йөртәләр.

***(Велосипед)***

*1970 елда Чакмагыш районы Яңа Калмаш авылында Шәмсинур Насыйбуллинадан (1912 елгы) БДУ студентлары язып алган*

## 317. Сынамышлар

Песи пичкә керсә – көн суыта, песи идәнгә ятса – көн җылыта.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында Зиннәтулла Шәймөхәммәтовтан (1892 елгы) БДУ студентлары язып алган*

Песи тырнашса, буран булыр.

Сукыр чебен күп булса, кышын суык була.

Кырмыскалар канатланса, яңгыр була.
Сыерчык кара кисә, карабодай уңар.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Бибинур Нәҗметдиновадан (1907 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Һавада аҗаган уйнаса, иген уңар.
Яшен еш булса, баланны кырау алыр.
Кузгалак күп булса, кыш җылы килер.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Бибикамал Хәертдиновадан (1902 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Песи тырнашса, буран булыр,
Песи тырнашса, яңгыр көт.
Торналар биек узса, көн әйбәт була.
Җәен сукыр чебеннәр күп булса, кышын суык булыр.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында Гөлҗамал Әхмәлетдин кызы*
*Әхмәтдиновадан (1914 елгы) БДУ студентлары язып алган*

Кояш иртән кып-кызыл булып чыкса, я бик эссе, я яңгыр була.

*1977 елда Борай районы Кузбай авылында*
*Мансур Хәбир улы Хәбировтан (1893 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Песи мич башына менсә, көн кинәт үзгәреп, салкынаеп китә.
Яңгыр яварга булса, корт умартасыннан чыкмый.
Кырмыскалар канатланса, яңгыр явасын көт.
Урманда миләш күп булса, көзен пычрак була.
Эт аунаса, буран була.
Урманда талпан күп булса, ашлык уңа.
Бүрәнәгә кар ябешеп яуса, ашлык уңар.
Вакыты җитми күк күкрәсә, агач яфрак коймый.
Кыйбла яктан күк күкрәсә, агач яфрак коймый,
Ай чалкан туса – аяз була, ай кырын туса – яңгыр була.
Песи мич башына менеп ятса, көн суыта.

Кич аязган, һич аязмас.

Карлыгачлар түбән очса, яңгыр булачак.

*1977 елда Борай районы Кузбай авылында*
*Маһира Исламовадан БДУ студентлары язып алган*

### 318. Ышанулар

Өй салганда, почмагына көмеш акча салып калдыралар. Көмеш акча салсаң, өй иялэнә, ди. Көзге салып калдыралар – ул нигез матур торсын өчен.

Ипи кискәндә, ипинең өске ягын уң якка куеп кисәргә кирәк. Бу ризык өетенә ризык килеп торсын, дигән мәгънәне аңлата.

Аяк киеме кигәндә, урындыкка утырып киенергә кирәк. Башта уң аякка, аннан сул аякка кияләр.

*1977 елда Борай районы Гомәр авылында*
*Миңсафа Әкрамовадан (1916 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Басуда кәтмән белән кәтмән бәрелешсә, яңгыр яварга була.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Зиннәтулла Шәймөхәммәтовтан (1892 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Куян елында мәшәкатьләр бик күп була. Ни өчен «куян елы» дигәннәр? Бу елны аяз көннәр күп була. Бал күп була. Бал корты күп була. Куян шуларның безелдәгән тавышына тыз-быз чабып йөри. Шуңа куян елы бик мәшәкатьле була. Елкы елы – әйбәт ел. Байлык була.

*1977 елда Борай районы Кузбай авылында*
*Мансур Хәбир улы Хәбировтан (1893 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Җомга көнне башланган яңгыр бик озакка сузыла.

Меңдәр караваттан авып төшсә, кунак килә.

Песи кайсы якка карап юынса, шул яктан кунак килә.

Тупсага басып керсәң, бәхетсез буласың.

*1977 елда Борай районы Кузбай авылында*
*Маһира Исламовадан БДУ студентлары язып алган*

Салават күперенең яшел төсе нык беленсә, алдагы көннәрдә яңгыр булачак; зәңгәр төсе ачык беленсә, көннәр аяз торачак; ә кызыл төсе нык беленсә, ут ява.

Салават күпере сазга төшсә – яңгыр явачак, тауга төшсә – аяз булачак.

Козгын кычкырса, алама хәбәр булачак; аның кычкыруын ишетү белән: «Изге хәбәр китер, әйбәт хәбәр китер, авызыңа бал да май», – дип әйтергә кирәк.

Юлны песи киссә – юл уңмый, эт киссә – юл уңышлы була.

Үлгән хайваннарның үләксәсен җиргә күммәсәң, алар мәет теләп ята, йортка үлем киләчәк.

Песи үләксәсен ихатага күмергә ярамый, ихатада песи сөякләре булса, хуҗалыктагы малларга зыян килә.

Кош оясын туздырсаң, кош каргый, дөньяң актарыла, ут чыга.

Кошлар каргагач, кешеләр чирли һәм үлә.

Бака үтергән кешенең сыерының сөте бетә яки әнкәсенең күкрәге шешә.

*(2017 елда Илеш районы Илеш районы Рсай урта мәктәбенең туган якны өйрәнүчеләр түгәрәгенең архивында саклanучы Шәмсури Мөхәмәтҗан кызы Камалова истәлекләреннән (1911 елгы, Йонны авылында туган) БДУ студенты Ләйсән Вәлиханова күчереп алган*

### 319. Юраулар

Төшеңдә коры йөзем күрсәң, дәүләт китә.

Төшеңдә кара йөзем күрсәң, мәшәкать күрәсең.

Төшеңдә чи йөзем күрсәң, мал табасың, әйбәт була.

Төшеңдә хәлвә күрсәң, кеше зурлый, олылый.

Төшеңдә ак кием һәм күк кием күрсәң, әйбәт була.

Сары кием күрсәң, кайгы була, кызыл кием дә әйбәт түгел.

Төшеңдә кош күрсәң, рәхәт торасың.

Төшеңдә тире тун күрсәң, малларыңнан файда күрәсең.

Төшеңдә резинка итек күрсәң, егетеңнән аерыласың.

Төшеңдә ат өстенә менү яхшы була.

Төшеңдә саескан күрсәң, кияүгә чыгып кыз бала табасың.

Төшеңдә болан күрсәң, бик әйбәт була.

Төшеңдә елан тотып күрсәң, кулыңа мал керә.

Төшеңдә күгәрчен яки куян күрсәң, хәлле егеткә барасың.

Төшеңдә кар яки су күрсәң, үзеңә чир була.

Төшеңдә сарык ите күрсәң, кайгырасың.

Төшеңдә итле аш ашасаң, хәрәмнән мал керә.

Төшеңдә уң кулың сынса – агай-энеңнән кеше үлә, сул кулың сынса – малларыңа зыян була.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Шәмси Каюм кызы Гариповадан*
*БДУ студентлары язып алган*

**Таш белән юрау**

Ташлар белән үзләренең теләкләре тормышка ашамы-юкмы – шуны юраганнар. 41 вак ташны җиргә чәчеп җибәргәннәр. Якынрак ятканнарын өч урынга җыйганнар һәм ташларны парлап чыкканнар.

Мәсәлән, бер кыз баланың яңа күлмәк киясе килә яки хат киләчәкме, юкмы? Чирле энекәше тереләчәкме? Шушылар тормышка ашамы-юкмы икәнен белер өчен, ул 41 ташны чәчеп җибәрә. 3 урынга җыйгач, бер урында – 16 таш, икенче урында – 9, өченче урында – 16 таш. 16 ташны парлап чыккач, артыгы калмый, димәк аңа күлмәк көтәсе юк, энекәшнең терелүе дә өметсез. Ә тугыз ташны парлап чыккач, берсе артып калды, димәк, хат киләчәк.

*2017 елда Илеш районы Илеш районы Рсай урта мәктәбенең*
*туган якны өйрәнүчеләр түгәрәгенең архивында саклanучы*
*Әбүбәкер Харис улы Галиев истәлекләреннән (1919 елгы, Рсай авылында*
*туган) БДУ студенты Ләйсән Вәлиханова күчереп алган*

## ЙОЛА ИҖАТЫ

ӨМӘЛӘР

### 320. Тула өмәсе

Тула эрләнгән йон җебеннән сугыла. Өмәгә кызлар җыелалар, егетләр дә була. Тула сугылып беткәч, бик зур табын әзерлиләр. Өстәлгә аркылы-торкылы итеп дилбегә бәйлиләр, туланы басар өчен. Шуннан соң туланы кайнар су белән басалар, тәмам киезләнеп беткәнче. Бер-ике сәгать баскач, егетләр белән кызлар парлап-парлап җырлыйлар.

Пример:

*Басабыз да басабыз,*
*Була микән тулабыз.*
*Булса булыр, булмаса юк,*
*Җыелышып кунабыз.*

*Машина әйләнә бушка,*
*Ялгыз әйләнә кушка,*
*Бер иптәшне аласың да*
*Чыгып керәсең тышка.*

*Быел салган бурагызның*
*Буятырсың ашасын.*
*Мин сиңа булалмам инде,*
*Иркәң миңа охшасын.*

Бу җырлар туланы борырга чыккач җырлана. Шундый җырлар җырлыйлар да, кереп, тагын баса башлыйлар. Тула өлгерә башласа, хуҗа хатын аш әзерли. Аштан соң һәркем үз өенә тара-

ла иде, ә кызларны ата-анасы килеп алалар. Тула өмәсе көз көне үткәрелә торган иде.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Ихсан авылында колхозчы-пенсионер Нәби Моратовтан БДУ студентлары язып алган*

### 321. Тула басу

Агач сәкегә утырасың. 4–6 кеше утырып язасың. Басасың-басасың да алты кеше – тула керсен, дип басасың. Такталар ярыла, аннары туланы елга буена төшеп юасың.

*Тула өмәсенең җыры да була:*
*Әй тула ул, тула ул,*
*Тула тупа була ул,*
*Кызлар кич йөр(е)гән чакта*
*Төрле хәлләр була ул.*

Егетләр килгән була иде. Качып кына уйный идек. Яулык бәйләтә идек егетләргә. Болай дип җырлый идек:

*Биек тауга арпа чәчтем,*
*Чыпчык чүпләп бетерде,*
*Бәләкәй генә егетемне*
*Тәкә сөзеп үтерде.*

*1977 елда Борай районы Абдулла авылында Фәрхикамал Мөзиповадан БДУ студентлары язып алган*

## ГАИЛӘ-КӨНКҮРЕШ ЙОЛАЛАРЫ

### 322. Туй йоласы

Элек булган хәлләр инде бу. Менә бервакыт кияүне көтәбез. Аны атка утыртып, төрле җирләрдән йөртеп алып киләләр. Кыз келәттә көтеп тора.

Келәт алдына халык җыела, кулларында герләр, таяклар. Менә атлар кайтып җитте. Кияү кеше олы толып кигән. Ул ничек тә суктырмаска, сакланырга тырыша. Аңа йодрыклар, герләр, таяклар белән сугалар. Кияү кеше халыктан көч-хәл белән котылып, келәткә кереп китте.

Шулай алар 3–4 көн торалар. Алар янына билгеләнгән бер кеше генә керә ала. Ул аларга коймак пешереп кертә. Бу кешегә кияү көзге, кершән, яулык кебек бүләкләр бирә.

*1977 елда Борай районы Абдулла авылында*
*Хөсникамал Низаметдиновадан (1910 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

Туй вакытында кунак күп чакырыла иде, аш-су мул әзерләнә. Кияү белән кыз аерым өйдә дүрт кич куналар. Алар янына кеше керми, җиңгиләр ашарга гына кертеп чыгалар. Дүрт көндә дә иртән иртүк мунча ягыла. Кияү белән кыз караңгыда ук мунча кереп кайтырга тиешләр. Кияүләр мунча саен акча салып чыгалар.

Кодалар, кунаклар икенче өйдә бик күп булалар. Бирнә бирәләр, көче җиткәнчә һәр кешегә бүләк бирергә тырышалар.

Кияү бер бәләкәй сандык белән тутырып вак бүләкләр алып килә: сабын, кершән, пәке, ун тиенлек акча, бадыян. Һәркөн иртән кызлар кияүгә коймак китерә, кияү аларга бүләк бирә. Кияүләр кеше китергән коймакны ашамыйлар иде.

Кияүгә кием әзерлиләр иде. Кем ничек булдыра ала. Өч, дүрт, җиде кат кием әзерләүчеләр дә бар иде. Төрле җепләрдән сугып әзерлиләр иде ул киемнәрне. Оек-бияләй бәйли идек.

Кияүне озаталар. Кыз исә бер ел үткәч кенә барырга мөмкин кияү йортына. Кияү унбиш көнгә бер килеп китә иде.

Кызны озатыр вакыт җитә. Кыз озатканда, ирле-хатынлы арчи булып баралар. Алар кызга бүләк алып баралар. Бертуган абыйсы кызны арбага җитәкләп утырта, үзеннән кызга бер сарык әйтеп куя. Барып җитәләр кияү йортына. Күтәрмә төбендә бер сарык тора, аңа бер тастымал салып, килен кереп китә. Килен мендәргә төшәргә тиеш. Аннан кияү җитәкләп өйгә алып керә, икәү дога кылалар.

Ашка җыйган җирдә биатай белән бианайга бүләк бирәләр. Алар исә киленгә сыер, я ат әйтәләр. Беләзекләр, тәңкәләр, көмеш каптырмалар салалар киленгә. Киленнең әйберләрен өйгә кертәләр.

Килен бер кыз белән суга бара. Ул кызга я күкрәкчә, я яулык бирә килен.

Арчилар дүрт кич кунып кайтып китәләр. Кияү белән кыз аларны басуга кадәр озатып бара.

Кияүнең әтисе янында олы яулык бәйләп, йөзне каплап йөри килен. Бергә ашамыйлар, сөйләшмиләр. Соңыннан бераз ияләшә башлый килен.

Туй менә шулай күңелле генә үтеп китә инде.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Шәмсә Каюм кызы Гариповадан*
*БДУ студентлары язып алган*

Туйлар була иде инде, балакаем, менә болай: егет кызны күрми, кыз егетне күрми.

Егетнең кияү була аламы-юкмы икәнен сынийлар иде: егет кызны бер ел буена яучыларга тиеш. Ләкин аның күзенә күренми. Бер ел буена хәтта кызның әти-әнисе дә күренмәскә тиеш. Шушы бер ел эчендә төрле юллар белән егетнең түземлеген сынийлар, кайвакытта хәтта тукмак белән кыйныйлар. Егет шушы сынауны уңышлы үтсә, бер елдан соң кызның әти-әнисенә күренергә хаклы. Шуннан соң гына, ата-аналар җыелышып, никах укыйлар. Туй, гадәттә, дүрт көнгә сузыла. Ләкин хуҗалар бик тә хәерче булса, ике көндә дә бетерергә мөмкин.

Туйлар кызлар өчен бәхетсезлек алып килүче йола иде иске вакытларда. Чөнки яратмаган кешесенә, үз ризалыгыннан башка бирәләр иде. Күп вакытта егетләрне бай җиңгәсенә өйләнергә мәҗбүр иткәннәр, әгәр дә абыйсы үлгән булса. Япь-яшь кенә кызларны 60–70 яшьлек картларга бирәләр иде, күп вакытта җизнәсе балдызын ала.

*1977 елда Борай районы Бустанай авылында*
*Әхмәтсафа Закировтан*
*БДУ студентлары язып алган*

### 323. Кода белән кодача арасында әйтеш

***Кода:***
*Кода күңелен кодача*
*Ачмаса кем ачар?*
*Кода моңарча кызмаса,*
*Кодачасыз эш начар.*
*Кодачам булмаса*
*Алларымда тормаса.*

***Кодача:***

*Саумы кода, иминлекме,*
*Ни бетереп йөрисең?*
*Вакытларың бик тар мәллә,*
*Бер дә килеп йөрмисең?*
*Юк, кодам Ямалый,*
*Алай он(ы)ту ярамый.*
*Үзең беләсең чаманы,*
*Якынайтыйк араны.*

**Кода:**

*Син димәгән сылуым юк,*
*Ни сөйлисез кодача? –*
*Күз тия генә күрмәсен,*
*Гөр килдек бит моңача.*
*Кодачам Майбәдәр,*
*Чәчрәп китим әгәр,*
*Теләсәң, кыламын сәфәр*
*Җәһәннәменә кадәр.*

**Кодача:**

*Кабаланмый җайлап кына*
*Бер мәслехәт кылыйк без.*
*Бер җай чыгып тора, кода,*
*Уйлашкандай булыйк без.*
*Тик, кодам Ямалый,*
*Кабаланмый ярамый,*
*Болгатмасыннар араны,*
*Сак була күр, кара аны.*

**Кода:**

*Әйтеп кара йомышыңны,*
*Син дигәндә нәүбәттә,*
*Корбан кылам башкаемны*
*Син дигәндә, әлбәттә.*
*Әйт йомышың, кодача,*
*Тыңладым бит моңача –*
*Кода, кодача булмаса*
*Яши алмый, ләбаса.*

*1964 елда Балтач районы Комъязы авылында*
*БДУ студентлары язып алган.*
*Информатор күрсәтелмәгән*

### 324. Аулак өй

Берәр кызның әтисе-әнисе кунакка китсә, шул өйдә яшьләр җыелып, аулак өй ясаганнар. Урын ашы пешергәннәр. Җәмилә әби бер кызларда аулак өй үткәрүе турында сөйли:

Болар каз пешергәннәр. Казны, пешкәч, мич башына яшереп куйганнар. Боларның яшергәнен бер егет күреп торган. Икенче бер егет белән сүз берләшкән дә, кызларны алдатып, биергә кушкан, ә үзе кызлар биегән арада казны урлаган. Теге биюче егет бу егетнең урлаганын күргән дә такмаклап биегән, ди:

*Элдер, абзый,*
*Элдер, абзый,*
*Булдыр, абзый!*
*Булдырдың, элдердең,*
*Булдырдың, булдырдың!*

Кызлар теге егетнең такмаклап биегәненә һушлары китеп, карап тик утырганнар.

*1977 елда Борай районы, Чишмә-Борай авылында*
*Җәмилә Вәлинур кызы Газизовадан (1913 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

ИМ-ТОМНАР

### 325. Күз тигәндә төтәсләү

Бер гөмбә алына, иске-москы чүпрәк, шырпы алына. Һәм шушы гөмбәгә иске-москы чүпрәкне урап, шырпы белән төтәсләп, күз тигән кеше алдында йөриләр. Төтәсләгәндә, шушындый сүзләр әйтә: «Төтәс, төтәс хатыннан, кыздан, зәңгәр күздән, кара күздән, яшел күздән, җегетләрдән, кызлардан, картлардан, яшьләрдән – тфү, тфү; урыстан, марҗадан – тфү, тфү. Бетсен китсен – тфү, тфү!

### 326. Күз тигәндә өшкерү

Бисмиллаһи шаһи,
Бисмиллаһи кафи,
Бисмиллаһи мәгафи.
Бисмиллаһи әлләзи.

Ләизҗире, ләизҗир мәгаисмеһе шайән фим арис вәләфи сәнаи вәһхә сами әнгам.

### 327. Чирне өшкерү

Кирәлхәм бисмиллаһи мәрмүн, бисмиллаһи зар зур, бисмиллаһи хапка бур, бисмиллаһи сатса зур, заһуранди маһуран, бисмиллаһи мәнҗәлә, вәсихи фәнзәлә, аллаһуа яманга, китәр булсаң кит, мәлгунь!

*1970 елда Чакмагыш районы Тозлыкуш авылында*
*Рәкыя Исламовадан (1910 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 328. Дәвалаганда әйтелә торган сүзләр

Җир анасы җирән сакал, су анасы дәван сакал,
Җир кендеге җирән ат, каян килдең, шунда кит!
Илеңә, көнеңә, җиреңә, суыңа – тфү, тфү.

### 329. Елан им-томы

Чәңки-чәңки, чәңки елан,
Чәңки башлы кара елан,
Агуын сузган рауан елан,
Сәни елан, фән елан, пух.
Пигамбәрнең хакы-хөрмәте
Өчен яткан җирдән тибрән елан.

### 330. Уа догасы

Каты чыккан агачны уа очкыны ашап, йолдыздай, болыттай очып китсә, туфрактай туздырса; җитмеш җиде диңгезнең аръягында карчыга бар, канатлары күккә чыккан, томшыклары җиргә чыккан – ул карчыганы кайчан чәнчеп, ашап бетерсә; сөяк саплы пычак белән җитмеш җиде аршин буй-буй тамырны буын-буын кылып, парә-парә китереп җитмеш ике төрле коры сөякне уа ашап бетерсә дә, бу бәндәне ашамасын.

*1977 елда Борай районы, Кодаш авылында*
*Нәгыймә Хәсәнҗан кызы Суфияновадан (1906 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

ХАЛЫК УЕННАРЫ

## 331. Үрдәк атыш

Уен барышы болай. Зур түгәрәк сызалар. Шул түгәрәкнең эчендә 20-30 «үрдәк» була. Бу түгәрәкнең читендә унбишләп «үрдәк» була. Шуннан күл буенда – төньякта һәм көньякта ике «аучы» була. Бу ике «аучы» түгәрәк эчендәге «үрдәк»ләргә туп белән ата башлый. Күл эчендәге туп тигән «үрдәк»ләр уеннан чыга торалар, тимәсә, икенче яктагы «аучы» тиз генә тупны эләктереп ала да, күл эчендәге «үрдәк»ләргә бәрә.

Шулай итеп, бу ике «аучы» 20–30 «үрдәкне» атып беткәнче аталар. Уен, күл эчендә бер «үрдәк» калганчы, шулай дәвам итә. Хәзер шушы ялгыз «үрдәк»кә ун тапкыр аталар, әгәр дә тимәсә, бу «үрдәк» герой булып кала, һәм теге атылып чыккан «үрдәкләр» бу «күл»гә кире керәләр. Бу очракта теге ике «аучы» җиңелә, һәм уен шулай дәвам итә.

## 332. Песи белән тычкан

Уен барышы. Түгәрәкләнеп басалар, кулга-кул тотынышып. Бер бала –«тычкан», икенчесе «песи» була. Хәзер «тычкан»ны «песи» бастыра башлый. Түгәрәкләнеп торган җирдән балалар «мәче»не кертмиләр. Ә «мәче» үзенең сизгерлеге аркасында түгәрәк эченә кереп тә китә ала. Шулай итеп, «тычкан»ны «мәче» тотканга кадәр дәвам итә һәм, әгәр «песи» «тычкан»ны тотса, икенче бер уйнаучылар арасыннан «песи», «тычкан» сайлана һәм уен шулай дәвам итә.

## 333. Шпион

Уен барышы. Ике группа алына, тигез сандагы уйнаучылар белән. Бер чыбык алалар һәм, һәр группадан бер кеше сайланып алга чыга – алар бу чыбык белән тотамлашалар. Кайсысы өскә чыга, шул группа кача, икенче группа «качкын»нарны эзли. Икенче группа уйнаучыларының кулларында «мылтык» була. Шуннан болар эзләнүче группа кешеләрен «атып» бетсә, җиңүче була. Кайсы группа җиңә, шулар кача, ә җиңелүчеләр эзләүче була. Уен шулай дәвам итә.

## 334. Аксак мәче

Уен барышы. Уйнаучылар ничә булсалар да, тезелеп утыралар. Аларның арасыннан берсе чыга да, «әни» була. Ул уенчыларның һәрберсенә исем кушып чыга – буяу исемнәре. Хәзер «аксак мәче» ишек шакый. «Әни» әйтә:

– Ишек төбендә елан бар.

«Аксак мәче» чатанлый-чатанлый атлап керә, тиз керергә тиеш иде инде, чөнки тиз кермәсә, аны «елан» тотып ала. «Елан» булып, ишек төбендә бер уйнаучы ятарга тиеш инде. Шуннан «аксак мәче» үтеп кергәч сорый:

– Миңа кызыл буяу бир әле.

Ә «әни» исемнәрне элек кушкан иде бит инде, шунда ук «кызыл» исемле уйнаучы чыгып чаба. «Аксак мәче»дән, аксак булса да, бик сизгерлек сорала. Чөнки, ул тагын теге ишектән чыга алмаска мөмкин. «Елан» аңа тагын комачаулый. Чыгып китә алса, теге «буяу»ны бик нык бастыра һәм тота алса – тота; тота алмаса – барыбер «аксак мәче» булып кала. Ә тота алса, теге тотылган кеше «аксак мәче» була, һәм уен шулай дәвам итә.

## 335. Граница алыш

Ике кеше бер пар була, һәм бу уенда ничә кеше булса да катнаша ала. Мәсәлән, бу ике пар бер-берсенә: «Син «йорт» бул, ә мин «үлән» булам», – дип килешеп, үзләре сайлап куйган ике кеше янына баралар. Алар шушындый сүзләр әйтәләр:

*Әтки, мәтки,*
*Сәвә сәтки –*
*Үләнме, йортмы?*

Кайсысы үзләренә ошый, бу сайланган ике кеше шуларны үзләренә тартып ала. Шушылай, бу ике кеше янына бик күп пар килә, һәм алар үзләренә ошаганын сайлап алалар. Хәзер ике группа барлыкка килә. Болар бер граница сызалар, һәм һәр группа, берсе артыннан икенчесе тотынышып, шушы граница янына килеп туктыйлар. Берсе бер якка тарта, икенчесе икенче якка тарта. Кайсы группа үз ягына тартып чыгара, шул җиңүче була, һәм уен шулай дәвам итә.

### 336. Энә белән кое казу

Бу уенда «әни» һәм аның «бала»лары, бер «әби» катнашалар. Бер «кое казучы» «әби» була. Ул энә кебек бер нәзек һәм кыска гына чыбык белән кое казый. Бу «әби» янына «әни» һәм аның артына ябышкан балалары килә. Алар шушындый сүзләр әйтә:

«Әни»:

– Әби, нәрсә казыйсың?

«Әби»:

– Энә белән кое казыйм.

«Әни»:

– Ул коены нишләтәсең?

«Әби»:

– Таш тутырам.

«Әни»:

– Ул ташны нишләтәсең?

«Әби»:

– Менә, синең балаларың бакчама керә, шуларны таш белән бәреп үтереп бетерәм.

«Әни»:

– Балаларым, керәсезмени, бәй?

«Балалар»:

– Юк-юк-юк, әни, алдый ул, кергәнебез юк.

«Әби»:

– Ә сез шулаймыни әле, – дип, сикереп тора да балаларны тотарга маташа.

Ә «әни кеше» үз балаларын үзе сакларга тиеш бит инде. Уен шулай «әби» бу балаларны тотып алганга тиклем дәвам итә.

### 337. Чокыр туп

Кечкенә итеп, бер чокыр ясала, ничә чокыр ясалса, шунча кеше катнаша. Бер кеше артык була инде, аның чокыры булмаска тиеш. Ул тупны ала да чокырларга таба тәгәрәтеп җибәрә. Хәзер туп кай чокырга барып төшсә, шуның «хуҗасы» тиз генә тупны ала да: «Стоп!» дип кычкырып җибәрә. Бу кычкырганга тиклем, теге чокыр караучылары тиз генә төрле якка йөгерешәләр. Ә тупны алучы: «Стоп!» – дип кычкыргач, төрле

якка китә алмыйлар. Кайда басканнар, шунда торып калалар. Тупны тотучы берәр уйнаучыга бәрә; туп тисә, теге уйнаучы үз чокырын туп аткан кешегә бирә. Аннары уйнаучылар кире үз чокырларына җыелалар, һәм теге чокырын биргән уйнаучы тупны чокырларга таба тәгәрәтә. Уен шулай дәвам итә.

### 338. Качкалак

Ничә кеше булса да катнаша ала. Уйнаучылар арасыннан берсе гөрелди. Ул гөрелдәгәндә, калганнары төрле якка качышып бетәләр. Гөрелдәгән вакытта теге шушындый сүзләр әйтә:

*Гөр-гөр-гөр әтәч,*
*Ике тавык бер әтәч, –*

дип, ун тапкыр кабатлый һәм азак качучыларны эзли башлый.

Шуннан соң тегеләрне таба да, үзенең гөрләгән җиренә килеп төкерә. Шуннан гөрелдәүче качкан кешеләрнең барысын да тотып китерә һәм, иң беренче кемне тапкан – шул кеше гөрелдәп кала. Уен шулай дәвам итә.

*Бу уеннарны 1970 елда Чакмагыш районы Тозлыкуш авылы балалары Наил Янгиров, Әхәт Галиев һәм Рамил Арзамасовтан БДУ студентлары язып алган*

### 339. Наза

Караңгы капкач, яшьләр уйный бу уенны. Ике яклап тотынышып басалар. Бер кеше алда кала. Шуннан җырлыйлар:

*Минем чәчем – җиде тотам,*
*Җидедән үрмәсәм дә.*
*Син дустымны онытмамын,*
*Җиде ел күрмәсәм дә.*

Аннан чәбәкләп җырлыйлар:

*Наза, Наза,*
*Наза – уңган кыз бала.*
*Наза укый, Наза яза,*
*Наза ударник була.*

Яисә:

*Наза, Наза,*
*Наза, дигән бер бала.*
*Чаңгылары кулында да*
*Коммунизм юлында.*

Шушы җырны җырлаган вакытта, алда калган кеше тегеләрнең уртасыннан чыга да, үзе теләгән кешене сайлап алып, артка барып баса, ә аның иптәше алга чыга. Уен шулай дәвам итә. Төрле җырлар җырлана, чәбәкләп җырланганы уен соңына кадәр үзгәрми, җырдагы кушымта сымак.

### 340. «Кыргый» яки «Таң ярылды»

Икешәрләп тотынып басасың, бер кеше алда тора. Ул: «Кыргый!» – дип кычкыргач, арттагы ике кеше йөгерергә тиеш. Ә алда торганы, аларның берсен тотып, алга килеп баса; икенчесе, алда ялгызы гына калып: «Кыргый!» – дип кычкыра. Уен шулай бөтенесе йөгереп беткәнче бара.

*Бу уеннарны 1970 елда Чакмагыш районы Яңа Ихсан авылында*
*колхозчы-пенсионер Мәһинур Әминевадан (1915 елгы)*
*БДУ студентлары язып алган*

### 341. Буяу

Бер төркем балалар тезелешеп басалар. Берсе – «буяу сатучы», берсе «сатып алучы» була. «Сатучы» бу балаларга буяу исемнәре куша. Мәсәлән: кызыл, сары, зәңгәр, күк һ.б. Буяу исемнәре кушканны «сатып алучы» ишетмәскә тиеш. Аннан «сатып алучы» килә дә:

– Әби, нинди буяуларың бар? – ди.

– Төрлесеннән төрлесе, – ди әби. – Сиңа нинди кирәк?

Алучы буяу исемнәрен әйтә. Һәр «буяу» (кеше) үз исемен ишеткәч, йөгерергә тиеш. Әгәр «сатып алучы» моны тотса, «буяу черек» булып чыга. Мәсәлән:

– Әби, кызыл буяуың черек булды, – ди. «Сатып алучы» бөтен буяуларны алып беткәнче, уен дәвам итә.

*1970 елда Чакмагыш районы Иске Ихсан авылында*
*колхозчы-пенсионер Нәби Моратовтан*
*БДУ студентлары язып алган*

### 342. Яшермә туп

Бу уенда ничә кеше катнашса да була. Шулай ук ничә яшьтә булуына да карамый. «Яшермә туп» уены җәй көне, яз көне урамда уйнала. Көн әйбәт булган чакта уйнасаң, бигрәк тә яхшы.

Уен барышы болай. Җиргә олы итеп түгәрәк сызыла. Шул түгәрәккә берничә кеше кереп утыра. Кругның тышында басып торучылар тупны кием эчләренә яшереп әйләнеп йөриләр һәм бер-берсенә күрсәтмичә генә бирәләр. Шуннан берәү тупны түгәрәк эчендә утыручыларга җибәрә, туп тигән кеше, аны тотып алып, круг тышындагы берәрсенә тигерсә, кругтан чыга. Кругтагы кешегә туп тисә, аны «черегән» дип атыйлар. Тыштагы кешегә туп тисә, ул эчкә керә, ә эчтәгесе тышка чыга. Уен түгәрәктәге уенчылар чыгып беткәнчегә кадәр дәвам итә.

### 343. Чәкән

Бу уен малның чәкән сөяге белән уйнала. Җиргә түгәрәк сызасың, ул бик үк олы булырга тиеш түгел. Шул түгәрәккә чәкәннәрне куясың һәм уенчылар бер-бер артлы шул чәкәннәргә таяк белән сугарга тиеш. Бер сугучы ничә чәкәнне түгәрәктән чыгара, шул сөякләрне үзенә ала. Кем күбрәк чәкән җыяла, шул җиңүче булып кала. Әгәр сөяк бетсә, ул берәрсеннән сөякләрне берәр нәрсә биреп, алмашып алырга мөмкин. Бу уенда күп кеше катнаша ала.

### 344. Лапта

Бу уенны малайлар уйный. Түгәрәк уртасына таяк казап куясың. Шул таяк янына чүртине лапта белән чөеп, сугып җибәрәсең. Чүрти килеп төшкәч, лапта белән чүрти кырына үлчәп киләсең. Бер лапта үлчәме бер ипи дип атала. Шуннан таякка лаптаны сөяп куясың, чүртине җибәрәсең. Чүрти лаптага тисә, җиңүче була. Ә тигермәгәне лапта белән чүртигә сугып:

*Әбием, бабаем,*
*Кара сыер савам,*
*Без-з-з-з, –*

дип урам буйлап йөгерә. Бу аңа җәза була.

### 345. Тычкан салышлы

Кич. Өйдә күпме кеше булса да ярый. Тезелешеп утырасың. Бер башлап йөрүче куясың. Аны чутлап чыгарып сайлап була. Мәсәлән:

*Бер бабай урманга барган,*
*Аның чанасы ватылган.*

*Ул чананы төзәтергә*
*Ничә кадак кирәк булган?*

«Булган» дигән сүздә тукталган кеше берәр сан әйтә, чутлап китәсең. Һәм башлап йөрүче шулай билгеләнә. Башлап йөрүче тычкан салып йөри, салганнан соң: «Тычкан батыр, йөгереп чык!» – ди. Баса. Шул тычканлы кешегә җәза бирәләр. Мәсәлән, биергә, җырларга һ.б. Шулай, уен дәвам итә.

### 346. Яулык салышлы

Бу уенны өчтән күбрәк кеше уйный. Кызлар, егетләр түгәрәккә җыелышып утыралар. Уен иркен урынлы йортта уйнала. «Яулык яшерүче» итеп бер кеше сайлана. Мәсәлән:

*Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун –*
*Байлар кия сары тун.*
*Сары тунның бәясе –йөз дә кырык ике сум.*

Яисә икенче төрле дә сайлаганнар:

*Әлчи-бәлчи,*
*Әни күлмәк үлчи,*
*Чәүкә, чыпчык,*
*Син – кал, мин – чык!*
*Ары алачык, бире алачык.*
*Кыр капкасы шар ачык.*
*Анда – чыпчык, монда – чыпчык*
*Син дә торма, йөгереп чык!*

Әгәр дә санаучы кешенең харәмләшкәнен сизеп калсалар, аны уеннан чыгарганнар, яисә җәза биргәннәр. Санауга чыккан кеше, түгәрәкләнеп утырган кешеләр яныннан такмаклый-такмаклый йөгерә:

*Яшерәм-яшерәм яулыгымны,*
*Яшел каен артына.*
*Сиздермичә салып китәм ,*
*Бер иптәшем артына.*

Ул кульяулыкны кемгә булса да салырга тиеш. Кеше, артында кульяулык бар икәнен күрсә, башлап йөрүче була, ә күрмәсә, аңа җәза бирәләр. Ул да яулык салып китә. Уен шулай дәвам итә.

*Бу уеннарны 2002 елда Илеш районы Кыргыз авылында*
*Гыйбадулла бабай Габдуллиннан (1913 елгы)*
*БДУ студенты Альмира Хәйретдинова язып алган*

## БАЛАЛАР ФОЛЬКЛОРЫ

### 347. Бишек җырлары

1. Әлли итәр бу бала,
Бәлли итәр бу бала,
Әткәсенә-әнкәсенә
Хезмәт итәр бу бала.

2. Минем кызым бик иркә,
Башларында кәсинкә,
Күлмәгендә сәрпинкә,
Аягында бәтинкә –
Алтын чәчле, зәңгәр күзле,
Коеп куйган кәртинкә.

3. Әлли-бәлли, бәбкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка җиләккә
Бәбкәсенә бүләккә.

4.Әлли-бәлли, бәбкәем,
Җан йөрәгем, нәнәкәем,
Рәхәт кенә тынычланып
Йоклап китәр бәбкәем.

*2001 елда Дүртөйле шәһәрендә яшәүче*
*Мәүлидә Хәбәбетдин кызы Сәлимгәрәевадан (1952 елгы)*
*БДУ студенты Гүзәл Сәлимгәрәева язып алган*

### 348. Баланы өчтеки иттерү

Үчтеки, үчтеки,
Үсмәгәнгә үчтеки.
Илдән-җирдән бер булыр,
Бер дип әйткән ул булыр.

*2001 елда Дүртөйле шәһәрендә яшәүче*
*Мәүлидә Хәбәбетдин кызы Сәлимгәрәевадан (1952 елгы)*
*БДУ студенты Гүзәл Сәлимгәрәева язып алган*

### 349. Баланы мунча кертү, юындыру

Элек авылда баланы беренче башлап мунча керткәндә, кендек әбисе болай дип әйтеп чабындыра торган булган.

Атаң кискән утын түгел,
Анаң яккан мунча түгел,
Аюдай ага бул,
Бүредәй бөгә бел,
Аю баласы, бүре баласы,
Мунча ташы, бүрәнә башы,
Картны күрсәң, «бабай», диген.
Карчыкны күрсәң, «әби», диген.
Яшьне күрсәң, «абзый», диген,
«Җиңги», диген –
Тәмле-татлы телле бул.
Минем кулым түгел –
Әйшә-патима кулы.
Минем телем түгел –
Идел кичкән инәкләр теле.
Кәбестәгә су салдым –
Суы сарыксын.
Ят та йокла, тор да уйна!

### 350. Баланы коендыру

Кәбестәгә су салдым –
Суы сарыксын,
Үзе калыксын,
Имәндәй таза булсын,
Үзәктәй озын булсын!
Ябалактан йон ал,
Бүдәнәдән – май,
Кәбестәдән – аклык,
Судан – пакьлык,
Баламнан кичер
Дөньяга шатлык.

### 351. Кояш чакыру

Кояшкаем, чык,чык!
Майлы кашык бирермен,
Майлы таба бирермен.
Симез үгез суярмын –

Маен сиңа куярмын,
Итен үзем ашармын,
Сөяген эткә ташлармын.

### 352. Яңгыр чакыру

1. Яңгыркаем, яу, яу!
Тәти кашык бирермен,
Тәмле ботка бирермен –
Тәти кашык базарда,
Майлы ботка казанда.

*1977 елда Борай районы Иске Тазлар сигезьеллык мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты түгәрәге әгъзалары җыйган материаллардан БДУ студентлары күчереп алган*

2. Яңгыркаем, яу, яу!
Җиргә ачлык килмәсен.
Ачтан халык үлмәсен,
Чума чире йөрмәсен!
Яңгыркаем, яу, яу!
Иген-ашлык мул булсын,
Кибән-эскерт күп булсын!
Яңгыркаем, яу, яу!

*2017 елда Илеш районы Илеш районы Рсай урта мәктәбенең туган якны өйрәнүчеләр түгәрәгенең архивында саклаучы Мөнибә Сабирҗан кызы Камалова истәлекләреннән (1912 елгы, Бишкурай авылында туган) БДУ студенты Ләйсән Вәлиханова күчереп алган*

3. Яңгыркаем, яу,яу!
Байның йөрәген яндыр!
Без ятырбыз ябынып,
Байлар йөрер кабынып.

*(2017 елда Илеш районы Илеш районы Рсай урта мәктәбенең туган якны өйрәнүчеләр түгәрәгенең архивында саклаучы Фәния Сәләхетдин кызы Ямалиева истәлекләреннән (1918 елгы, Рсай авылында туган) БДУ студенты Ләйсән Вәлиханова күчереп алган*

### 353. Яңгыркаем, яу, яу!

Сыерларга сөт булсын.
Игеннәрнең башаклары
Ач булмасын, тук булсын.
Яңгыркаем, яу, яу!
Бакчадагы алмага
Корый яңгыр булмагач.
Бакчалардан ни файда бар,
Алма пешеп тормагач!

*2017 елда Илеш районы Илеш районы Рсай урта мәктәбенең*
*туган якны өйрәнүчеләр түгәрәгенең архивында саклanучы*
*Гомрух Хөсәен кызы Ялаева истәлекләреннән*
*(1928 елгы, Тыпый авылында туган) БДУ студенты*
*Ләйсән Вәлиханова күчереп алган*

### 354. Каз бәбкәсе саклаганда, тилгән куу

Тилгән, тилгән
Бәбкә алырга килгән –
Бер аягы камырдан,
Бер аягы тимердән –
Көш-ү-ү!

Тилгән, тилгән
Бәбкә күрсә тилергән,
Бер бәбкә дә алмыйча
Көне буе тилмергән.

Тилгән, тилгән
Агач башын көйдергән
Бер канатын каерган.
Балаларын-чагаларын
Хәер эстәп туйдырган.

Атаң сиңа ни дигән?
– Бәбкә урлама, – дигән.
Бер күзеңә – яфрак,
Бер күзеңә – туфрак –
Көш-ү-ү!

### 354. Тукранга эндәшү

Тук, тук, тукран,
Тукылдатып утырам.
Мичтә бәлеш пешәме?
Шуны көтеп утырам.

Тук, тук, тукран
Тугыз имән чукыган.
Унынчысын тукыганда
Егылып төшкән чукынган.

*1977 елда Борай районы Иске Тазлар сигезьеллык мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты түгәрәге әгъзалары җыйган материаллардан БДУ студентлары күчереп алган*

### 355. Бармак уеннары

Бу бармак – бабай,
Бу бармак – әби,
Бу бармак – әти,
Бу бармак – әни,
Бу бармак – нәни бәби,
Аның исеме Чәнти!

*2001 елда Дүртөйле шәһәрендә яшәүче Мәүлидә Хәбәбетдин кызы Сәлимгәрәевадан (1952 елгы) БДУ студенты Гүзәл Сәлимгәрәева язып алган*

### 356. Тизәйткечләр

Сантый бара сыерын сава, сауган сөтен сәкедәге сиксән сигез соры савытка сала.

Сантый Сайра сарайда сарыкларга салам салганда, сарыкларның сыртына салган да, сәнәген сындырып, сәндерәгә салган.

*1964 елда Балтач районы Комъязы авылында БДУ студентлары язып алган. Информатор күрсәтелмәгән*

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТМАЛАР

АЭМ, 1973 – СССР Фәннәр Академиясе Уфа гыйльми үзәге Тарих, тел, әдәбият институтының 1973 елгы археографик экспедиция материаллары.

БХИ РЛ, 1980 – Башҡорт халыҡ ижады: риүәйәттәр, легендалар / төҙөүсеһе, инеш мәҡәлә һәм аңлатмалар авторы Фәнүзә Нәҙершина; яуаплы редакторы Кирәй Мәргән. Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1980.

БХИ РЛ, 1997 – Башҡорт халыҡ ижады: риүәйәттәр, легендалар. Икенсе том / төҙөүсеһе, инеш мәҡәлә һәм аңлатмалар яҙыусы Фәнүзә Нәҙершина; яуаплы мөхәррирҙәре Кирәй Мәргән менән Әхмәт Сөләймәнов. Өфө: «Китап», 1997.

Исхакова-Фаткуллина – Башкорт дәүләт университеты филология факультеты студенты Э.И. Исхакова-Фаткуллинаның «Балтач районы татарларының легендалары һәм риваятьләре» исемле чыгарылыш квалификация эше / фәнни җитәкчесе: филология фәннәре кандидаты, доцент И.К. Фазлетдинов. – Уфа, 2016 *(кульъязма)*.

МПТД, I, II, III, IV, V – Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1955 – вып. I, 1962 – вып. II, 1974 – вып. III, 1978 – вып. IV, 1984 – вып. V.

ТХИ РЛ – Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С. М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1987.

Фазлетдинов, 2018 – Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррир Ә.М. Сөләйманов. – Уфа: Китап, 2018. – 344 б.

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ 3
АВЫЛ ТАРИХЛАРЫ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
**Бакалы районы** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
1. Камышлы авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
2. Мостафа авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
**Балтач районы** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
3. Әрдәгеш авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
4. Балтач авылы *(1 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . 24
5. Балтач авылы *(2 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . 25
6. Бигелде авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
7. Итәвәш авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
8. Карыш авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
9. Мата авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
10. Сандугач авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
11. Тимер җире . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
12. Тучыбай (Туйчыбай) авылы . . . . . . . . . . . . . . . . 27
13. Тушкыр авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
14. Штәнде авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
15. Яңа Янбай авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
**Борай районы** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
16. Бадрак авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
17. Бакалы авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
18. Бигәнәй авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
19. Борай авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
20. Йомакай авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
21. Кәшкәләү авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
22. Кәшкәләү, Бакалы, Шады, Даутлар, Карагыш авыллары . . . 33
23. Кодаш авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
24. Кузбай авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
25. Сәет-Көрҗә, Ает авыллары . . . . . . . . . . . . . . . . 35
26. Үтәгән авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
**Дүртөйле районы** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
27. Дүртөйле авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
28. Дүртөйле һәм Илеш районы авыллары . . . . . . . . . . 37
29. Мәскәү авылы *(1 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . 37

30. Мәскәү авылы *(2 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
**Илеш районы** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
31. Базытамак авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
32. Бишкурай авылы *(1 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
33. Бишкурай авылы *(2 нче вариант* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
34. Бәләкәй Бишкурай авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
35. Бүләк авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
36. Груздьевка авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
37. Дөмәй авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
38. Иләкшиде авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
39. Илеш авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
40. Исәмәт авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
41. Иске Күктау авылы *(1 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . 43
*42. Иске Күктау авылы (2 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . 44
43. Иске Күктау авылы *(3 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . 45
44. Яңа Күктау авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
45. Ишкар авылы*(1 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
46. Ишкар авылы*(2 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
47. Иштирәк авылы *(1 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
48. Иштирәк авылы*(2 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
49. Йонны авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
50. Кадер авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
51. Лена авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
52. Рсай авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
53. Сүлте авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
55. Теләкәй авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
56. Тыпый авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
57. Уяндык авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
58. Үрмәт авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
59. Череккүл авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
60. Этәй авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
61. Югары Яркәй авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
62. Ябалак авылы*(1 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
63. Ябалак авылы *(2 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
**Чакмагыш районы** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
64. Бәшир авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
65. Калмаш авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
66. Карьяуды авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
67. Коты авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
68. Рәҗәп авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
69. Тозлыкуш авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
70. Үрнәк авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
71. Чакмагыш авылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61

РИВАЯТЬЛӘР . . . 62
**Тарихи риваятьләр** . . . 62
***а) Алтын Урда дәвере һәм карымта-барымта яулары турында*** . . . 62
72. Урда . . . 62
73. Калатау һәм Калмык күле . . . 62
74. Үрәзикәй чишмәсе . . . 62
75. Такыя тавы . . . 63
***ә) Батырша, Салават Юлаев һәм Емельян Пугачев җитәкчелегендәге милли-азатлык көрәше турында*** . . . 63
76. Батырша күле . . . 63
77. Пугач белән Салават юлы . . . 64
78. Әби патша юлы . . . 65
79. Каторжан юлы . . . 65
80. Йолдыз тавы . . . 66
81. Кала тавы . . . 66
***б) Җир биләүчеләр һәм җир өчен сугышлар турында*** . . . 66
82. Күҗмә зираты . . . 66
83. Гәрәй имәнлеге . . . 67
84. Илекәй карт . . . 67
85. Кала күле . . . 68
86. Әдел тавы . . . 68
87. Әптерәү иннеге . . . 69
88. Баяр бакчасы . . . 69
89. Кәсәй тавы . . . 69
90. Нажы буе . . . 70
91. Сугыш чокыры . . . 70
92. Яшь барыня урманы . . . 71
93. Җир сату . . . 71
94. Аю җире . . . 71
***в) Милләтара, динара мөнәсәбәтләр, ыру, сословие атамалары белән бәйле риваятьләр*** . . . 72
95. Башкорт очы, Түмән очы . . . 72
96. Башкорт урамы . . . 72
97. Типтәр басуы . . . 73
98. Типтәр ягы . . . 73
99. Казакъ тау башы . . . 73
100. Бетле саз . . . 74
101. Мариларны куу . . . 75
102. Кыргыз бүләге җире . . . 75
103. Тушкыр суы, Көсәк күл . . . 75
***г) Караклар һәм качкыннар хакында*** . . . 76
104. Кизгән сазы . . . 76

105. Гайнетдин чокыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
106. Әпес тавы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
107. Яркәй тавы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
***д) Социаль һәм милли изү фаҗигаләре хакында*** . . . . . . . . 77
108. Баяс урманы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
109. Саклау урманы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
110. Вафа буасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
111. Мәчет саклавы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
112. Сәгъдәт кулы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
113. Шәмсия чокыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
114. Хәдичә урамы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
***ж) Гражданнар сугышы турындагы риваятьләр*** . . . . . . . . 81
115. Смак күле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
116. Солдат күпере . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
117. Солдат имәнлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
118. Бетле күпер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
119. Гәверлә кыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
120. Сәет тавы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
121. Чучак тавы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
122. Җиде каен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
123. Челтер чишмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
**Топонимик риваятьләр** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
***җ) Халыкның шөгыле, тормыш көтү, яшәү рәвеше,***
***йола һәм гореф-гадәтләре турында*** . . . . . . . . . . . . . . 85
124. Силдиби күл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
125. Гөлчирә чокыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
126. Кашыкбаш урамы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
127. Салкын чишмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
128. Фарсый буасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
129. Ялгыз каен басуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
130. Балкүмгән басуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
131. Баязит аланы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
132. Гайнешлим табуры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
133. Гайса каены . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
134. Кәҗә, Мишәр, Мөгәҗәй урамнары . . . . . . . . . . . . . 88
135. Көрпә елгасы *(1 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . 89
136. Көрпә елгасы *(2 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . 89
137. Тимеркәй урамы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
138. «Чабатачылар» белән «суганчылар» . . . . . . . . . . . . 90
139. Алтын күпер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
140. Тимер юлы җире . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
***з) Табигать стихияләре, бәла-каза, афәтләр хакында*** . . . . . 91
141. Көек ялан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91

***и) Кайчандыр әйтелгән сүзләргә нигезләнеп барлыкка килгән урын атамалары турында*** . . . 91
142. Сикияз елгасы . . . 91
143. Иске йорт . . . 92
144. Каракай урамы . . . 92
145. Кортлы саз . . . 93
146. Кызыл таң чишмәсе . . . 93
***к) Шәхси фаҗигаләр турында*** . . . 94
147. Хасбулат чокыры . . . 94
148. Каңгылды зираты . . . 94
149. Мәк тавы . . . 94
150. Семен күле . . . 95
151. Хәния чишмәсе . . . 95
152. Азнай чокыры . . . 96
153. Әбиләр чокыры . . . 96
154. Марҗа чокыры . . . 96
155. Әмин кулы . . . 97
156. Шабай күле . . . 97
157. Исмәгыйль, Заһид һәм Сәйкәй чокырлары . . . 98
158. Разия чокыры *(1 нче вариант)* . . . 98
159. Разия чокыры *(2 нче вариант)* . . . 98
***л) Игелекле затлар, әүлияләр, изге чишмәләр турында*** . . . 98
160. Әүлия чишмәсе *(1 нче вариант)* . . . 98
161. Әүлия чишмәсе *(2 нче вариант)* . . . 99
162. Изгеләр чишмәсе . . . 100
163. Әүлия кабере . . . 100
***м) Кеше һәм хайваннар дөньясы арасындагы мөнәсәбәтләр турында*** . . . 101
164. Әхмәр кулы . . . 101
165. Бизәр тавы . . . 101
**Көнкүреш вакыйгалары турында** . . . 102
166. Шапыр күле . . . 102
167. Идрис сазы . . . 102
168. Разыя таллары . . . 103
169. Мөхәммәтдин батыр . . . 103
ЛЕГЕНДАЛАР . . . 104
**Зоогоник легендалар** . . . 104
170. Аюлар каян килеп чыккан? . . . 104
171. Ни өчен тирәк агачы җимешсез булып калган? . . . 104
172. Кандала каян барлыкка килгән? . . . 105
173. Тартай белән кысла ничек килеп чыккан? . . . 105
174. Үрмәкүч белән чебен каян барлыкка килгән? . . . 106

**Дини легендалар** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
175. Якуп пәйгамбәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
176. Тәкъдир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
177. Сөләйман пәйгамбәр белән Бәлхис патша . . . . . . . . 108
178. Тылсымлы йөзек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
179. Чупа ябалак турында хикәят . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
**180. Фиргәвен турында хикәят** . . . . . . . . . . . . . . . . . . **111**
**Алыплар турындагы легендалар** . . . . . . . . . . . . . . . 115
181. Иш тавы *(1 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
182. Иш тавы *(2 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
МИФОЛОГИК ХИКӘЯТЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
183. Убыр белән очрашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
184. Абзар иясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
185. Зират иясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
186. Мунча иясе *(1 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
187. Мунча иясе *(2 нче вариант)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
188. Мунча җене . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
189. Юл иясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
190. Куркыныч «өчпочмак» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
191. Адаштыра торган урман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
192. Өй иясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
193. Өй иясен чакыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
194. Җен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
СӨЙЛӘКЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
195. Мин Тукайны күрдем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
196. Ленин белән очрашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
197. Җеп еланы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
198. Кулак калдыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
199. Мулла яхшы булмый, козгын кош булмый . . . . . . . 126
200. Ат эзләгәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
201. Тун тиреле каз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
202. Рамазан ае килгәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
203. Ике такмак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
204. Мич чыгаргач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
205. Яшканың үлеме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
206. Яшка батыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
МӘЗӘКЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
207. Мәтык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
208. Гөбе боткасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
209. Аңгыра кияү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
210. «Ике генә каптым ич!» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
211. Оялчанлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
212. Тапкырлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134

213. «Кайсы тирәдә туктыйм?» . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
214. Тыйнак кияү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
215. Шунда ук бар иденмени? . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
216. Кызганган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
217. Кашык бушагач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
218. Кунакчыл хуҗа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
219. Салкын канлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
220. Аңласаң, аңла... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
221. Аю тоткан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
222. Наданлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
223. Диктант язганда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
224. Физкультура дәресе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
225. Сәүдәгәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
226. Сыерга бозау ашату . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
227. Юри генә әйттем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
228. Барыбер үлгән инде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
229. Контужен булган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
230. Жикет хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
ӘКИЯТЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
**Хайваннар турында әкиятләр** . . . . . . . . . . . . . . . 141
231. Үткер кияү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
232. Песи белән тычкан балалары . . . . . . . . . . . . . . 141
233. Үткер песи . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
234. Аю белән төлке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
235. Кәҗә белән аю . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
236. Бал корты ничек кәҗәне җиңгән? . . . . . . . . . . . 145
**Тылсымлы әкиятләр** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
237. Үги ана белән малай . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
238. Явыз патша һәм тереклек чишмәсе . . . . . . . . . . . 148
239. Ал чәчкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
240. Кыз һәм патша . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
241. Яман хатын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
242. Ятим бала һәм сары ат . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
243. Көчек һәм хатын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
244. Ятимә кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
245. Усал хатын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
246. Алтын балалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
247. Кара сыер һәм үги кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
248. Байдогыш әкияте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
249. Алтын балдак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
250. Ана васыяте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
251. Ана сөте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171

**Тормыш-көнкүреш әкиятләре** . . . . . . . . . . 172
252. Аждаһа кәләше . . . . . . . . . . 172
253. Тапкыр таз . . . . . . . . . . 173
254. Мылтыкчы карт хәйләсе . . . . . . . . . . 175
255. Зирәк кыз . . . . . . . . . . 176
256. Әкият яратучы король . . . . . . . . . . 178
257. Кәҗә, фәкыйрь һәм мәзин . . . . . . . . . . 179
258. Таз әкияте . . . . . . . . . . 180
259. Кырык карак әкияте . . . . . . . . . . 182
260. Өч туган . . . . . . . . . . 185
261. Тугрылык һәм хыянәт . . . . . . . . . . 186
262. Ике сатучы . . . . . . . . . . 187
263. Тапкыр кыз . . . . . . . . . . 187
264. Пәйгамбәр акылы . . . . . . . . . . 193
265. Поп ничек көлкегә калган? . . . . . . . . . . 194
266. Без еламый кем еласын? . . . . . . . . . . 197
БӘЕТЛӘР . . . . . . . . . . 198
**Сак-сок бәетләре** . . . . . . . . . . 198
267. Беренче бәет . . . . . . . . . . 198
268. Икенче бәет . . . . . . . . . . 199
**Хәрби-тарихи бәетләр** . . . . . . . . . . 201
269. Миңнулла бәете . . . . . . . . . . 201
270. Герман сугышы бәете . . . . . . . . . . 202
271. Аерылу бәете . . . . . . . . . . 203
272. Сугыш бәете . . . . . . . . . . 204
273. Әфган сугышы бәете . . . . . . . . . . 204
274. Чечен сугышы бәете . . . . . . . . . . 206
**Социаль-иҗтимагый бәетләр** . . . . . . . . . . 207
275. Манара бәете . . . . . . . . . . 207
276. Мирсәет бәете . . . . . . . . . . 208
277. Сәхәб бәете . . . . . . . . . . 209
278. Ачлык чире бәете . . . . . . . . . . 210
279. Төрмә бәете . . . . . . . . . . 211
**Хатын-кызның михнәтле язмышы турындагы бәетләр** . . . . 212
280. Гайшә бәете . . . . . . . . . . 212
281. Комсомолка кыз бәете . . . . . . . . . . 213
282. Фәрүзә кыз бәете . . . . . . . . . . 214
**Шәхси фаҗигаләр турындагы бәетләр** . . . . . . . . . . 215
283. Хәлимә әби бәете . . . . . . . . . . 215
284. Яхъя бәете . . . . . . . . . . 216
285. Фәтхерахман бәете . . . . . . . . . . 219
286. Суга баткан Гайшә бәете . . . . . . . . . . 221

**Сатирик бәетләр** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 221
287. Самогончы Хафиз бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . 221
288. Хәсән мулла бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
289. Канау буе бәете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 223
МӨНӘҖӘТЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 224
**Үлем турында** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 224
290. Беренче мөнәҗәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 224
291. Икенче мөнәҗәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 225
292. Өченче мөнәҗәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 227
293. Дүртенче мөнәҗәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 228
294. Бишенче мөнәҗәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 230
295. Рамазан ае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 231
296. Уза гомеребез зарланып... . . . . . . . . . . . . . . . . . 232
297. Әллә яшьли генә җәтим калганга мин... . . . . . . . . . 233
298. Аналар утыра түрдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 234
ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
**Лирик җырлар** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
299. Зиннәт җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
300. Мәдинәкәй җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236
301. Асраулар җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236
302. Төрмә җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
303. Әллүки . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
304. Тау җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
305. Алдырмастай киек, ай, алдырмас... . . . . . . . . . . . 238
306. Сагыну җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 238
307. Егет җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 239
308. Яшьлек җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
**Рекрут һәм солдат җырлары (назлар)** . . . . . . . . . . . 242
309. Солдатка киткәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 242
310. Солдат җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 242
311. Табын җырлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 243
312. Кыска җырлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 245
313. Такмаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 250
АФОРИСТИК ИҖАТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
314. Мәкальләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
315. Әйтемнәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256
316.Табышмаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 258
317. Сынамышлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 269
318. Ышанулар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 271
319. Юраулар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 272
ЙОЛА ИҖАТЫ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 274
**Өмәләр** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 274
320. Тула өмәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 274

321. Тула басу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 275
**Гаиләкөнкүреш йолалары** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 275
322. Туй йоласы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 275
323. Кода белән кодача арасында әйтеш . . . . . . . . . . . . 277
324. Аулак өй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 279
ИМ-ТОМНАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 279
325. Күз тигәндә төтәсләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 279
326. Күз тигәндә өшкерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 279
327. Чирне өшкерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 280
328. Дәвалаганда әйтелә торган сүзләр . . . . . . . . . . . . . 280
329. Елан им-томы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 280
330. Уа догасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 280
ХАЛЫК УЕННАРЫ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 281
331. Үрдәк атыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 281
332. Песи белән тычкан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 281
333. Шпион . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 281
334. Аксак мәче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 282
335. Граница алыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 282
336. Энә белән кое казу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 283
337. Чокыр туп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 283
338. Качкалак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 284
339. Наза . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 284
340. «Кыргый» яки «Таң ярылды» . . . . . . . . . . . . . . . . 285
341. Буяу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 285
342. Яшермә туп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 285
343. Чәкән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 286
344. Лапта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 286
345. Тычкан салышлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 286
346. Яулык салышлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 287
БАЛАЛАР ФОЛЬКЛОРЫ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 288
347. Бишек җырлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 288
348. Баланы өчтеки иттерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 288
349. Баланы мунча кертү, юындыру . . . . . . . . . . . . . . . 288
350. Баланы коендыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 289
351. Кояш чакыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 289
352. Яңгыр чакыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 290
353. Яңгыркаем, яу, яу! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 291
354. Каз бәбкәсе саклаганда, тилгән куу . . . . . . . . . . . . 291
354. Тукранга эндәшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 292
355. Бармак уеннары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 292
356. Тизәйткечләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 292
**Шартлы кыскартмалар** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 293

Научно-популярное издание

**ФОЛЬКЛОР ТАТАР БАШКОРТОСТАНА**

*Центральные и северо-западные районы*

Составитель, автор вступительной статьи и комментариев:
*Ильдус Камилович Фазлутдинов*

(на татарском языке)

Корректор *Р.К. Сагдеева*
Компьютерная верстка *А.В. Булатова, Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Подписано в печать 20.01.2021.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная.
Усл.-печ. л. 17,7. Уч-изд. л. 14. Тираж 1000 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20